Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

11

ноябрь 2018

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

АЛСУ ТИМЕРГАЛИНА «КАЗАН».

5 ОКТЯБРЬ – ХАЛЫКАРА УКЫТУЧЫЛАР КӨНЕ

6 октябрь көнне Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концертлар залында Укытучылар көненә багышланган тантана узды. Тантанада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, мәгариф хезмәткәрләре катнашты.

Фотолар http://president.tatarstan.ru/ сайтыннан

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
11 (299)
ноябрь 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

57

68 **ЙОРТ ИЯСЕ – ЙОРТ ТОТКАСЫ**

74 **РОМАН УЙЛАНДЫРА.** *Аяз Гыйләҗев*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Шәүкәт Галиев**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Гәүһәршад.** *О.Иванова*
10 **Казан ханлыгының язмышы.** *Б.Хәмидуллин*
16 **Эчкен татарлары.** *Р.Исакаев*
20 **Гани бай.** *Б.Шәрәф*
29 **Ачлыктан соң Татарстан авыллары.** *Р.Сабиров*
34 **Шам татарлары.** *Л.Мортазина*
37 **Гарәп мохитендә татар туе.** *Камал*
40 **Риза казый нәселе.** *Р.Шаһиев*
44 **Нияз хәзрәт Сабиров: «Тарикатьләр – экстремистик ислам агымнарына альтернатива»**
46 **Кәче иле.** *Ф.Закиров*
51 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**

ТАТАР ГАМЕ

52 **Дөнья гаме – садә җанында.** *Л.Лерон*
57 **«Буа Талиясе».** *М.Хәбетдинова*

ДИНИ МИРАС

62 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ЯДКӘРЛӘРЕБЕЗ

67 **Алишны халык онытмый**

ФОЛЬКЛОР МИРАСЫ

68 **Йорт иясе – йорт тоткасы**

ӘДӘБИ МИРАС

74 **Роман уйландыра.** *А.Гыйләҗев*
82 **Мәгыйшәт.** *С.Максуди*
88 **Шагыйрь Бәдруш Мокамай.** *Ф.Хәбибуллин*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89520365448

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 **Тыңлагыз, Казан сөйли!** *Ф.Галимуллин*
98 **Истә, һаман да истә!**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

100 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
102 **Телебезне кадерләп саклыйк.** *Р.Юсупов*

ХӘТЕР САГЫНДА

106 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
112 **Кала тавы**
114 **Киез итекләр иле**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы**. *Ноябрь*

Заказ №Е-2836. Тираж – 2100 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 23.10.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иркле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Казан». 2008. ***Алсу Тимергалина рәсеме***

Шәүкәт Галиев

(20.11.1928-7.05.2011)

Һәр таштан да ут чыкмый.

***

Һәр сукмак та юлга әверелми.

***

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел.

***

Сәхнәдә аңгыра ролен уйнарга акыл кирәк.

***

Тар күңеллене киң күңелле дә сыйдырмас.

***

Сәнгатьтә биек күтәрелер өчен, тирән төшәргә, тирәнлеккә төшәр өчен, биек күтәрелергә кирәк.

***

Шик, шикәр түгел, тиз эреми.

***

Кыңгыр эш – кыңгыраулы.

***

Коелган чәч агармый.

***

Кешенең ялгышы шунда – ялгышны гел бүтәннәрдән эзли.

***

Онык күзе – офыкта, бабай күзе – шәфәкъә.

***

Бала күзен әти ача, әтиләр күзен бала йомдыра...

***

Кояшта яфрак матурлыгы күренә, давылда тамыр ныклыгы беленә.

***

Кешелек дәрәҗәңне саклый белү – иң югары дәрәҗә.

***

Үткән көннәрнең төннәре дә якты.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

Гәүһәршад

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Казандагы тормыш-көнитеш, Гәүһәршад ерактан торып күз алдына китергәнчә, җайлы гына бармый. Габделлатыйф хан сеңлесенең пырдымсыз, тәкәллефсез холкын күтәрә алмый, ул аны булачак олуг карачы Булатширинга димләргә җыена. Булатширин яшь, чибәр, Гәүһәршад шуңа күрә ул күрекле ирнең сөйкемсез хатыны булудан курка, аның һаман да үз-үзенә хуҗа булып каласы килә. Шул ук вакытта ханәкә тугрылыклы мәхәббәт эзли. Язмышы һәм кырыс агасы моның өчен аны яңа сынаулар алдына куя. Габделлатыйф киребеткән кыз туганын чал чәчле әмиргә – Булатширинның бабасына бирә. Ни гаҗәп, карт Коләхмәд ханәкәгә ошый, ә ул теге дөньяга киткәч, яшь хатын гомумән рәхәткә чыга, үзаллы яшәүгә ирешә һәм сәяси уеннарда катнаша башлый. Хан кызы буларак, Гәүһәршадның Казан диванында утырырга тулы хокукы бар, ул заман кәгазьләрендә аның исеме беренчеләрдән булып атала. Анасы яклаган бар нәрсәне куралмый торган Гәүһәршад «шәрекъ фиркасе»н җитәкли, шул көннән башлап Мәскәү аның төп дошманына әйләнә. Мөхәммәдәмин ханның вафатыннан соң, ирләр ягыннан бөек Олуг Мөхәммәд нәселе өзелә.

Ике агасы да фани дөньядан күчкәч, Гәүһәршад үз заманында Казан ханлыгына нигез салган Олуг Мөхәммәд нәселенең бердәнбер дәвамчысы булып кала. Рус елъязмачылары күзлегеннән ул күп санлы мәкерле һәм астыртын эш йөртүләр, түнтәрелешләрдә катнашучы дип санала.

Алда әйткәнебезчә, Гәүһәршад, әнисе Нурсолтаннан аермалы буларак, Русь белән бер сүздә яшәү, дуслык тарафдары түгел. Әмма тапкырлыгы, зирәк акылы һәм табигатеннән килүче хәйләкәрлеге ярдәмендә ул яраклаша белә һәм Казан сәхнәсенә (тәхетенә) бөек кенәз куйган Шаһгали ише «курчаклар» белән шактый оста гына уйный. Хәтта аз сүзле, бигрәк тә тасвирлауга саран документаль чыганакларда да (әлбәттә, русныкында) аның башкалардан аерылып торган, хакимлек итәргә яратучы, хатын-кызга бигүк хас булмаган коры-кырыс холыклы шәхес икәнлеге ачыла. Гәүһәршад, шул дәвернең иң йогынтылы сәяси затларыннан берсе буларак, Мәскәүнең Казан өстенә бастырган «алтын багана»ларына озак табынып тора алмый, үз тарафдарлары белән сүз куешып, Шаһгалине илдән кудырта.

Бу дәвердә Казан тәхетен бер-бер артлы алышынып торган ханнар били, Кырым-

---

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

нан да солтаннар килгәли, Гәүһәршад ханәкә исә, аңа карамый, диванда ныгып утыруын дәвам итә, төрле хәйләкәр планнар кора тора...

Ул кырымлыларга да рәхим-шәфкатьле булмый. Кайчандыр кияүгә чыгарга теләмәгән көндәше – әмир, ягъни шул чордагы диван (хөкүмәт) башлыгы Булатширин белән берләшеп эш йөртә һәм үз максатларына ирешә. Әлбәттә, Казан тәхетенә читтән килгән ханнарның фәрештә булмавы, илнең байлыгын оятсыз рәвештә талаулары, аның чәчәк атуы турында кайгыртмаулары да хак. Шуңа күрә әледән-әле булып торган түнтәрелешләр, аксөяк-түрәләрнең генә түгел, гади халыкның да түземлеге тәмам төкәнгәч, бу карак «илбаш»ларын ике якның да кулга-кул тотынышып кууы белән төгәлләнгән...

Мөдәррис Вәлиев

...Язгы аяз көннәрнең берсендә шагыйрьләрнең Сәмәрканд мәктәбе мөриде Мөхәммәдьяр кунакчыл төстә киң итеп ачылган Казан капкасыннан килеп керде. Аның белән янәшәдәге ияр өстендә өлкән юлдашы, мөридләрнең зур хөрмәткә ия остазы Галим хаҗи чайкалып бара иде. Мөхәммәдьяр – хаҗиның иң яраткан пишкадәмнәреннән[1] берсе, шуңа бөек Итил ярларында күкрәгән киереп баскан калага күптән кайтып килергә теләгән остаз аны үзе белән сәфәр чыгарга өндәде.

– Ул ханлыкта чын шигъриятнең кадерен беләләр. Хуҗалары Мөхәммәдәмин хан бәхетле җырләрдә нәфис сәнгатьне кабат торгызды, каләм әһленә менә дигән яшәү шартлары тудырды. Шәкертем, аксакаллар янында – акыл иясе, шагыйрьләр янында – шагыйрь, ә йолдызбагарлар мохитендә нөҗүм галиме[2] булган ул шәхес белән аралашудан син чын ләззәт алырсың әле! Ихластыр, хакимнең шундый бөек аң вә сәләткә ия булуы – Ходайдан килгән бүләк бит!

Тик Казан ханлыгы чикләренә җитү белән, Галимнең өмете өзелеп, бәгыре телгәләнде. Яшь чагында ук белгән хакимнең инде гүр иясе булуын шунда гына ишетте ул.

– Әмма без барыбер бу юлны бушка гына кичмәдек, – дип, әллә үзен, әллә шәкертен юатты мөдәррис[3]. – Яңа хаким безне үзенең мәрхәмәтле канаты астына алыр. Сабый баладан алып чал чәчле картларга кадәр барчасы да шигырь укудан-язудан тәм тапкан илдә иҗат итүнең иң югары хозурлык икәнлеген шулай тиз генә онытмаганнардыр әле.

Алар Казан капкасыннан буш калта[4] тотып диярлек килеп керделәр. Азмы-күпме булган сәрмаялары юлда тотылып бетте, шунлыктан, сәфәрчеләр атларын туп-туры хаким сараена таба юнәлттеләр. Казан язы Сәмәркандныкыннан нык аерыла икән шул, күптән түгел сибәләп узган яңгырдан соң киемнәре әле кибеп өлгермәгән шагыйрьләр икесе дә салкыннан бөрешеп киләләр иде. Бу сәгатьтә хан эргәсе каршына җыелган гозерле халык төркемен күреп, шулар янында туктап калдылар. Монда игенчеләр, вак сәүдәгәрләр, дәрвишләр дә булырга охшаган. Ханга һәркайсының үз йомышы бардыр, әмма, боек кына сөйләшеп-киңәшеп торуларына караганда, биек койманы үтеп керү һәм Казан хакиме каршында йөгенү мөмкинлегенә берсе дә өметләнми шикелле. Иң алда өелешеп торучыларга кинәт җан керде, алар, күзгә күренмәс кылыч чабып төшергәндәй, ике якка аерылдылар. Ниндидер могҗиза белән иң элек галим-голяма урын алган икән. Ул арада капус-капкадан башта усал җайдаклар очып чыкты, алар, айбалталарының агач саплары белән эткәләп-төрткәләп, төркемне тагын да чигенергә, сибелә-чәчелә төшәргә

[1] Пишкадәм – иң алдынгы шәкерт *(тәрҗ. иск.)*.
[2] Нөҗүм галиме – йолдызбагар, астролог, астроном *(тәрҗ. иск.)*.
[3] Мөдәррис – остаз.
[4] Калта – акча янчыгы *(тәрҗ. иск.)*.

«Гәүһәршад». Зөфәр Хәкимов рәсеме

мәҗбүр иттеләр. Болар артыннан, кара чарыска[5] атланган хан үзе дә күренде. Аты, һай, матур иде. Аның зифа гәүдә-сыны, акыллы башы-карашы, үзенең бәясен белеп кенә атлаулары сокландырды. Җилкә калкымыннан алып койрыгынача чапрагы[6] да үтә зиннәтле-купшы. Казан осталарының бу затлы иҗат җимеше гаҗәеп чигешләр, алтын һәм көмеш чәмчә, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән. Бай нәкыш арасына учлап-учлап сибелгән асылташлар күзләрне камаштыргыч язгы кояш нурында очкыннар чәчеп уйный. Айгыр да, япмасы матур булган кебек, үзенең дә бик күркәм икәнлеген белгәндәй, башын югары чөеп, горур адымнар белән йөзеп кенә алга бара. Гүзәл атыннан аермалы буларак, ияргә менеп өлгергәнче үк төшәргә җыенгандай, авыр һәм бик ипсез-уңайсыз утырган яшь ханның кыяфәте генә ташка үлчим диярлек. Алагаем киң япма-чапаны, купшы кием-салымнары, кукраеп кына капкадан чыгып килүе – боларның берсе дә Шаһгалинең шөкәтсез гәүдәсен каплап-яшереп бетерә алмый. Аяклары кыска, шуңа күрә өзәңгеләр махсус сайланганлыгы ап-ачык күренеп тора; гәүдәсе калын-симез һәм килбәтсез; куллары артык озын, ә җәелеп киткән йөзен каймалап торган башы зур кабак хәтле. Әлеге батман[7] башны алтын парчадан тегелгән, ак торна каурые белән бизәлгән затлы түрбан[8] тагын да кабартып күрсәтә. Ханның булмышын күреп, Мөхәммәдьяр аптырашта калды, аны адәм баласының ачыктан-ачык гариплегенә, иләмсезлегенә карата кызгану-кайгыру хисе биләп алды. Галим хаҗи исә, бернигә дә исе китмәгән кебек, Казан хакименә якынрак килергә ыргыла иде. Ничектер, җаен туры китереп, шагыйрь ханның өзәңгесенә кулы белән кагылды һәм, зур хөрмәт күрсәткән кебек, бармакларын иреннәренә тидереп:

– Хаким, Сезгә түбәнчелек белән бер үтенечемне җиткерергә рөхсәт итегезче? – диде.

Көтелмәгән бу хәлдән Шаһгали атын туктатырга мәҗбүр булды һәм хаҗига өстән генә күз ташлады. Галим хаҗиның тәкъва кыяфәте, бу кеше гади генә түгел, гыйлем ияседер, дип уйларга мөмкинлек бирә иде. Шулай да:

– Сез кем? – дип сөаль бирде яшь хан.

– Мин, бөек әфәндем, данлыклы Сәмәрканд каласының гали мәдрәсәсендәге остаз-мөдәррис булам. Мөридем белән әле генә Казан ханлыгының тәхет хуҗасын күрергә дип килеп төштем. Гүр иясе булган Мөхәммәдәмин ханга – Аллаһның рәхмәте яусын аңа! – элек хезмәт иткән кебек, инде алга таба Сезгә хезмәт күрсәтергә телим.

[5] Чарыс – тиз йөрешле ярсу ат (*тәрҗ. иск.*).
[6] Чапрак – ат өстендәге япма (*тәрҗ. иск.*).
[7] Батман – зур, дәү (*тәрҗ. иск.*).
[8] Түрбан – чалма (*тәрҗ. иск.*).

Шаһгалинең, уйга калганын белдереп, калын иреннәре калтырап куйды:

– Сез элеккеге хуҗа хозурында кем булып тордыгыз соң?

– Хакимем, мин аның яраннары төркеменә кергән сарай шагыйрьләре арасында идем.

Шаһгали артыннан килүче җайдак-түрәгә борылып карады. Өстенә – чит мәмләкәттә тегелгән озын чабулы кафтан, башына биек кеш бүреге кигән теге адәм шагыйрьне эче пошкан кыяфәт белән күздән кичерде. Бу түрә дигәнебез Мәскәү кенәзенең яшь Шаһгалигә ханлык белән бергәләп идарә итәргә дип җибәрелгән урыс илчесе Карпов иде. Кенәз Василийның сүзеннән чыкмый торган Казан ханы бөтен мәсьәләдә дә Карпов белән киңәшеп эш йөртә, хәзер аңа борылып каравы да, нишләргә соң инде моның белән, дип сүзсез соравы иде.

– Холопны куып җибәрегез, – дип ялкау гына мыгырдап алды Мәскәү бояры. – Сезгә моның ише поэтлар нигә кирәк, сезнең двор болай да шулар белән тулы!

Шаһгали күндәм кыяфәт белән атының тезгененә кагылды, шулай да, китеп барган уңайга, карт остазга әйләнеп карады:

– Сезнең кебиләргә калада ханәкалар[9] бар, шуларның берәрсендә тукталырсыз...– диде.

Менә кайгылы төскә кергән хаҗи «кабак» дип йөртелә торган кечкенә, пычрак бер мәйханәдә утыра. Сыңар күзле Ислам ачкан бу йортта бүтән күркәмрәк җиргә кереп ашар өчен түләрлек хәлләре булмаганнар, теш арасына ни дә булса кыстырып чыгарга, дигән өмет белән җыелыша. Базардагы һәм мәйдандагы кабаклар кыздырылган ит, майлы пылау, яңа пешкән ипи һәм өреле шулпа исләре белән тамакны, борынны кытыклый. Сыңар күзле Исламның ашханәсе исә ач карыннарны кызыктыра торган әлеге төшләрдән ерактарак, караңгырак бер почмакка сыенган. Әйтерсең лә ул үзенең фәкыйрьлегеннән ояла һәм мескен кыяфәте белән бай кабакларны үртәүдән курка иде. Аның каравы, бу урын илгизәр дәрвишләр, өйдә сугылган киндер киемле ярлы һөнәрчеләр һәм игенчеләр арасында бик зур танылу алган. Сыңар күзле Ислам кергән кешеләргә «буш», ягъни май төсен күрмәгән сыек ясмык ашы салынган агач кәндиләрне үзе тарата. Шулпага өстәп, көл ябышканлыктан соры төскә кергән өслегенә вак күмер тимгелләре сибелгән чиле-пешле арпа көлчәсе бирелә.

Мөхәммәдьяр, мәдрәсәләрендәге мөридләрнең шуклыкларын бәян итеп, остазның күңелен күтәрмәкче булды. Әмма еракта калган Сәмәрканд турында искә төшерү акынның[10] боеклыгын тагын да көчәйтә генә төште. Табын янынннан алар, тәмам телләрен йоткан төсле, дәшми-тынмый кузгалдылар. Алдан сүз куешкандай, икесе берьюлы атларын йөгәннәреннән тотып, якындагы ханәканы эзләп киттеләр. Тар кәкре җусыкларда[11] сирәк-мирәк очраштыргалаган адәмнәр кайсы якка таба юл тотарга икәнен күрсәттеләр һәм шагыйрьләр ямансу кыяфәтле диварлар янына тиздән барып та җиттеләр. Вакыт җил-яңгыр-карлары шактый каезлаган әлеге бина түбәсе астында ярлы сәяхларны һәм фәкыйрь дәрвишләрне вакытлыча сыену урыны көтеп тора иде. Ишек ачып-ябып торучы чал агай аларны дымланып торган, фәйләсуф карашынча гына «кеше торагы» дип атарга мөмкин булган тар хөҗрәгә озатып куйды. Якын көннәрдә биредә Мөхәммәдьярга да остазы белән яшәп торырга туры киләчәк иде.

Ханәканы күзәтеп-карап торучы кешенең, кырыс кына сорау алу мәрәкәсе оештырганнан соң, шагыйрьләрне тынычлыкта калдырып китүе белән, остаз-мөдәррис хәлдән таеп такта сәке өстенә ауды да:

– И-и! Мөхәммәдьяр, белсәң иде, нинди бөек затның Казанны калдырып киткәнен! Мөхәммәдәмин хан бүтән юк, ил өстендәге кояш та баткан, – дип кенә әйтә алды.

---

[9] Ханәка – суфиханә, дәрвишханә *(тәрҗ. иск.)*.

[10] Акын – халык шагыйре.

[11] Җусык – урам *(тәрҗ. иск.)*.

Галим хаҗи тар ятагында шул арада йокыга да талды. Мескен шагыйрь төн буе саташып, бастырылып чыкты, мөгаен, аның тиз җәрәхәтләнүчән бәгыренең бу кадәр авырту, кимсетелү кичергәне булмагандыр. Мөхәммәдьяр, учакка ут элдереп, остазының уттай янган маңгаендагы юеш чүпрәкләрне алыштыра торды. Таң алдыннан исә кулы каләмгә тартылды. Хәрефләр бер-берсенә үрелеп китте, ак кәгазь өстенә күңел сагышы чайпалып түгелде:

Бервакыт утырам, тутырып хөҗрәм эчен,
Сусаудан өшеп, кайгы касәсеннән эчеп.
Ут алган бәгырь кылларым тартылды,
Мин, хәсрәт тотыгы, шуннан чыгарга талпындым.

Бер ай узгач, Галим хаҗи белән Мөхәммәдьяр Мөхәммәдәмин ханның ахирәт йортына барып баш иделәр дә атларын Казаннан чыгу тарафына юнәлттеләр. Юллары Болгар каласына таба иде. Дәрвишләр сөйләве буенча, Болгарда әле дә шагыйрьләр бер гаилә булып яши, шәһәр башлыгы каләм осталарына карата мәрхәмәтле икән.

Әмма кичкә таба болар, бераз тамак ялгарга, дип, юл буендагы кабакларның берсенә сугылгач, остаз белән аның мөриден базык гәүдәле нугай тумасы килеп тапты. Гыйлем ияләренә баш орып, яугир үзен зур хөрмәткә ия Гәүһәршад ханбикәнең нукеры дип танытты.

– Минем ханым-әфәндем, элек сез бакыйлыкка күчкән хакимнең, – урыны җәннәттә булсын, йа Рабби, – сарай шагыйрьләре арасында булгансыз икән, дип ишеткән.

– Бу хак, – диде аңа җавабында, дулкынлануы тавышына чыккан Галим хаҗи. – Миңа Мөхәммәдәмин ханыбызның рәхим-шәфкатьле канаты астына сыенып яшәү бәхетен татырга насыйп булды.

Нугай ир-егете кабат башын иеп, ихтирамын белдерде:

– Миңа сезне зур дәрәҗәле хуҗабикәм исеменнән аның биләмәсенә чакырып алып кайту бурычы йөкләнде. Ул утар моннан ерак түгел. Хөрмәтлеләребез, минем артымнан барсагыз иде.

Шагыйрьләр гаҗәпләнеп-аптырашып бер-берсенә карашып алдылар, аннары, бер сүз дә алышмыйча, шигырь төргәкләре генә утырып калган буш хурҗиннарын[12] җилкә аша салып, атларына менделәр.

– Ходай безне кызгандымы икән әллә? – дип, Мөхәммәдьярның колагына яшертен генә пышылдап алды хаҗи. – Әгәр мәрхәмәтле солтанбикәгә, шагыйрьләрне канат астына алган затның бертуган сеңлесенә, бөек агасыннан бер тамчы гына нур тамып калса да, без иркен вә тыныч тормышта яшәп китәр идек. Кичке ашка көлчә бирсәләр, җылы почмакта ятагыбыз булса, безгә, бер кайгысыз яраткан эшебез белән шөгыльләнү һәм көн-төн димичә каләм шыгырдатудан кала, тагын ни кирәк булсын?!

Карт остаз башаягы белән хыялга чумды, ә Мөхәммәдьяр инде юлларына үзе каршы чыккандай күренеп торган зиннәтле биләмәне еракан ук кызыксынып күзәтте.

– Мөхтәрәм хаҗи, ничек уйлыйсыз, ханым-әфәнде безнең турыда кайдан белде икән? – дип сорап куйды ул остазыннан.

Мөдәррис, уйланып, кашын җыерды һәм шәкертенә борчылу катыш караш ташлады.

– Әйе шул, Казанда без озак тормадык, уй-фикерләребезне дә теләсә кемгә чәчеп йөрмәдек. Ә, бәлки, ханәканы күзәтеп торучы хөрмәтлебез солтанбикәнең хезмәтчесенә безнең атаклы Болгар каласына китәргә кузгалуыбызны тишкәндер? – Бу фараз хаҗига җан иңдерде, ул мәһабәт төскә кереп чалара башлаган кечтеки генә сакалын сыпырып

[12] Хурҗин – куш капчык *(тәрҗ. иск.)*.

«Мөхәммәдьяр». Рушан Шәмсетдинов рәсеме

куйды. – Менә күрерсең дә торырсың, бу очрашуны изге Хозыр галәйһиссәлам үзе оештыргандыр әле. Аны бит, фәкыйрь юлчыларга ярдәм кулы сузучы, дип, тикмәгә генә әйтмиләр. Ханбикә безне сыендырса, рәхәтләнеп яшәр идек соң!

Гомер бик кыска тоелды сагышлы башыма...
Ә бит ахырын эзлисең – чыгасың иң башына, –

дип, сөенеп, әллә үз шигырен, әллә шәкертенекен кабатлады ул.

Мөхәммәдьяр остазының канатлануына елмаеп кына җавап бирде, яшь шагыйрь алларында тутырып ачылган биек капкадан, үзләрен буй сонып каршы алган капка каравылчысыннан һәм куенында нәфис чатырны, су чәчәкләре атып торучы фонтанны һәм гүзәл аллеяларны саклаган гөлбакчадан күзен ала алмый иде. Ә бакча уртасында, кабырчыгын ачкан әкәм-төкәм кебек, ымсындыргыч, шул ук вакытта гаҗәеп сарайга тартым, ак таштан салынган йорт калкып чыкты. Шагыйрьгә әле беркайчан да мондый муллык, купшылык һәм гүзәллекне күрергә туры килмәгән иде. Ул, бу матурлыкның хуҗасы да мөкәммәл чибәрлеккә ирешкән яшь хатын булырга тиеш, дип уйлады. Аның күзаллавында ханымның ай кебек якты йөзе, җәйраннықыдай[13] канатлы карашы, сәрвигә[14] охшаш төз сыны-гәүдәсе җанланды...

Дәвамы бар

Урысчадан ***Мөдәррис Вәлиев*** *тәрҗемәсе* ■

---

[13] Җәйран – газель *(тәрҗ. иск)*.
[14] Сәрви – кипарис *(тәрҗ. иск)*.

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

Казан ханлыгының язмышы

Булат Хәмидуллин

САФАГӘРӘЙНЕҢ ВАФАТЫ. КУЗЫЙЧАК УГЛАН. БҮЛӘКГӘРӘЙ ҺӘМ ДӘҮЛӘТГӘРӘЙ

...Бик күпләр яратмаган үзсүзле Сафагәрәй хан 1549 елның марты башларында кинәт дөнья куя. Ул вакытта аңа 42 яшь була, дип яза М.Г.Худяков. Әйтелгәнчә, тәхеткә аның ике яшьлек улы Үтәмешгәрәй тәгаенләнә. Дөресрәге, ханлык белән идарә итү бурычы аның анасы Сөембикәгә йөкләнә. Регентша Сөембикәнең төп киңәшчесе һәм ярдәмчесе буларак кырымлыларның гаскәри төркеме җитәкчесе, Сафагәрәй исән чакта ук диван башлыгы итеп тә билгеләнгән Кузыйчак углан (еш-рак «Кошчак углан», «Кушчак углан» рәвешендә языла) танылa. Кайбер тарихчылар раславынча, бу чорда ханлыкның төп таянычы шушы кырымлы яугирләр, дөресрәге, хан сагында торучы гаскәри берәмлек белән Сөембикәнең үз ырудашларыннан торган кечерәк бер төркем генә була да. Зур ыруг башлыклары, Арча, Җөри, Нугай һәм Тау ягы даругалары (административ берәмлекләре) белән идарә иткән, ханлыкның төп гаскәрен туплаган бәкләр хакимияттән Сафагәрәй исән чакта ук читләштерелгән булалар. Төгәлрәге, ыруг башлыкларының берише хан тарафыннан җәзалап үтерелә, икенче – ишлерәк төркеме иленнән чыгып качарга мәҗбүр ителә.

Казан елъязмачысы, Сафагәрәй вафатыннан соң, Казанда җирле бәк-морзалар белән кырымлылар төркеме арасында тәхет биләүчене билгеләү мәсьәләсендә берара тарткалашу да булып алуын күрсәтеп уза. Ханның өлкәнрәк яшьтәге уллары да кала. Аның әсир ителгән кәнизәк хатыннан туган, тәхет варисы буларак танылмаган бер улы 1550 елда, Казан язмышы хәл ителгән көннәрдә, яу кырында һәлак була. Шул хакта М.Г.Худяков хезмәтендә дә мәгълүмат бар. 1560 елда төзелгән «Казан патшалыгы тарихы» китабында ханның үлгәндә, әлеге кәнизәк хатынны да исәпкә кертсәң, 5 хатыны булуы теркәлгән... Ә «Царственная книга»да исә аның бер хатынының 1551 елда Шаһгалигә чыкканлыгы да әйтелә, дип яза М.Г.Худяков. Ханның буйга җитеп килүче ике улы – Бүләкгәрәй белән Мөбәрәкгәрәй аталары үлгәндә Кырымда яшиләр. Кырымлы Сәед Мөхәммәд Ризаның 1832 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күргән «Кырым ханнары тарихы» китабында бу вакыйгага багышланган мәгълүмат барлыгын Шиһабетдин Мәрҗани дә белгән. Аның «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтендә Казан бәк-морзалары тарафыннан Бүләкгәрәйгә чакыру хаты җибәрелгәнлеге хәбәр ителә, Кырым ханы исеменә язылган ул хатта: *«Үтенәбез ки, ханыбызның углы Бүләкгәрәйне безгә хан кылып җибәрсәгез иде»,* – дигән сүзләр була, ләкин, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә, ул монда кайта алмаган. Чакыру хатын илтә киткән беренче төркемне Дон казаклары кулга ала, алар тарафыннан ул хат аннары Мәскәүгә озатыла. Икенче төркем Бакчасарайга барып җитә, хатны Сәхибгәрәй хан кулына тапшыра. Ләкин ханның Бүләкгәрәйне Казанга җибәрәсе килмәгән. Кайбер галимнәр, илле яшькә җитеп килүче Сәхибгәрәй аны Кырым тәхетенә утыртырга

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

Казан Кремлендә Хан сарае комплексының нигезе

өмет иткән була, дип язалар. Качып китмәсен, дип, хан бу яшүсмерне сак астына ала. Бүләкгәрәйнең зинданга Казандагы кырымлылар үтенече белән ябылган булуы да ихтимал. Сәхибгәрәйгә, мөгаен, Кузыйчак углан вәкилләре дә килгәндер, алар «Сафа угланнарын Казанга җибәрмә», дигәнрәк эчтәлекле хәбәр китергәннәрдер, дип фаразларга урын бар.

Шуннан соң Сәхибгәрәй хан икенче бер туганының улын, Истанбулда Сөләйман Кануни карамагында тәрбияләнгән Дәүләтгәрәйне Казан тәхетенә билгеләүне үтенеп, Төркиягә кеше җибәрә. Тарихчылар бу очракта Сәхибгәрәй Дәүләтгәрәйне Кырымга кайтарып, аны юк итүне күздә тоткан, дигән фикерне алга сөрәләр. Чыннан да ул вакыйга зур низаглар, үтерешләр белән тәмамлана. Төркиядә Дәүләтгәрәйне Кырым тәхетен биләргә әзерләгән булалар. Һәм озакламыйча ул Кырымга кайтып, агасы тәхетенә утыра да (1551). Бу вакытта инде Дәүләтгәрәй кешеләре тарафыннан азат ителгән Бүләкгәрәй ханның гомерен өзгән була. Дәүләтгәрәй хан исә аның үзен дә җәзалап үтертә. Нәтиҗәдә, Казан бәк-морзалары үз дигәннәренә ирешә алмыйлар. Ике яшьлек Үтәмешгәрәй чорында ханлык белән җитәкчелек итү элеккечә кырымлылар кулында кала. М.Худяков: «*Правительство сформировалось в прежнем составе – из крымских татар. Во главе его стал оглан Кощак... начальник ханской гвардии при хане Сафе. Правление Сююн-бике было продолжением царствования Сафы. В Казани оказалось правительство, составленное из иностранцев*», – дип яза.

Дәүләтгәрәй чирек гасырдан артыграк Кырым тәхетен биләп (1551-1577), башлыча Төркиягә буйсынып идарә итәчәк. 1552 елның җәендә бу хан, Казанга ярдәм итү максаты белән, Мәскәү кенәзлегенә каршы яуга чыга. Рус елъязмачылары мәгълүматларына нигезләнеп, С.Х.Алишев: «*22 июньдә аның гаскәре Тула каласына туплардан ата башлый. Каланы берникадәр вакыт утка тотканнан соң, җәяүле һөҗүм оештырыла. Әмма уңышка ирешә алмыйча, чигенергә мәҗбүр ителә. Шәһәр сагындагыларга ярдәмгә тагын 15 меңлек гаскәр килүен белгәч, өченче төндә Дәүләтгәрәй,*

обозының бер өлешен ташлап, качарга мәҗбүр булган», – дип икърар итә. Шуннан соң да әлеге ханның Казан белән Әстерханны азат итәргә талпынганлыгы билгеле. Ун-унбиш еллап вакыт үткәч, ул, Сөләйман Кануни вафатыннан соң, Төркиядәге яңа остазлары белән киңәшеп, башта Әстерханны азат итәргә тырышып карый. Ә 1571 елда Мәскәү тарафына зур яу оештырып, аны күпмедер вакыт камалышта тота. Ләкин инде бик соңга калынганлыктан, аңа ярдәмгә килүчеләр булмый...

КАЗАН ВИЛАЯТЕНЕҢ ҖИҢҮЕ

Мәскәүлеләр Сафагәрәйнең вафат булуыннан файдаланып калырга уйлыйлар. Иван IV шул ук җәйдә зур гаскәр тупларга керешә. Кенәзлеккә кергән боярлар июль аенда Мәскәүдә узган җыенда «Казан ханлыгын бөтенләй яулап алу максаты» турындагы карар да кабул итәләр. 1549 елның ахырында 60 меңлек гаскәр Казан тарафына юлга чыга. Ләкин мәскәүлеләрнең бу омтылышы әлегә уңышсыз тәмамлана, Казанны яулап ала алмыйлар. Әлеге яуда катнашкан кенәз А.М.Курбский шул чор вакыйгаларына багышланган хезмәтендә: *«Казанны ала алмадык» («града Казани не взяша»)*, – дип язачак.

Шул яу вакытында Казанны саклауда катнашкан Шәриф Хаҗитарханиның алдарак телгә алынган әсәренә – «Казан вилаятенең җиңүе» сәхифәләренә кабат күз салыйк. Анда Казан шәһәре капкалары сагында торучы сугышчан төркем башлыклары мактап телгә алына. Шулар арасында Сафа тарафыннан күптән түгел җәзалап үтерелгән Булат Ширин[1] бәкнең улы да була. «Казан вилаятенең җиңүе» шигъри дастаныннан өзек: *«Каланың бер капкасын бу вилаять инсаннарының юл күрсәтүчесе булган мәрхүм Булат бәкнең углы Нургали морза төркеме Мамай бәк белән – кадере арткан ир, сугыш азманы һәм данлыклы яугирләрдән Дарий белән Искәндәргә (ягъни Александр Македонскийга) тиң (батыр) егетләр саклар иде. Икенче бер капкада элекке яуларның берсендә һәлак булган Аталык бәк углы Байбулсынның Рөстәм белән Бәһрамнарга[2] тиң гаярь сугышчылары дошман белән орышты. Хан Сарае капкасын сугышчан батырлык остасы, яу мәйданының сафдары, арысланы булган Кузыйчак углан һәм егетләре саклады. Аллаһы аларның батырлыгын арттырсын. Башка капкаларда Котби әл-Актаба оныгы, сәед Ата углы Кол Мөхәммәд сәед, шәкертләрне, руханиларны һәм суфиларны җыеп, сугышка әзер булды. Тагын бер капкада шәһәр бәге, хан казнасының башлыгы, әмирләр нәселеннән булган Бәйбарс (Растов) бәк төркеме дә, арка күрсәтмичә, арысландай көч белән дошманнарга каршы торды. Ике гаскәр берберенә ташланмак өчен үзара кара-каршы килгәннәр иде. Дөрес сүз булса, кяферләрнең гаскәрендә унбер утлы төфәнг (туп) саналды (бер тупчы качып килеп әйткән хәбәр). Ул тупларның һәрбер ядрәсе чама белән Казан ташының бер батманы кадәр бар. Ул ядрәләр тыштан тимер белән кыршаулы, эчендә янучан нефть, күкерт һәм кургашын ядрәчекләр иде. Караңгы төннәрдә шәһәр эченә шулардан атканда җиргә, кешеләр өстенә янар йолдызлар, күк җисемнәре убылып төшкән кебек булыр иде... Бу сугыш шундый булды ки, әйтерсең мәхшәр. Шәһәр өстендә кылыч чыңлаулары туктап тормады, кан елга булып акты. Кала алдындагы мәйданнарда кяферләрнең мәетләрен этләр дә чүпләп бетерерлек түгел иде».*

Кыскасы, ун көннән артыграк дәвам иткән бу сугыш барышында ике як та зур югалтуларга дучар була. Мәскәү гаскәре максатларына ирешмичә кайтып китәргә мәҗбүр ителә. (Мәскәү елъязмачылары бу уңышсызлыкны кыш уртасында яңгыр яуганлыгы, көрәшне дәвам итү мөмкин булмаганлыгы белән аңлаталар.)

[1] Кайбер чыганакларда бу исем Булатширин дип кушып язылган.
[2] Фарсы шагыйре Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасы каһарманнары.

«Ничек килгән ушал мәлгунь, имәстер бу Иван шәһәре.
Шәрифи, китмә бу йирдән, изге өмидегәрең булса...» – дип тәмамлый Хаҗитархани үз әсәрен. Ягъни бу шәһәр мәлгунь Иванныкы имәстер (түгелдер), ди.

М.Г.Худяков Сафагәрәйнең кәнизәк хатыннан туган улының һәм Кырым бәге Чилбәкнең шушы һөҗүм барышында һәлак булуларын икърар итә. С.Х.Алишев исә: *«Казан кирмәненә һөҗүм барышында Шаһгали җитәкләгән гаскәри берәмлек Арча кыры тирәсеннән хәрәкәт иткән, кремль капкаларына һөҗүм итүче мәскәүлеләр төркеме сафында Казан ханлыгының булачак ханы Ядегәр Мөхәммәд тә катнашкан. Ә Иван патша Кабан куле тарафыннан сугыш барышын күзәтеп торган»*, – дип яза.

Һади Атласи да дошманның бу явына каршы башлыча Кузыйчак җитәкчелегендәге кырымлылар белән шәһәр халкының гына каршы торуы хакында хәбәр итә. Шуннан соңгы сугышларда да ханлыкның кырымлылар тарафыннан җитәкчелек ителгән хөкүмәте (диваны) дошман яуларына каршы зур гаскәрләр туплый алмаган.

СӨЕМБИКӘ. КАЗАН ХАНЛЫГЫ – НУГАЙ УРДАСЫ – МӘСКӘҮ КЕНӘЗЛЕГЕ. 1549-1550 ЕЛЛАР КЫШЫНДА КАЗАНГА ҺӨҖҮМ

Сафагәрәй ханның үлем хәбәрен ишеткәч, Йосыф та тол калган кызының язмышы өчен борчыла башлый. Әүвәл ул, кечерәк гаскәр туплап, Казанга улы Юнысны җибәрә. Ләкин шәһәр сагында торган Кузыйчак углан кешеләре аны Казанга кертмиләр. Шуннан соң Йосыф, бераз соңлабрак, мәсьәләне Мәскәү кенәзе белән бергә хәл итәргә ниятли. (Аның шулай соңлабрак – җәй урталарында шундый фикергә килүенең сәбәбе үз урдасындагы вакыйгаларга бәйле булса кирәк. Шул җәйдә Нугай Урдасының соңгы берничә елдагы идарәчесе Шәех Мамай бәк тә вафат була. Бәклек тәхете өчен барган тартыш-низагларда өлкән яшьтәге Йосыфның өстен чыгуын, ил бәге дәрәҗәсенә ия булуын да әйтеп үтү урынлыдыр.) *«Ханның үлемен ишеткәч тә, Йосыф бәк Сөенбикәне Шаһгалигә бирмәкче була»*, – дип яза Һади Атласи. Төрки кавемнәрдә элек-электән килгән гадәт һәм йолалар таләп иткәнчә, Сөембикә инде беренче ире вафат булгач та шул иренең якын туганына бирелергә тиеш була. Фәндә ул йола таләпләре «левират тәртибе» дип атала. Бу очракта тол хатын-кыз язмышын ике ыруг вәкилләре үзара килешеп хәл иткән. Яшьли тол калган хатыннарны иренең якын туганына бирә торган булалар. Казан ханлыгының йөзьеллык тарихында да андый мисаллар берничә. Шул ук Мөхәммәдәмин ханның да, ата-баба йоласы кушканча, үз җиңгәсенә өйләнгәнлеген искә алып уздык. Аның анасы Нурсолтанны да, беренче ире үлгәннән соң, иренең энесенә – булачак хан Ибраһимга биргән булалар. Башка ханнар-солтаннар тарихында да шундый очраклар булгалап торган. Мондый гореф-гадәтләр, әлбәттә инде, хан нәселе вәкилләрен төрле тарафларга таратмау өчен гамәлгә ашырылган. Күренекле әдип Мостай Кәримнең тарихи фактларга нигезләнеп язылган «Ай тотылган төндә» драмасы да шундый йола җирлегендә мәҗбүри рәвештә өйләнешү вакыйгасын да чагылдыра, дип язалар әдәбият белгечләре.

Җангали хан үтерелгәннән соң, Сөембикә дә, кем мине килеп алыр икән, дип, үз бүлмәсендә булачак киявен көтеп утыра алмаган. Иң әүвәл тол ханбикәнең язмышын Касыйм ханлыгы белән Нугай Урдасы идарәчеләре, элекке кодалар хәл итәсе булган. Йола тәртибе кушканча, аның шул вакытта ук хатынлыкка Шаһгалигә биреләчәге күздә тотылган. Ләкин Сөембикәнең шыксыз кыяфәтле Шаһгалигә барасы килмәве, зур көч-куәткә ия булган Нугай Урдасының Касыйм ханлыгы кодаларын үзара килешүгә күндерә алулары сәбәпле генә ул вакытта әлеге никах булмыйча кала. Бу ике тараф вәкилләре, ягъни кодалар Җангалидән туган кыз язмышын киләчәктә Касыйм ханлыгы кодалары карамагына калдыру белән генә килешәләр. Шул рәвешле,

Сөембикә ул чакта үз ирегендә калдырыла. Никадәр гайрәтле, күп кенә мәсьәләләрне үзе генә хәл итсә дә, Сафагәрәй дә Сөембикәгә ата-анасының ризалыгыннан башка өйләнә алмаган, әлбәттә. Йола кушканча, бу очракта ике як ыруг вәкилләренең арадашлык итүе дә кирәк булган. Ул заманда андый эшләр хәзергедәй – тулай торак бүлмәсендә боегып утырган кызны ияртеп чыгып киткән кебек кенә хәл ителмәгән... Шул сәбәпле, Сафагәрәйнең Сөембикәгә өйләнү вакыйгасы, «Казан ханлыгы тарихы» китабында язылганча, 1546 елда булса кирәк.

Сафагәрәйнең үлеменнән соң, Йосыф бәк, әлеге йола тәртипләрен дә исәпкә алып, Сөембикәне Шаһгалигә димләргә карар кыла. Аның уйлавынча, бу вакытта Казан ханлыгы тәхетен биләрдәй кеше фәкать Шаһгали генә була ала. Һәм шундый үтенеч белән ул Мәскәүнең бөек кенәзе Иван IV исеменә хат юллап, үз кешеләрен Мәскәүгә озата. Әлеге хатның эчтәлеге Һ.Атласи хезмәтендә китерелә: «*Минем дустым олуг кенәз Иванга Йосыф морзадан сәлам... Синең атаң Василий кенәз (тәкъдиме белән) Шаһгали ханның якын туганы булган Җангалине Казанга хан итеп алганнар иде. (Шуннан соң) Казанның яхшы кешеләрен безгә җибәреп, безнең белән якынлашуны да үтенгәннәр иде. Тәңренең язмышы буенча, Җангали ханга үзебезнең кызыбыз Сөембикәне биреп, кода булышкан идек...Синең дустың, безнең киявебез булган Җангалине үтерделәр. Минем кызым Сафагәрәйгә бирелде... Ул Казанга 30 кеше белән килгән иде. Соңыннан ул анда әллә ничаклы ялангач Кырым кешеләрен чакырып китерде. Казанлыларны кыса башлады...*».

Шуннан соң, Йосыф бәк Сафагәрәй заманында Казаннан Мәскәүгә качып киткән кайбер бәк һәм морзаларның исемнәрен яза да, Шаһгали белән бергә аларны да Казанны яуларга җибәрү кирәклеген җиткерә: «*Шул һәм башка кешеләрне, чуаш, чирмеш, мукшыларны барысын Шаһгали белән бергә Казан өстенә җибәр. Казан кешеләре, Казан янына барып: «Менә сезнең падишагыз, менә сезнең бәкләрегез!» – дип әйтерләр... Кайсы көндә Шаһгалине Казан өстенә җибәрәсегезне безгә белдерсәгез иде... Шаһгалигә булышлык итәр өчен туганыбызны, алар илә балаларыбыз вә явыбызны, (вә Казанның) сәед, бәкләрен җибәрер идек*». Һәм ул Казаннан Нугай иленә качкан кайбер Казан аксөякләренең исемнәрен атап китә.

Бу хат июль аенда, улы Юныс морзаның Казанга керә алмыйча кайтуыннан соң язылгандыр, мөгаен. Хат эчтәлегенә караганда, ата белән кыз арасында әле элемтә булмаганлыгы чамалана. Байсунгар исемле илче төркеме бу хатны Мәскәүгә 1549 елның июль ахырларында китереп җиткерә. Август башларында исә алар, Мәскәү кенәзенең илчесе Кадыш Кудинов җитәкчелегендәге төркем белән бергә кайтыр юлга чыгалар. Иван IVнең җавап хатында Шаһгали дә катнашачак яуның кайчан оештырылачагы әлегә төгәл генә хәбәр ителмәгән була.

Иван IVкә һәм Мәскәүнең идарәче боярларына Нугай Урдасыннан килгән бу хат бик ошый. Алар Казан тарафына бергәләп яу оештыруны хуплыйлар, ләкин Йосыфның булачак кияве Шаһгалине Казан ханлыгы идарәчесе итәргә теләвен генә өнәп бетермиләр. Дөресрәге, Шаһгалинең Сөембикә белән бергә идарә итүен теләмиләр. Шулай булган очракта Казан белән Нугай Урдасы берләшеп, Мәскәүгә каршы торачак бит! Сөембикә, тәхет тарафына аяк атларга өлгермәстән, яңарак кына бер золымын кылды ич, дип фикер йөртә мәскәүлеләр...

Эш шунда ки, Сафагәрәй вафат булганнан соң ук, 1549 елның март ае ахырларында казанлылар Муром шәһәренә һөҗүм иткән була. Ул яуны, ихтимал, Сафагәрәй оештыра башлаган булгандыр. Мәскәүлеләр исә аны Сөембикә белән аның киңәшчесе һәм диван җитәкчесе Кузыйчак углан оештырган, дип исәплиләр. Шунлыктан, регентша ханбикәгә карата тискәре фикердә булалар. Соңрак Сөембикә ике арадагы

киеренкелекне йомшартырга тырышып карый. *«Шул елның 6 июлендә Сөембикә, Үтәмешгәрәй исеменнән Мәскәүгә кеше җибәреп, Иван илә барышлыкта булырга теләгәнлеген белдерә. Иван IV Үтәмешгәрәй исеменә юлланган хатында: «Безнең белән барышлыкта булырга теләсә, яхшы илчеләрне, Нургали бәкне, угланнарны җибәрсен», – дип кискен җавап бирә,* – дип яза Һ.Атласи, тарихчы В.Н.Татищев мәгълүматларына нигезләнеп. – *Сөенбикә булдыклы хатын иде исә дә, казанлылар аны чынлап танымыйлар, аңа бер хатын диеп кенә карыйлар иде. Казанның бәкләре арасында чын кеше булмаганлыктан, Сөенбикә Кошчак исемле Кырым бәгенә киңәш итеп эш йөртәдер иде»,* – дип өсти.

1549 елның ахырларына таба Мәскәү гаскәрләре инде тупланган, яуга кузгалырга әзер була. Кайчанрак Казан тирәләрендә буласыларын белгертеп Нугай Урдасына да хәбәр җибәрәләрме? Анысы билгесез. Бу вакытта инде Йосыф бәк тә җәйге уй-фикерләреннән кире кайта башлаган була. Шул көздә аңа Казаннан да илчеләр килә. Һ.Атласи, рус елъязмаларына нигезләнеп: *«Изәл-Гура исемле хаҗи җитәкчелегендә 7 кеше иде. Илчеләрнең ни өчен килүләре хат-ярлыкта күрсәтелмәгән булса да, Сөенбикәнең атасыннан ярдәм сораганлыгы аңлашыла иде. Йосыф Казан илчеләрен салкынлык илә каршы ала»,*– дип яза. Бәкнең казанлыларның шул җәйдә улы Юнысны Казанга кертмәүләре, аның кешеләрен күпләп үтерүләре өчен ачуы әле сүрелмәгән була. Бу вакытта инде ул Иван патша тирәсендәгеләрнең Йосыф карт хыялланганча фикер йөртмәүләрен, Казан тәхетендә Шаһгали белән Сөембикәнең парлашып утыруын теләмәүләрен чамалый башлый. Һәрхәлдә, үзе башлап җибәргән эшнең ул теләгәнчәрәк дәвам ителмәгәнлеген тойган булса кирәк. Шуннан соң Йосыф бәк мәскәүлеләр тарафыннан шул елда оештырылачак яуда катнашмау фикеренә килә. 1549 елның көз ахырында Иван IVкә җибәргән хатында ул аңа Казан белән узара килешүләргә барырга кирәклеге турында: *«Минем кызым да, ырудашларым да Казанда. Мин Казанга Сезнең илә килешергә боерырмын, мин сезне килештерермен. Инде синең илә килешергә теләмиләр икән, ул чагында җәй көне син кырдан, мин бу яктан барырмын. Минем өчен син аларны хәзерендә мөхарәбә (дошман) итмә. Әйе, мин сине Казан илә килештерермен. Сезгә түләк түләргә боерырмын. Минем сүземне казанлылар тыңламыйлар икән, үз эшеңне үзең карарсың»,* – дип яза. Һ.Атласи: *«Бу хатның Мәскәүгә ирешүе 1549 елның 11 декабрендә була. Ул чагында Иван IV (гаскәре белән) Мәскәүдән Казан өстенә йөргән иде. Шуңа күрә Йосыф ярлыгының Казан өчен аз булса да файдасы булмады»,* – дип билгеләп уза.

Элек Казаннан нугай җирләренә качкан кайбер аксөякләр дә шул җәйдә Иван IV кешеләре белән үзара хәбәрләшеп торганнар. Һ.Атласиның хезмәтендә мондый юлларны укыйбыз: *«Боерган сәед, Ислеман бәк, Габдулла бахшилар да Иванны... Казан өстенә барырга димлиләр иде. Казан йортын Иванга алып бирергә тырышалар... Иван 1549 елның августында аларга язып, Казан өстенә йөриячәген белдерә...»*

Мәскәү кенәзлеге гаскәренең 1549-1550 еллар кышында Казанга оештырылган зур явының ничек тәгәлләнүе укучыга мәгълүм. Әлеге һөҗүм Казан кирмәне капкалары сагында торган батыр сугышчылар тарафыннан кире кагыла. Мәскәүлеләр, Казан капкаларын ватып-җимереп керә алмауларын «февральдә яуган яңгыр»га сылтап, кайтып китәргә мәҗбүр булалар.

«Бу ел Сөенбикә өчен иң кайгылы ел булды. Иренең үлүе, баласының яшьлеге, ата вә туганнарының, руслар илә бер булып, Казан өстенә йөрергә теләүләре аны чиктән тыш борчыды... Йосыф Сөенбикәне соңыннан кызганды исә дә, аның кызгануы Сөенбикәнең канлы яшьләрен туктатырга ярдәм итмәде», – дип яза Һ.Атласи.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

ЭЧКЕН ТАТАРЛАРЫ

Рафаил Исакаев

ҖӘЙЛӘҮГӘ ЧЫГУ

Иртәгә җәйләүгә чыгасы. Кырда яшәү өчен кирәкле бөтен әйберләр арбаларга кичтән төяп куелды. Иртән гаиләнең барлык әгъзалары да, китүчеләргә ярдәм итү һәм хәерле юл теләп калу өчен, ишегалдына чыкты. Атлар инде җигелгән, җәйләүдә көтәсе бияләр һәм терлек-туарны урамга куалар. Карт бабай һәм аның гаиләсе юлга чыгар алдыннан утырып алырга булалар. Хуҗа, Аллаһыдан рәхим-шәфкать сорап, догалар укый. Карт бабай, алга узып, яраткан аты җигелгән арбага утыра да кул болгый һәм бөтенесе дә юлга кузгалалар.

Гадәттәгечә, барлык ирләр, хәтта 7-8 яшьлек малайлар, алар белән бергә, киленнәрнең берсе китә. Әлеге хатын-кыз җәйләүдәге хуҗалык эшләрен алып барачак: ашарга пешерәчәк, сыерлар һәм бияләрне савачак һәм ирләргә кыр эшләрендә булышачак. Авылда картлар һәм кечкенә балалар, хуҗалык эшләрен, өйдәге терлек-туарны, кош-кортны карарга икенче килен һәм кызлар кала. Җәйләүгә куылмаган терлекне йөртер өчен, авыллар янында киртә белән уратып алынган зур биләмәләр – көтүлекләр калдырылган.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

Ә безнең кәрван акрын гына җәйләүгә юл тота. Терлек-туар, үлән чемченеп, алга бара. Малайлар көтүгә таралырга ирек бирмиләр. Һәм менә кичкә кәрван тиешле урынга барып җитә. Урман кырыенда – күл буенда карт бабайның җәйләүдә яшәү өчен уңайлы булган торагы – аскы өлеше җиргә кертеп салынган зур йорты бар. Барысы да кояшка, җылы һавага сөенәләр. Малайлар үзләрен сәйранга чыккандай хис итә: салкын озын кыштан соң ирек, иркенлек. Ә өлкәннәрне көзге чәчүлекләрнең кышны өшемичә, черемичә имин үткәрүе – яшәреп-яшелләнеп килүе, көтүлектәге үлән үсеп җиткәнче ашатырга дип әзерләнгән печән һәм саламның, утынның саклануы шатландыра.

Балачактан башлап һәр елны җәйләүгә чыкса да, карт бабай да дулкынлана, күченүгә сөенә.

Карт бабамның гаиләсе 15 дисәтинә җирне чәчкән, гомуми мәйданы исә 45 дисәтинә булган (чәчкәненнән тыш, тагын 15 дисәтинәсе парга, ягъни ял иттереп ел аралаш чәчәргә һәм 15 дисәтинә залогка – «озаграк вакытлы ялга» калдырылган).

Печәнлекләр исә уртак милек саналган һәм аларны ел саен гаиләдәге ирләр санына карап бүлгәннәр.

Карт бабам гаиләсендә терлек-туардан 17 ат (шуларның 8е – эш аты, савыла торган 3 бия, 5есе – 3 яшьлек ат һәм 1тай); мөгезле эре терлек: савыла торган сыерлар – 14 баш, башмак таналар һәм үгезләр – 16, сарыклар – 40 баш.

Язгы чәчү башланганчы, карт бабам ирләргә эш коралларын тагын бер кат карап-тикшереп чыгарга, эш атларын, күп көч килгәнгә, солы белән яхшылап тукландырырга кушкан. (Ябык, көчсез ат – игенченең ярдәмчесе түгел).

Язгы чәчү гадәттә 15 апрельдә башланган, ләкин һава торышына карап, май башына калган вакытлар да булган.

«Элекке сынамышлар буенча быел чәчү иртә булганга, 15-16 апрельдә башларбыз», – ди карт бабай. Чәчү җирне бер көн алда тырмалаудан башлана.

Һәм менә карт бабам ирләрне иртә таңнан уята. Килен инде иртәнге ашка мул табын әзерләп куйган. Ашагач, ирләр үз эшләренә керешәләр. Карт бабай аларга кырга чыгарга күрсәтмәләр бирә. Ирләр атларны тырмага җигәләр. 8-10 яшьлек малайларны – оныкларны карт бабай кайда һәм ничек тырмаларга өйрәтә. Менә малайлар инде ат өстендә утыралар. Карт бабам, дога укып, беренче атны басу кырыена китерә һәм, фатиха биреп, малайның ботыннан кагып куя. Ике оныг, бер-бер артлы, атларын сөрелгән җир буйлап куа башлыйлар. Ирләр ул арада көздән сөрелми калган җирне сукалый башлыйлар. Һәр сукага ике ат җигелә, аларны, арган саен, башка атларга алыштыралар. Кыскача әйткәндә, эш кайный башлый.

Эчкеннәрдә язгы чәчү малайлар һәм кызларны крестьян хезмәтенә өйрәтү өчен иң кулай вакыт санала. Һәм менә безнекеләргә дә тырмалаганда атлар белән идарә итүне ышанып тапшыралар.

Икенче көнне инде тырмалаган җиргә чәчәргә дә мөмкин. Эчкеннәр гореф-гадәте буенча, язгы чәчүнең беренче көнендә «орлык чыгару» йоласы үтәлә. Аның беренче үзенчәлеге булып, иртән эшне башлар алдыннан кырда ашау, орлык белән бергә йомырка («орлык күкәе») алып чыгу тора. Һәм менә безнекеләр дә бу йоланы үтиләр – кырда ашыйлар. Тубал тулы, орлык өстенә унлап йомырка куелган.

Чәчүне һәрвакыт гаиләдәге иң өлкән ир башлый. Менә карт бабам, дога укып, тубал каешын муенына аса да басуга керә һәм учына орлык белән бер йомырка алып, җиргә сибә. Борынгы чорда, җир рухларын ашатсаң, яңа уңыш алганда иген бөртекләре күкәй чаклы булыр, дигән ырым яшәгән, күрәсең. Карт бабам артыннан уллары, шул исәптән бабам Габидулла да китә. Чәчүчеләр тырма эзенә аркылы барып чәчәләр. Бу иген бөртегенә тырма эзенә төшү мөмкинлеге бирә.

Эчкеннәр бөртекле культуралардан беренче итеп солы чәчкәннәр, чөнки ул салкыннан курыкмый һәм дымлы җирне ярата.

Чәчүлек мәйданының бүленеше мондый: беренче урында 7 дисәтинә сабан бодае, икенчедә – солы – 7 дисәтинә, ул – атларның төп азыгы.

Безнең чәчүчеләр караңгы төшкәнче эшлиләр, кичен, арып-талып һәм канәгать калып, ашарга кайталар. Малайлар, билгеле, көне буе атка атланып йөреп бик талчыкканнар, әмма сер бирәселәре килми. Өлкәннәр атлар белән идарә итүне ышанып тапшырганга, аларның күңелен горурлык хисе били. Йөзләре тузанга батып, негрга охшап калганга, алар бер-берсенә карап көләләр.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, чәчүдән соң, орлыкны җиргә күмдерер өчен, җирне аркылыга тырмалыйлар. Икенче көнне таңнан торып, салкыннан бөрешеп, атларны яңадан җигәләр һәм солы чәчеп бетергәнче һәр көнне шулай.

ЧӘЧҮ ТӘМАМЛАНУ

Пәнҗешәмбе көннәрендә, мунчада юынып, мөселманнарның бәйрәм – җомга көнендә ял итәр өчен, авылга кайталар. Ә карт бабамның кече улы – Нигъмәтулла бизәнгән кәләше – гүзәл Сабира янына бара. Әти-әниләре инде быел көзен, урып-җыю тәмамлангач, туй үткәрергә килешкәннәр. Шимбә көнне яңадан кырга чыгалар һәм бу чәчү тәмамланганчы – быел 15 майга кадәр дәвам итә. Чәчүне тәмамлап, безнекеләр, башка гаиләләр кебек үк, авылга ял итәргә кайталар. Күптәннән килгән гадәт буенча, авылда чәчүчеләрне каршы алырга әзерләнәләр. Бөтенесе дә, күлдән су алып, мичкәләрне һәм башка савытларны тутыралар, мунча ягалар, камыр ашлары пешерәләр.

Кыр эшләреннән кайтучыларның арбаларынерактан ук күреп алып, алар каршына сулы чиләкләр күтәргән хатын-кызлар һәм кызлар чыга. Чыр-чу килеп, чәчүчеләрне су белән коендыру башлана. Күпләрнең киемнәре, өйләренә кайтып җиткәнче, лычма су була. Әмма беркем дә үпкәләми, чөнки бу йола гасырлар буе килә һәм аның асылы шифалы җылы яңгырлар, мул уңыш теләүгә кайтып кала.

Кич, мунча кергәч һәм ашагач, басу капкасы артындагы яланга чыгып, төнгә хәтле



күңел ачалар. Нигъмәтулла бедән Сабира – яшь кияү белән кәләш тә, билгеле инде, шунда булалар.

Менә июнь ае җитә, чәчелгән кырлар, яшелләнеп, уҗым тишелеп чыга. Ул – яхшы уңыш алуга, хәзер мул яңгырлар кирәк. Бу чорда, яхшы уңыш алуны һәм терлек-туарның артымын теләп, җәйге корбан чалу йоласы үтәлә. Корбанлык (гадәттә ул сарык, сыер яки үгез була) өчен акчаны бөтен өчкүллеләрдән җыеп, үгез сатып алалар. Әлеге йоланы, зират янында алдан намаз укып, күл буенда үтиләр.

Корбан итен берничә казанда пешерәләр. Ашка салу яки шулпада ботка пешерү өчен, тагын акча җыялар. Корбан ашын бөтен теләүчеләр авыз итә. Итнең сөякләрен: «Җир рухы, безнең белән бергә аша», – дип әйтеп, җиргә күмәләр. Шуннан соң, Аллаһтан басуларга мул яңгырлар җибәрүне сорап, бер-берсенә су сибәләр.

Хәзер инде өчкүллеләргә теләкләренең үтәлүен көтәргә генә кала. Хәер, куелган хезмәттән ләззәт алып утырырга вакыт калмый – парга калдырылган кырларда чүп үләннәре котырып үсеп килә. Ашлама – черегән тирес кертергә кирәк. Башка өчкүллеләр кебек үк, карт бабам гаиләсе дә кырга чыгарга җыена. Парга калдырылган җирләрдә эш күп, аннары инде печән өсте дә җитәчәк. (Парга калдырылган җиргә ашлама кертеп, җәй буена берничә мәртәбә сукалыйлар.)

Ирләр тиресне арбаларга кичтән үк төяп, иртән кырга кузгалалар. Барып җиткәч, ирләрнең һәм яшүсмерләрнең бер өлеше кырга тирес тарату белән шөгыльләнә башлый, ә ике олы улы җир сукаларга керешә. Йомшак туфракны (пар җирен) эшкәртү өчен – сука, каты җирне сукалау өчен исә сабан кулланыла.

Ирләр җир сөргән арада, малайлар көтү көтәләр хатын-кызларга йорт эшләрендә булышалар, су, утын китерәләр. Алар ук кыр суганы, кузгалак, балтырган һәм ашарга яраклы башка үләннәр җыялар – болар төрле ашлар пешергәндә кулланыла.

Җирнең бер өлеше сукалануга, малайлар аны тырмалый башлыйлар. Тырмалар агачтан, ә тешләре алдан ук очланган ботаклардан ясала. Кантарлырак җирне тырмалаганда, өстенә агач бүкәннәре куеп, тырмаларны авырайталар.

Пар җирләрендәге эшләр тәмамлануга, июль ае – печән өсте җитә.

Ахыры киләсе санда ■

ТАТАР БАЙЛАРЫ

ГАНИ БАЙ

Борһан Шәрәф

XIX йөз ахыры-XX йөз башында халкыбызның иҗтимагый-мәдәни тормышындагы тирән үзгәрешләр, милли мәгариф өлкәсендәге җитди яңалыклар, милли матбагачылык, газета-журналлар һәм әдәбият-сәнгать үсешен милли җанлы татар эшкуарлары эшчәнлегеннән башка күз алдына китереп булмый. Татар халкының киләчәк тормышын кайгыртып йөз меңнәрчә акчаларын милләт файдасына сарыф иткән бу ак байларның эшчәнлеге дистә еллар буе бары тик тискәре яктан гына яктыртылды. Әмма узган гасырның туксанынчы елларыннан башлап бу үтә берьяклы караш-бәяләмә хаклы рәвештә тарих чүплегенә атылды. Бертуган Рәмиевләр, Акчуриннар, Агафуровлар, Галикәевләр һәм башка бик күп фидакарь эшкуарлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә XIX йөз ахыры-XX йөз башында татар халкы милли ренессанс дәверен кичерде, милләт булып формалашты. Бу катлаулы һәм күпкырлы процесста бертуган Хөсәеновлар да җуелмаслык эз калдырган.

Атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсеннән тыш, йөзләгән мәчет-мәдрәсә салдырган, меңләгән шәкерт укыткан, мөгаллим-мөгаллимәләр хәзерләгән һәм, гомумән, татар-мөселман мәгариф системасын үзгәртеп коруга бәяләп бетермәслек өлеш керткән, фәкыйрь-фөкарага ярдәм иткән фидакарь иганәче Хөсәеновларның исем-гамәлләре онытылырга тиеш түгел.

Журналның бу санынннан башлап ***Габделгани Хөсәенов (1839-1902)*** *турында 1913 елда Борһан Шәрәф төзеп бастырган җыентыктан (авторлары төрле) кайбер өзекләр бирелә башлый һәм алар бу атаклы шәхеснең тормышын, эшчәнлеген күз алдына китерергә ярдәм итәр.*

Җәүдәт Миңнуллин, *тарих фәннәре кандидаты*

ГАБДЕЛГАНИ ХӨСӘЕНОВНЫҢ ЯШЬЛЕК ВАКЫТЫ

Мәрхүмнең үз кәгазьләре эчендә табылган бер шәҗәрәгә күрә, аның нәсәбе шөйлә: Габделгани бине Мөхәммәтгали бине Хөсәен бине Гобәйдулла бине Габдрахман бине Иманколдыр. Ата-бабаларының ватаны искедән Каргалы касабәсе *(авылы)* булса да, Габделгани Орски өязенең Юлык карьясында, ана ягыннан бабасы булган Гатиятулла Әдһәмов йортында туган. Анасы – мәзкүр Гатиятулланың кызы Тәкыядер.

Мөхәммәтгали илә Тәкыя даимән бергә тормаганнар, бик сирәк күрешкәннәр. Аларның вакыйгасы шөйлә булган: Каргалыда яхшы дәүләтле Хөсәен бабайның үз янындагы угылы Мөхәммәтгали сәүдә илә төрле якларга чыгып йөргән. Ул бервакыт


غنی بای

ترجمهٔ حالی، مکتوبلری و آنک حقنده خاطره‌لر.

ناشری: شیرین‌بانو حسینوا هم بالالری.

اورنبورغده «وقت» مطبعه‌سی.

ТИПОГРАФІЯ ГАЗ. „ВАКІТЪ" ВЪ ОРЕНБУРГѢ.

1913.

Гани бай: тәрҗемәи хәле, мәктүбләре вә аның хакында хатирәләр / Тәхрир итүче – Борһан Шәрәф, нашире – Ширинбану Хөсәенова һәм балалары. – Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1913.

Олуг агалары Мөхәммәтбакый, үзенә аерым эш итеп, болардан аерылган. Габдрахман исә, яшь булып, сәүдә башлаганда катышмай калган. Калган өч борадәр – Әхмәт, Габделгани вә Мәхмүтнең суммалары бергә йөргән. Фирмалары «Әхмәт Хөсәенов һәм борадәрләре» исемендә йөртелгән. Бер ун ел кадәр сәүдә итеп сумма ясагач, эшнең мәйданын киңәйткәннәр, Төркестан әтрафына бик әһәмият биргәннәр.

(1838 елда) Юлык карьясына *(авылына)* вак сәүдә илә бардыгында, яшь хатын алырга дәртләнеп, шунда Гатиятулла агайның Тәкыя исемле кызына өйләнгән. Бу вакытта Мөхәммәтгали – 34тә, Тәкыя 15-16 яшьләрдә булганнар. Мөхәммәтгали аның янында Юлыкта бер тәүлек кенә калган да, кайтып киткән. Соңра йиде ел эчендә Юлыкка һичбер тапкыр килмәгән, яшь хатыны илә күрешмәгән. Тәкыя исә, никахланудан мәгълүм мөддәт*(вакыт)*үткәч, бер угыл тапкан вә шуны Габделгани атаганнар. Тәкыя аны Гатиятулла бабай өендә тәрбияләп үстергән. Йиде елдан соң, Мөхәммәтгали йәнә Юлыкка барып, Тәкыяне Каргалыга алып кайткан. Каргалыга кайткач, ул йәнә бер угыл табып (Габдрахман исемендә) шул баладан соң биш-алты ай гына торып, вафат булган. Риваятьләргә караганда, кайгы-хәсрәт аның гакылына бераз зарар итеп, ул үләр алдында моның галәмәтләре бик еш беленерлек хәлгә килгән. Мәрхүмә Каргалыда дәфен ителмештер *(җирләнгән)* (1846 елда). Ходаның рәхмәтендә булгай иде.

Габделгани илә Габдрахман анадан ятим калгач, боларны тәрбия итү өчен Ямманболак авылында (Оренбург өязенең Кыпчак вулысында) Гөлбәгыйдә исемле бер карчыкка тапшырганнар (бу эш 1846-1847 елларда [булган]). Габделгани шул Ямманболак авылының мәдрәсәсенә сабакка йөргән. Анда ничә ел укыганы мәгълүм түгел. Шулкадәресе мәгълүм ки, Габделгани укуны тәмам итеп Каргалыга кайтып киткәндә, Габдрахман инде мәдрәсәгә йөри торган булып, аннан йәнә бер ел калып укыган. Аннан соң ул да Каргалыга кайткан. Габделгани мәктәпкә керерлек вакытта Габдрахман бер генә яшьтә иде. Боларның икесенең дә мәктәпкә керүләрен 7 йә 8 яшьтә хисаплаганда, Габделгани мәдрәсәгә 7-8 ел чамасы йөргән була. Әгәр дә аны мәктәпкә салу соңрак булса, уку вакыты моннан кимрәк булырга да мөмкин. Нә исә, нәтиҗәсе ба-

Атасы Мөхәммәтгалинең үз кәефе өчен генә яши торган вә киләчәк өчен кайгысыз булуы, Хөсәен бабай калдырган малны бетерүе, балаларының аңа игътимад итүләренә имкян (мөмкинлек) калдырмаган. Шуңа күрә балаларга үз бәхетләрен үзләренә эзләргә калган.

рыбер. Ул замандагы гадәт буенча, Габделгани Яманболак мәдрәсәсеннән күп файдаланмаенча чыккан. Кул куярлык та язу өйрәнә алмаган. Шулай булса да, Габделгани Яманболакка шөкрана итүдә косурлык *(кимчелек)* кылмаган. Баегач, анда 5-6 мең сумга төшереп, таштан мәктәп бинасы һәм мәктәп өчен варидәт*(табыш)* килергә зур амбар салдырып, вәкыф иткән. Яманболак мулласы да үзенең ниндәен мөстәкъбәлле *(киләчәге өметле)* кешене тәрбиядә иһмаль иткәнлеген *(әһәмият бирмәгәнлеген)* соңыннан да белә алмаенча вафат булгандыр. Алла мәгъфирәт кылсын *(гафу итсен)*.

Каргалыга кайткач, Габделгани үзенә үги ана тиешле Хәмидә тәрбиясендә булган. Хәмидә әби Мөхәммәтгали бабайның өлкән хатыны булып, Әхмәт бай вә Мәхмүт байларның туган аналарыдыр. Риваятьләргә караганда, Хәмидә әби Габделгани вә Габдрахманнарга бер дә үгилек күрсәтмәгән, аларны үз балалары кеби караган. Аналарының көндәшлеге күп тимәгәч, бу балаларның яшь вакыттагы җәфалары күренмәгәч, үгилекнең тәәсире аз булачагы табигыйдер. Габделгани дә, үз анасыннан яшьләй калганга күрә, Хәмидә әбине үз анасы кеби ярата вә хөрмәт кыла торган булган. Ул һаман да Хәмидә әбине сагынып вә яратып сөйлидер иде.

Габделгани нарасый чакта һәм аңы ачылган вакытта атадан аерым торып, боек күңелле вә ялгыз калдырылган ана кулында үскәч, аннан соң ул анадан да ятим калгач, читләр мәрхәмәтендә торган үксез бала шикелле басынкы вә юаш табигатьле булган. Бик боек үскән. Ләкин үсеп, егет булганчы (14-15 яшьләргәчә) үгиләрдән аерым, читтә, бинаән галәйһи *(шуңа күрә)* һәртөрле косурлардан *(кимчелекләрдән)* азат яшәве дә аңа файда иткән. Бу сәбәпле, аның табигатендә булган кәмаләтләр *(камил сыйфатлар)* вә әхлак бозылмаенча кала алганнар. Шуның илә бәрабәр, дөньяда һичкемнән шәфкать вә химая *(яклау)* көтә алмаячагын да белеп, бөтен хәятендә үзенә генә игътимад кылып *(ышанып)* яшәргә тиешлеген әхвәл аңа үзе аңлатырлык булган. Алладан башка һичкемгә ышанычы юк идеген ул һәрдаим сизеп вә анык белеп торырлык хәлдә булган. Атасы Мөхәммәтгалинең үз кәефе өчен генә яши торган вә киләчәк өчен кайгысыз булуы, Хөсәен бабай калдырган малны бетерүе, балаларының аңа игътимад итүләренә имкян *(мөмкинлек)* калдырмаган. Шуңа күрә балаларга үз бәхетләрен үзләренә эзләргә калган. Ул балалар һәркаюсы үз көчләре илә генә дөнья көтә алачакларына һәм һичбер арка таянычлары юк икәнлеккә ышанып үскәннәр. Сәфаһәтнең *(кирәкмәскә мал сарыф итү)* вә исрафның зыяннарын күреп белергә дә аларга һәрвакыт күз алдында гыйбрәт булып торган. Мөхәммәтгали үзенең балаларын дөньяга чыкмаган хәлләрендә калдырып, 1858 елда, 54 яшендә Иләк каласында[1] вафат булган. Хәерле вә тәүфыйклы балалары үзләре анарга даимән догачы булып, меңнәр, ун меңнәрчә кешеләрнең дә Гали бабайга хәер-дога кылуларына сәбәпче булганнар. Хәерле балалар калдырган ата-ана – бәхетле җаннардандыр. Мәрхүмнең җаны рәхәттә булсын.

Мөхәммәтгалидән Мөхәммәтбакый, Әхмәт, Габделгани, Мәхмүт, Габдрахман исемнәрендә биш угыл һәм Бибисара исемендә бер кыз калганнар. Угылларыннан өчесе – Әхмәт бай, Гани бай, Мәхмүт бай исемнәрендә олуг шөһрәт казанмышлардыр.

---

[1] Иләк каласында – хәзерге Оренбург өлкәсендәге Тозтүбә (Соль-Илецк) шәһәре.

БОРАДӘРАН ХӨСӘЕНОВЛАРНЫҢ МАЛ ТАБУЛАРЫ

Мөхәммәтгали бабайның олуг җәмәгате Хәмидә әби бик гайрәтле, йорт тотар хатын булып, иренең вафатыннан соң йортны таркатмай, үзенең вә көндәшенең балаларын бергә җыеп торган. Балалар бергә хезмәт итүләре сәбәпле, кәсепләре дә бәрәкәтле булган. Мөхәммәтгалинең угыллары – агай-эне бергә Каргалыда торып (хәзердә Хәбибулла Яруллин милкендә булган йортта) вак-төяк нәрсәләр илә сәүдә итә башлаганнар. Вак сәүдә илә авыл арасына вә кыргыз[2] эченә чыгып йөргәннәр. Шәһәрдән сатып алган товарны казакъ арасында йөртеп, анда җон, тире һәм аяклы мал илә алыштырганнар. Бу малларны да шәһәргә китереп сатканнар. Эшләре зурая башлагач, шәһәргә йөрүләре еш булганга күрә, Оренбургта бер даими фатир алганнар. Бу фатир соңрак кантур вә ысклад урынына хезмәт иткән. Шул вакытлардук Мәкәрҗәгә үзләре мал илтә башлаганнар. Олуг агалары Мөхәммәтбакый, үзенә аерым эш итеп, болардан аерылган. Габдрахман исә, яшь булып, сәүдә башлаганда катышмай калган. Калган өч борадәр – Әхмәт, Габделгани вә Мәхмүтнең суммалары бергә йөргән. Фирмалары «Әхмәт Хөсәенов һәм борадәрләре» исемендә йөртелгән. Бер ун ел кадәр сәүдә итеп сумма ясагач, эшнең мәйданын киңәйткәннәр, Төркестан әтрафына бик әһәмият биргәннәр. Өч борадәрдән кайсы булса да берсе ул якка ел саен барып, мал китерә торган булган. Ул якта базар яхшы күренгәч, 1869 елда борадәрләрдән Габделгани бөтенләй Казалы шәһәрендә[3] тора башлаган. Мәхмүт исә, һәр елны кышларны Төркестанда булып, җәй Оренбурга кайтып, тирә-якка йөргән. 1876 елдан соң гына ул Төркестанга бармый башлаган, даимән диярлек Оренбургта торган. Габделгани Төркестан ягының базарын Хөсәеновлар кулына каратырга керешкән. Тырышуы бушка китмәгән. Аталарыннан соң 15 ел сәүдә иткәч (1873тә) сәрмаяларын *(капиталны)* 80 мең сумга йиткергәннәр. Моннан эшләренең муаффәкыять илә *(уңгышлы)* барганлыгы һәм яхшы юлга салынганлыгы күренә.

Асыл бәхетләренең ачылуы вә фәүкылгадә *(гадәттән тыш)* күтәрелеп китүләре Оренбурга күчүләреннән соңдыр. Алар 1873 елда Каргалыдан бөтенләй күчеп, Оренбургта тора башлаганнар. Шуннан 5 ел үткәч, суммалары 300 меңгә йиткән. Шул вакытта (1878 елда) Диев мәйданындагы йортны 28 мең сумга сатып алганнар. Монда тире-яры вә Азия малы һәм куй илә сәүдәне зурайтканнар. Бу йорт Оренбургта Азия малының иң зур ыскладларыннан булган. Хәтта ки, шәһәр эчендә тире-яры, җонҗабага асрамау хакында Шәһәр Думасы мәҗбүри бер карарнамә чыгарган вакытта, бу йортны, йәнә берничә йорт илә бергә, гомуми хөкемгә кертмәенчә, истисна кылып *(аерып алып)* калдырмыштыр. Бу аерымлык Хөсәеновларның эшләренә ярдәм итеп, аларны бу базарга манапулия ясату дәрәҗәсенә китермештер[4]. Тиречелек өчен махсус имтиязлы*(өстенлекле)* булган бу йорт хәзерге көндә мәрхүм Мәхмүт бай варислары милкендәдер.

Хөсәеновлардан берсенең Төркестан вилаятендә, ягьни тире-яры, җон-җабаганың күп вә арзан йирендә торуы, икенчесенең Мәкәрҗә, Казан вә Мәскәүгә йөреп, ул базарлардан тиешенчә файдалануы, өченчесенең, Оренбургта торып, анда һаман үз күзләре булуы һәм Төркестан илә Русия арасында васитачылыкны*(арадашчылыкны)* төзек саклавы, Оренбург сәүдәгәрләренең Хөсәеновларга рәкабәт *(конкуренция)* итә

---

[2] Кыргыз – биредә казакълар күздә тотыла.

[3] Хәзерге вакытта Казакъстанның Кызыл Урда өлкәсендәге Казалинск шәһәре.

[4] 1870 елларда Орск шәһәреннән 50 чакрымлап төньяктарак аяклы мал симертү өчен зур биләмәле җир алына. Аның идарәчесе итеп Мирхәйдәр Фәйзинең әтисе билгеләнә, шул рәвешле Күкшел авылы нигезләнә. Ә XX йөз башында Каргалы читендә бу байларның консерва эшләү заводы ачыла. «Куй ите», «Елкы ите» дип тамгаланган консервалар патша армиясе өчен дә хәстәрләнә башлый.

алуларына имкян *(мөмкинлек)* калдырмаган. Габделгани Казалыда җон, тире, киез, куй, җәнлекне иң арзан чагында җыеп, монда йибәреп торган. Әхмәт исә, аларны кыйммәтрәк урында вә кыйммәтрәк вакытта сатуны кайгырткан һәм Төркестан малы бәрабәренә Русиядән фабрик маллары, шара-бара йибәреп торган. Ике арада даими йөреп торган кәрван бер тарафтан чи вә эшләнмәгән маллар, икенче тарафтан фабрик вә завод маллары ташып торган. Казалыда кибет вә Русия малларының зур ысклады тәэсис ителгән*(төзелгән)*.

Төркестан маллары	**Казалыда вә әтрафында**	**Оренбургта**
Куй тиресе	45-60 тиен	90 тиен
Куй тиресе (соңрак елларда)	60-65 тиен	1 сум 20 - 1 сум 50 тиен
Эчәге	5 тиен	25-30 тиен
Сыер тиресе (поты)	Чи көе 2 сум 80 тиен - 3 сум	Киптереп 9 сум - 9 сум 50 тиен
Җабага (поты)	1 сум 50 тиен - 2 сум	3 сум 50 тиен - 4 сум
Төя җоны	3 сум	5 сум
Куй	3 сум 50 тиен	6 сум - 7 сум 50 тиен
Төя	28-30 сум	Суела, мае илә тиресеннән хакы чыга. Йөк китерүе, ите бушка кала.

Ул вакытта Казалы шөгъбәсендә хезмәт иткән Камалетдин әфәнде Сәйфелмөлекевнең хатирәсенә күрә, 1870-[18]80 еллар эчендә Казалы илә Оренбург базарлары арасында аерма шушы рәвешчә булган:

Русия маллары	**Оренбургта**	**Казалыда**
Дегет (поты)	50-60 тиен	5-6 сум
Керосин (поты)	1 сум	4-6 сум
Тимер (поты)	2 сум 20 тиен	4 сум
Чуен (поты)	1 сум 90 - 2 сум 10 тиен	5-6 сум
Мунча себеркесе (пары)	3 тиен	15 тиен
Пыяла (чирек ящик)	7 сум	16 сум
Крупчатка богдай оны (5 поты)	8-9 сум	15-16 сум

1878 елларда Тукмак шәһәрендә богдайның потын 18 тиенгә алып, 30 мең пот чамасы богдай җыелды, шуны кәрван илә төрле шәһәрләргә, хәтта Троицки каласынача йибәреп, поты 2 сум 50 - 2 сум 80 тиенгәчә сатылды.

Мануфактур малларына сумга 30-50 тиен, галантерийный, мускательный *(буяу,*

җилем) нәрсәләргә аннан артыграк табыш куеп сатыла иде. Казалы илә Оренбург арасында йөк йөртү (төя илә) һаман бер чама – потка 50-55 тиеннәр төшә иде. Нәрсәнең юлда югалуы бөтенләй булмаган диярлек.

Борадәран Хөсәеновларның зур баюларына сәбәп – аларның Төркестаннан Оренбуркга, Оренбургтан – Казан, Мәкәрҗә вә Мәскәүгә, хәтта Берлинга кадәр урыннарда үзләре йөреп сәүдә итүләре вә бу базарлар арасындагы аермалардан чынлап файдалануларыдыр.

Ул заманда Төркестан вилаятләрендә, хосусан казакъ арасында, акча булмаганга, сәүдәнең күбрәк кыйсеме алмашу (эшләнмәгән малга эшләнгән мал бирү) илә була, шуңа күрә һәрбер сәүдәдә ике кат – алган нәрсәдә дә, биргән нәрсәдә дә файда ителә иде. Оренбургта үз кантуралары вә кешеләре булгач, Казалыда вә әтрафында нәрсә алуда вә нәрсә сатуда Хөсәеновлар илә рәкабәт *(көндәшлек)* итү башка сәүдәгәрләргә читен булган, соңра бәгъзән бөтенләй мөмкин булмаган. Урта Азия тимер юлы ачылгач, Русия вә Кавказ сәүдәгәрләре Бохара, Фирганә, хәтта Ташкентны үзләренә каратсалар да, Сырдәрья, Йидесу, Тургай областьларының күбрәк кыйсемен һаман да Хөсәеновларга калдырганнар. Габделгани бай Казалыда торганда эшне бик зурайткан. Акрынлап башка шәһәрләрдә дә вәкилләр тота башлаган. Соңра күп урыннарда кантур, ысклад вә отделениеләр ачкан. Мондый отделениеләр Акмәсҗед[5] (Перовский), Төркестан, Ташкент, Сәмәрканд, Әүлия Ата[6], Алмата, Чимкәнт, Тукмак һәм Ыргыз[7] шәһәрләрендә булган. Бу шәһәрләр һәммәсе Казалы кантурына карап, хисаплары вә эшләре Габделгани бай идарәсендә булган.

Габделгани Төркестан шәһәрләрен үз кулына алган вакытта, олуг борадәре Әхмәт Оренбургның тире вә акча базарында хакимлек итә башлаган. Казан, Мәскәү вә башка шәһәрләр илә эш йөрткән. Иң зур эшләре дә Мәкәрҗә ярминкәсендә булган. Аның вә соңрак борадәре Мәхмүтнең Мәкәрҗәдә мөселман сәүдәгәрләре арасында хакимлекләре күп еллар сизелерлек иде. Мәкәрҗәдә үзләре йорт алып (мәшһүр «Хөсәенов подворьесы», хәзердә вәкыф), аның нумерлары бөтен мөселман сәүдәгәрләренең мәркәзе хөкемендә булды. Бу йортның ишегалдындагы тире базары вә тире ыскладлары да Хөсәеновларга аз хезмәт күрсәтмәгәндер. Мәкәрҗә ярминкәсе ачылганнан бирле анда ничә йөз, ничә мең мөселман фирмасы эшләп килсә дә, бу ярминкәдә борадәран Хөсәеновлар шикелле эш торгызган мөселман фирмасы булмаса кирәк. Мәкәрҗәдән алар чаклы файдаланган мөселман фирмасы да мәгълүм түгел. Милләткә Мәкәрҗәдә алар шикелле олуг мәңгелек вәкыф калдырган кеше дә әлегәчә юктыр.

1878 елда 300 мең [сум] булган сәрмая, 18 ел эшләгәннән соң, өч миллионны ашып киткән[8]. 1896 елда, өч борадәр бүлешкән вакытта, һәркаюсына бер миллион 38 мең сум өлеш алганнар. Мәкәрҗәдәге «Хөсәенов подворьесы»на, мәдрәсәи «Хөсәения» илә аның мәсҗетенә кергән йөз меңнәр вәкыф ителеп, бу тәкъсимнән хариж (*бу бүлешүдән читтә)* калдырылганнар. (Болар уртак малдан вәкыф ителсәләр дә, элек фирма Әхмәт бай исемендә йөргәнлектән, бу вәкыфлар һәммәсе Әхмәт бай исеменә нисбәт илә шөһрәт алганнар. Фәкать бу вәкыфлар янына соңра Әхмәт байның үз суммасыннан куштыгы да күптер). Югарыдан аңлашыладыр ки, борадәран Хөсәеновларның зур баюларына сәбәп – аларның Төркестаннан – Оренбургка, Оренбургтан – Казан,

---

[5] Казакъстанның Кызылорда шәһәре.
[6] Казакъстанның Тараз шәһәре.
[7] Казакъстанның Актүбә өлкәсендәге авыл. Революциягә кадәр өяз шәһәре булып торган.
[8] Фирмаларының дәвамында һәр елны сәрмаяләренең күпме булганлыгы зәкят дәфтәрләреннән мәгълүмдер (Б.Шәрәф).

Мәкәрҗә вә Мәскәүгә, хәтта Берлинга[9] кадәр урыннарда үзләре йөреп сәүдә итүләре вә бу базарлар арасындагы аермалардан чынлап файдалануларыдыр. Оренбургтан Төркестанга тимер юл сузылганчы, кәрван илә мал йөртү эшендә Хөсәеновлар илә рәкабәт*(көндәшлек)* итәргә башка фирмаларга уңайсыз булган. Ташкәнт тимер юлы эшләнгән вакытта алар бу юл эшләнүдән чиксез зур файда иткәннәр. Фәкать тимер юл ачылганнан соң гына бик күп эшләрне башкалар алганнар. Аннан соң Хөсәеновларның файда итүләре фирманың мәшһүрлегеннән вә сумманың зурлыгыннан гына була башлаган. Элекке сәбәпләр сагынып сөйләргә генә калган.

Борадәран Хөсәеновларның, хосусан Әхмәт илә Габделганинең җәмәгать эшләрендә күп йөрүләре дә аларның фирмасына зур рәваҗ *(табыш)* биргән. Халык арасында игътибарлы булуның сәүдәдә һәрвакыт зур ярдәм иткәнлеге мәгълүм. Банклар һәм вексельләр хаким булмаган базарларда исә, боларның тәэсире миселсездер *(бәяләп бетергесездер)*. Мәсәлән, Казалыда бик күп сәүдәгәрләр акчаларын казначействога салган кеби, Гани байга әманәт[10] итеп куйганнар. Бу әманәтнең 40-50 мең сумнарга йитешкәне дә аз булмаган. Хөсәеновлар кантурлары Төркестан илә Оренбург арасында акча переводына да күп хезмәт иткән. Кәрван юлында акча йөртәсе килмәгән кешеләр акчаларын Казалыда, Ыргызда Хөсәенов кантурына биреп, Оренбургка йә Мәкәрҗәгә килеп акча алалар икән. Бу эшләр даими булып торганлыктан, Хөсәеновлар, әлбәттә, зыян итмәгәннәр. Хөсәеновлар Оренбургта, Мәкәрҗәдә банк тирәсендә игътибарлы булдыкларыннан, бик күп вак сәүдәгәрләр аларның васитачылыгы *(арадашлыгы)* илә файдаланганнар. Бу кешеләргә үзләренә дә Хөсәеновлар илә алыш-вереш итәргә тугры килгән. Хөсәеновлар фирмасы борадәрләр аерылышканчы 38 ел дәвам иткән мөддәттә *(вакытта)* сәүдәгәрләргә файдалану өчен бик күп форсатлар чыккан. Өч борадәр Хөсәеновлар болардан файдаланырга белгәннәр. Шул файдалануларны бергә җыеп, эшнең үзалдына зураюына да күп хезмәт иткәннәр. Бу урында шулкадәр илә кифаяләнеп *(канәгатьләнеп)*, сәүдә җәһәтеннән күп тәфсыйлат *(аңлатулар)* биреп булмай. Ләкин, әгәр дә бу фирманың тарихы мөфассал *(тулы, җентекле)* язылса, яшь сәүдәгәрләремезгә гыйбрәтләнерлек материал бик күп чыгар иде.

ГАБДЕЛГАНИ БАЙ КАЗАЛЫДА

Гани бай 1869дан 1892 елгача – 23 ел Казалыда торган. Аның бу вакыттагы бар хезмәте, Төркестан сахрасына таралган тәңкәләр вә тиеннәрене җыеп, Оренбургтагы Хөсәеновлар фирмасына миллион сумма ясаудан гыйбарәт булган. Бөтен фикерен, зиһенен, көчен сәүдә эшенә биргән. Ул вакытта җәмәгать хезмәте уларак эшләгән эшләренең мәгълүм булганы ошбулардан гыйбарәттер:

1) Русиядән барган мосафир шәкертләрне һәркаюсын яхшы кабул итеп, хаҗәтләрен йитештереп, тәхсил *(уку)* өчен бәгъзесен Бохарага вә бәгъзесен Хивага төя яллап озата, лазем булганда буларның мәсърафларын *(чыгымнарын)* үз өстеннән күтәрә иде. Бохарадан кайтучы шәкертләр аның мосафирпәрвәрлегеннән вә кәрван йөртүеннән файдалана иделәр. Бу эш үз заманасында кирәксез вә файдасыз булмаган; 2) казакъ вә сартлар *(үзбәкләр)* арасында ниндәен дәгъва булса да, килешер өчен Гани байга мөрәҗәгать кылалар, Гани бай аларга васитачылык *(арадашчылык)* итә.

[9] Хөсәеновларның Берлин илә сәүдә мөгамәләләре озак еллар дәвам иткән. Моннан күп файда иткәннәр. Әмма Париж илә сәүдә мөнәсәбәте башлау тәҗрибәсе муаффәкыятьсез (уңышсызлыкка) чыккан. Кәгазьләрдән аңлашылдыгына күрә, 1894 ел көз көне Хөсәеновлар Парижга сарык йибәргәннәр. Саны күпме булгандыр, әмма Парижга барып йитүгә юл расхуты илә бу партия сарыкның суммасы 72055 сум булган. Париждан Мәскәү аркылы 38507 сум 15 тиен акча кайткан. Парижга йибәрелгән сарыктан 33547 сум 85 тиен зарар күргәннәр (Б.Шәрәф).

[10] Әманәт – берәүгә ышанып саклап торырга бирү.

Казалы базары һәм Гани бай Хөсәенов төзеткән мәчет

Бу хосуста бер мировой судьядан артык эшли иде. Моның илә шөһрәте дә бар иде; 3) 1880 елда Казалы әтрафында ачлык булып, бу вакытта богдай онының поты 5-8 сумнарга, арпа вә тарының поты 3-4 сумнарга йитте. Гани бай үз амбарындагы берничә ун мең пот ашлыкка бәһане күтәрергә разый булмады. Фәкыйрьләргә, гаиләсенә карап, бер вакытта 2-3 поттан артмау шарты илә тары вә арпаның потын – 1 сум 50 тиеннән, онын 2 сумнан саттырып торды. Моның илә фөкарага *(фәкыйрьләргә)* бик зур ярдәм күрсәтте. Шул тарика *(юл илә)* базар бәһасен дә берничә айлар күтәртмәенчә тотты. Бу ачлыкта аның һәр җәһәттән хезмәтләре тәкъдир ителерлек булды. Шул елны Казалыда хастаханә салу өчен 1000 сум иганә кылды. Моның өчен аңа көмеш медаль бирелде; 4) Казалыда зур таш мәсҗет бина кылдырды һәм 5) Төркестан вилаятендә беренче ысулы җәдидә мәктәбе ачтырды.

Гани бай Казалыда чакта гадәте тәүфыйклы, игътибарлы, тырыш вә намуслы бер сәүдәгәр вә адәмнәргә хәерхаһ һиммәтле *(тырыш, кайгыртучан)* бер кеше булса да асыл аның имтияз *(өстен булган)* иткән эшләре Оренбургка кайттыгыннан соңдыр. Казалыда җәмәгать вә милләт хезмәтләре илә шөгыльләнергә урын вә мохит булмаган. Бу хосуста сөйләшерлек кешесе дә тугры килмәгәндер. Ул вакытта өч борадәрнең маллары да уртак булып, һәммә хәйрат юлына тотылган нәрсәләр Әхмәт бай исеменнән йөртелгәнгә, Гани байга үз исеменә олуг хәйрат кылырга җае да тугры килмәгән. Зәкятнең күбрәге Оренбургтан сарыф ителдеге хәлдә, бер кыйсеме Казалыдан вә башка отделениеләрдән дә өләшенмештер.

Гани байның хаҗга баруы 1884 елда булып, Казалыда вакытындадыр. Шул вакытта ул үзенең кечек борадәре Габдрахманга сәрмая *(капитал)* өчен 10 мең сум һәдия *(бүләк)* иткән[11].

1893 елда Гани бай Сәмәркандка барып, анда Исмәгыйль бәк Гаспринский вә Мәҗид бәк Ганизадәләр илә очрашып, мәктәп эшләре хакында күп сөйләшкән. Ул вакытта Гани байның яшь балалары укыр вакытка йитеп килдекләреннән, Гани бай бу мәктәп мәсьәләсе илә вә балаларны ничек укыту кайгысы илә мәшгуль булган.

[11] Габдрахман 12-13 яшьләрендә Каргалыда вафат була.

Мәктәп мәсьәләсенә һәвәсе кузгалган хәлдә, шул елны Оренбурга кайткан. Казалыда аны күп елларгача сагынып сөйләгәннәр. Әле дә искә төшерүчеләр күп. Аның Казалыда тоткан игътибарлы вә югары урыны хәзергәчә буш торадыр.

ГАНИ БАЙ ОРЕНБУРГТА

Гани байның мәйданга чыгуы вә киң шөһрәт казануы Оренбурга кайткач булды. Оренбургта тордыгы 8-9 ел мөддәт *(вакыт)* – аның өчен бөтен гомердер. Мәктәп мәсьәләсенә һәвәсе кузгалып кайткан кеше Оренбургта вә бу тарафта мәсьәләне сөйләшерлек кешеләр һәм дә фикерене гамәлгә татбикъ итәрлек *(яраштырырлык)* урын тапмыш. Ул кайтканда Оренбург тирәсендә ысулы җәдидә мәсьәләсе шактай кызып, Әхмәт бай аңа ачыктан-ачык тарафдарлык итмеш, Гани бай мәсьәләнең уртасына килеп төшмештер. Һәркөн күрешкән кешеләр бу мәсьәләдән бәхес иткәнгә, Гани байның дикъкате ысулы җәдидә мәктәпләре мәсьәләсенә хәсыр ителгән *(чолгап алынган)*. Бу мәсьәләдә аның фикере эшләүгә элек елларда күп ярдәм иткән кешеләр мәрхүм Шакир Рәмиев илә Гомәр хәлфә Дәүләтьяров булмыштыр. Гани байның кара гакылында мөбһәм *(билгесез)* рәвештә кузгалган вә аны мәшгуль иткән мәктәпләрне ислах *(яңарту)* мәсьәләсендә бу ике зат нәзарияләр бәян иткәннәр, ислах итү фикеренә формулалар хәзерләп биргәннәр. Гани бай Гомәр хәлфә илә бәрабәр Уфадагы «Өдәба *(әдипләр)* җыелышы»на барып, күп милләтчеләр илә танышкан. Төркестанда озак торган кешегә бу галәм тирән тәэсир калдырган. Соңра мәрхүм Шакир Рәмиевнең киңәше илә ул Фатыйх әфәнде Кәримевне Оренбурга чакырган. Аннан соң Гани бай, Фатыйх әфәнде Кәримев һәм аның атасы Гыйльман ахунд илә мөзакәрә *(фикер алышу)*, мосахәбә *(аралашу)* вә мәҗлесләрне берничә ел дәвам иттереп, аның мәктәп ислахы мәсьәләсендәге фикерләре тәмам ачык рәвештә эшләнеп, ул шуларны мәйданга куярга тәмам бирелгән. Бу фикерләрне нәшер итүдә *(таратуда)*, ысулы җәдидәне тәгъмим итүдә *(массалаштыруда)* малы илә, сәүдәгәрләр вә имамнар арасындагы нөфүз *(сүзе үтүе)* вә игътибары илә никадәр хезмәт итсә, аннан артыграк эшләүләре, йөрүләре, сөйләүләре илә хезмәт итмештер. Гани бай ысулы җәдидәне химая итүче *(яклаучы)*, аңа акча сарыф итүче бер хәйрат иясе *(бер меценат)* генә түгел, бәлки бу юлда иң фидаи бер мөҗаһид *(тырышучы)* иде.

Гани бай ысулы җәдидәнең тәгъмименә бик сызганып вә бик кызу хезмәт иткән вакытта вә бунын илә шөһрәте афакка *(төрле якка)* җәелгән чагында әҗәле ирешеп, 1902 ел, ноябрь 3ендә Оренбургта вафат итте. Җеназасы ул вакытта Оренбургта мосафир булган фәзыйләтле мөфти әл-хаҗ Мөхәммәдьяр Солтанов тарафыннан укылып, ноябрь 4ендә җәмгы газыйм (күп халык) хозурында дәфен ителде (күмелде). Җеназасындагы күпчелек аннан элек Оренбургта һичбер мөселманга насыйп булмамыштыр. Мәркаде *(кабере)* Оренбургның яңа каберлегендә[12] булып, күп кешеләр тарафыннан зиярәт кылынмактадыр[13]. Ходаның рәхмәтендә булгай иде.

*Текстны басмага **Җәүдәт Миңнуллин** һәм*
***Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

[12] Хәзер ул зират шәһәр уртасында, Җиңү проспекты чатында калган. Анда Гани бай кабереннән ерак түгел Мәхмүт бай һәм аның хатынының кабер ташлары да тора.

[13] Кабере өстендәге мәрмәр ташта шөйлә (болай) язылмыштыр (бер ягында): «Ошбу кабер сахибе Габделгани бай Хөсәенов шәгъбән унбишендә 1320 сәнәдә, 1902 миладиядә»; икенче ягында ни өчендер гарәпчә. Тәрҗемәсе: Рәхимле Аллаһ тынычландыр бу кабернең сахибен, хәйрат иясен Габделгани бине Гали Хөсәензадә. 1320 ел шәгъбән аеның уртасында вафат булды. Монда өч йөз урынына ике йөз дип язылган. Дөрест төрки язуны тәгъмим өчен никадәр мөҗаһидлек иткән фидакарьнең кабер ташында гарәби ялгыш чыннан да бик мәгънәледер (Б.Шәрәф).

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

АЧЛЫКТАН СОҢ ТАТАРСТАН АВЫЛЛАРЫ

Рәүф Сабиров*

АЕРЫМ ХУҖАЛЫКЛАР

Авылларда хуҗалыкларның төрле груһларга бүленгәнлекләрен әйтеп үткән идек. Аларны башлыча өч груһка бүлергә мөмкин. Беренче груһ – ачлык вакытында атын, сыерын, иген коралларын саклап калып, хуҗалыгын түбән төшермәгән һәм ачлыктан соң тагын бер ат өстәп, үз җиреннән тыш, атсызлар җиреннән файдаланучы бай хуҗалыклар. Бу груһка бик аз хуҗалыклар керә, күп татар авылларында мондый хуҗалыклар бөтенләй табылмый. Мәсәлән, Янбактыда ике атлы бер хуҗалык та юк.

Икенче груһка ачлыктан бер атын яисә бер сыерын саклап калып, хәзерге вакытта бер ат, бер сыерлы һәм иген кораллы хуҗалыклар керә.

Өченче груһ – эшче куллары, җирләре булса да игәргә ат һәм иген кораллары булмаган фәкыйрь хуҗалыклар. Бу соңгылары, авылның иң күп өлешен тәшкил итеп (65-70%), үзләре тагы икегә бүленәләр: атлы хуҗалыкларга эшләшеп һәм төрле юллар илә орлык чәчеп, җирнең зур өлешен чәчә алган, иген кораллары күп булган, хуҗалыгын

* Дәвамы. Башы журналның 2018 елгы 10 нчы санында. Мәкалә басмага Рәүф Сабировның «Ачлыктан соң Татарстан авыллары» (1923) исемле китабы нигезендә әзерләнде.

нычытырга өмид белән караучы атсыз хуҗалыклар һәм җирнең бик аз өлешен чәчә алган, хуҗалыгын төзәтү өчен бик күп еллар кирәк булган ярым пролетар хуҗалыклар. Бу соңгыларына кире кайткан качакларны да кертергә мөмкин.

Аерым хуҗалыкларның икътисади көчләрен ачыграк күрсәтү өчен, монда төрле типтагы хуҗалыкларны язып үтәргә мөмкин:

1) Ижбарскино авылында ачлыктан соң иң яхшы тормышлы крәстиән – Ивайкин. Аның хәзерге көндә ике аты, бер сыеры, 4 сарыгы бар. Түбәсен тимер белән япкан, 10-12 аршынлы йорт, таштан салынган кладовкалар, ике атлы иген кораллары бар. Бу ел ул 4 дисәтинә ярым арыш, 4 дисәтинә чирек сабан чәчкән. Бу груһ хуҗалыкларның игене җитеш ягыннан башка груһларныкына караганда яхшырак булган. Чөнки алар, бердән, ат һәм кораллары мөкәммәл булганлыктан, вакытында яхшы итеп эшли алганнар, икенчедән, орлыклар тазартылып, яхшыртылып чәчелгән. Бу хуҗалыкның алты җанга 3 эшче кулы бар. Аның өстенә, атсыз кешеләр кулыннан да файдалангалый. Ике басудан 162 пот ашлык көтә. Шуның 60 потын чәчәргә, калганнары белән семьясын туйдырырга уйлый. Революциягә кадәр 8 аты, 6-7 сыеры, 30 башлап сарыгы булган. Авылдагы җирен чәчә алмаучыларның бөтен җирен biläп, ике басуга 50шәр дисәтинә җир чәчкән. Элек тә һәм хәзер дә сәүдә итмәгән. Тормышыннан зарлана, салым булыр, дип уйлый.

2) Шул ук авылда Петр Муллин: 5 җаннан гыйбарәт семьясы, 2 эшче кулы, бер аты, бер сыеры, бер сарыгы бар. Башка хайваннары юк. 2 ярым дисәтинә арыш, 3 дисәтинә сабан чәчкән. Ике басудагы җирен 6 дисәтинәгә җиткерергә уйлый. Бу ел 30 потлап ашлык алыр. Шуның 40 потын чәчәргә уйлый. Үз җиреннән тыш, ике атсыз кешегә 5 дисәтинә җир эшләгән. Күпме эш хакы алганын хәтерләп бетерә алмый.

3) Кукина Анастасия. 6 җанга 2 эшче кулы бар. Бер йортыннан башка каралтылары юк. Ярты дисәтинә арыш, бер дисәтинә сабан чәчкән. Бөтен эшен җир һәм орлык бәрабәренә атлы хуҗалыклар эшләп чәчеп бетергәннәр. Казаннан орлык чыкса, бер ярым дисәтинә көзлек чәчәргә уйлый. Булмаса, ярты гына дисәтинә чәчә алачак.

4) Буа кантонының Шәйморза авылындагы Шәмсетдинов Нуретдин: 9 җанга 4 эшче кулы бар. Йорт-җирләре бик яхшы, зур амбарлары, таш кладовойлары, ике аты, бер сыеры, мөкәммәл иген кораллары, вак хайваннардан – 8 сарык, 10 баш тавыгы бар. Арыш – 4 ярым дисәтинә, сабан 5 дисәтинә чәчкән. 3 кешенең игеннәрен эшләгән, 190 пот ашлык алачак. Шуның 70 потын чәчәргә уйлый. Элек игеннән башка сәүдә дә иткән, зур магазины булган, хәзер кибет ачып сәүдә итмәсә дә, итәк астыннан эш йөртә. Гомумән, хуҗалыгы бик нык күтәрелеп бара.

5) Шул ук авылдан – Камалетдинов: 6 җан, 2 эшче кулы бар. Бер йорты, зәгыйфь каралтылары, бер сыеры, бер аты, бер атлык иген коралы бар. 2 дисәтинә арыш, 2 дисәтинә сабан чәчкән. Көзлек басуында 3 дисәтинә җир сукалап куйган һәм шуны чәчәргә ышана.

6) Фәхреддинов Гыймади: 4 җан, 3 эшче кулы бар, бер йорттан башка каралтысы һәм хайваннары юк, ярты дисәтинә арыш, 15 сажин сабан чәчкән. Көзлеккә 10 сажин чәчә алачак. Семьясын эшләп туйдырып чыгара яисә кая булса да күчеп китәргә уйлый.

Менә авылларда барлык хуҗалыклар шул груһларга бүленәләр. Болардан башка, авылда йортсызлар дип йөртелә торган, бөтенләй хуҗалыгы булмаган кешеләр дә очрый. Болар күбрәк читтән кире кайткан, ачлык качаклары һәм ачлыктан йортларына кадәр сатып, кеше йортында торучы, ялланып тамак туйдыручылар – авыл пролетары.

НЭП ҮЗ ЭШЕН ЭШЛИ

Гомуми коммунизм вакытында туры контрибуция, конфискация, развёрсткалардан какшап калган бай хуҗалыклар ачлык вакытында бөтенләй зәгыйфьләнеп, бер

атлы хуҗалыклар дәрәҗәсенә килгәннәр иде. Ләкин башкаларның кул көче белән мал җыярга өйрәнгән бу халык ачлыктан соң да үз эшенә керешә башлаган. Авылдагы чиксез күп буш эш кулыннан, чәчелми калган җирләрдән алар киң рәвештә файдалана башлаганнар. Авылда чәчелгән кырларның өчтән ике өлеше, кайбер авылларда артыграгы атлы хуҗалыкларга төшә. Димәк, атлы хуҗалыклар, үз җирләреннән тыш, атсызлар кырын да чәчеп, аларның җирләрен биләп һәм эш коралларын үзләренә хезмәт иттерә алалар. Табигый, икътисади җәһәттән гаять артта калган Татарстан өлкәсендә бу халәт артык зур куркыныч төс ала алмаган әле.

Авыл ел саен әллә никадәр җирләрнең кысыр ятуы, йөзләп эшче игенче кулларның эшсез, буш торуы дәверендә безнең лозунгыбыз бөтен җирләрне чәчү, буш кулларны ничек булса да эшләтү булырга тиеш. Шуның белән бергә, атсыз-коралсыз хуҗалыкларның тормышына игътибар итеп, аларны оештырырга, аларга авыл хуҗалыгы кредитлары бирергә, җир, урман эшчеләре союзы аша авыл батраклары, йортсыз хуҗалыкларның хисабын алып, тиздән төрле артельләр, коммуналар төзи башларга кирәк.

АВЫЛГА НИЧЕК АТ КАЙТА?

Һәр авылда 5-10 башка кадәр ат артканын әйтеп узган идек. Хәзер инде аларның нинди юллар белән кайтуларына тукталып үтәргә кирәк. Без Себердән ат алып кайтучы крәстиәннәр белән озак фикер алыштык. «Нигә соң сез һәр хуҗалык аерым рәвештә Себергә атка барасыз? Бөтен авыл йә волость берләшеп кайтарганда җиңел дә, очсыз да булыр иде», – дигән сөальгә ат алып кайткан крәстиәннәр безгә бертөрле җавап бирәләр. Бердән, аларның бу эшләрен башлап, оештырып йөрүче юк, икенчедән, үзләре генә барганда, алар хисабынча, ат очсызракка төшә. Табигатьнең рәхимсез авырлыклары белән гыйлемсез, коралсыз, сәрмаясез көрәшеп өйрәнгән авыл халкы һәрнәрсәгә үзенчә хисап бирергә, үз көченә генә таянырга, үзенә генә ышанырга өйрәнгән. Өченчедән, алар чиктән тыш авырлыклар белән иң ахыргы, иң кадерле булган тормыш нәрсәләрен, актык икмәкләрен сатып җыештырган акчаларын беркемгә дә ышана алмыйлар.

Аларның бу психологияләрен үзгәртү өчен, сүз белән генә түгел, эш белән хәрәкәт итәргә, оешып эшләү, оешып мал табу һәм иген кораллары кайтаруны күрсәтергә кирәк. Ләкин авыллар әле бу эшкә бик аз әһәмият бирә. Мәсәлән, Янбакты авылында 2 хуҗалык үзләре Себердән ат алып кайткан, алар алганда Казанда ат 400 сумнар чамасы торган. Алар, бар күк җүнәткән акчалары 150 сум гына булганга күрә, Себергә барырга ниятләгәннәр. Себергә җәяүләп китеп, бер айдан артык барганнан соң, ат очсыз сатыла торган җиргә барып чыгып, икесе берәр ат сатып алганнар. Барганда да, кайтканда да аларга бик аз расход чыккан. Төрле икмәк булган губерналарда, авылларда үзләренә дә, атларына да ашарга табуы читен булмаган. Ниһаять, өч ай йөреп, язып бетермәслек мәшәкатьләр күреп булса да, атларны алып кайтып җитә алганнар. Бу юлда йөреп узган өч кышкы айны алар хисапка алмыйлар. Барыбер кыш көне эш табып булмый, барыбер көн болай да буш үтәр иде, без атсыз калыр идек, диләр.

Крәстиән хуҗалыгының фундаменты булган ат, иген коралы авылда нинди роль уйнавын сөйләп торасы да юк. Шуның өчен дә игенчеләрнең нинди генә юл белән булса да атлы булырга теләүләре, башка хайваннардан, йорт җиһазыннан, хәтта ашар икмәктән язып булса да, ерак Себер сахраларына җәяү барып ат алып кайтырга тырышулары да бик табигый нәрсә. Совет оешмаларына, аеруча бу эшкә артык якын торган җир оешмаларына, кооператив органнарына һәм банкларга бу эшкә зур әһәмият биреп, ат кайтару эшен тизрәк җайга салуда, хөкүмәт көченнән бигрәк, авылның үз көчен оештыруда җитди чаралар күрергә кирәк.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КРЕДИТЫН ТИЗРӘК ЮЛГА КУЯРГА КИРӘК

Авылның ярлы һәм урта крәстиәннәрен көчле хуҗалыклар эксплуатациясеннән тәмам арындырыр өчен, югарыда әйткәнчә, артельләр төзү белән бергә, тиз рәвештә авыл хуҗалыгы бурычы бирүне гамәлгә куярга кирәк булачак. Юкса, авылда берничә генә көчле хуҗалык урта гына җир чәчү, яңа икмәккә кадәр азык биреп тору юллары белән аз көчле хуҗалыкларны куркыту эшен дәвам иттерәчәкләр. Авыл, аеруча татар авыллары авыл хуҗалыгы кредитының ни икәнен белми. Сельхозбанк турында һичберәүнең дә ишеткәне юк. Барлык көчне сарыф итеп, авыл хуҗалыгы кредиты өчен сәрмая хәзерләргә һәм совет көчләре аркылы көчле агитация ясап, бурыч алу, аннан файдалану ысуллары белән халыкны таныштырырга кирәк. Шул вакытта гына үсеп килә торган яңа авыл эксплуататорларының юлына киртә салырга, урта һәм ярлы хуҗалыкларны аларның золымыннан коткарырга, буш ятучыларга эш табарга һәм эш хайваннары, иген кораллары кертергә мөмкин булыр.

АВЫЛДА СӘҮДӘ ЭШЛӘРЕ

Татарстан авылларында элек вакытта сәүдә эшләренең барышы иген бүлү белән баглы булган. Соңгы ачлык елларда исә сату-алу эшләре бөтенләй дип әйтерлек туктаган. Шуның өчен дә бик күп авылларда бер төрле дә кооперативлар һәм частный кибетләр юк.

Без карап чыккан 9 авылда фәкать 3 хосусый кибет кенә очрата алдык. Бу кибетләрдә дә крәстиән тормышы өчен иң хаҗәт булган тоз, шырпы, керосин, урак, чалгы, кадак кебек нәрсәләр генә булып, шуннан артык булган зиннәт әсбаплары, фрукта, тәмле тәгамнәр һичбер авылда юк. Хәтта бу кибетләрнең берсендә дә мануфактура да сатылмый. Гомумән, авыл мунуфактура, чәй, шикәр кебек нәрсәләрне алуны күптән инде оныткан. Кантон калаларында Татторг, Татсоюзлар зур магазиннар, биргән справкалар мануфактура, шикәр кебек нәрсәләрнең авыл өчен чиктән тыш аз сатылганын күрсәтәләр.

Авылларны кирәк нәрсәләр белән базарлар туйдырып торалар. Һәрбер 15-20 чакрымлык төбәктә бер базар булып, авыл халкы товарны шуннан ала. Бу базарларда патент түләгән кибетләр элекке вакытка караганда 2-3 мәртәбә азрак булса да, аяклы кибетчеләр моннан шәп сәүдә итәләр. Сәүдә күбрәк икмәккә алышу белән барса да, соңгы вакытларда акчаның кыйммәте яхшы ук күтәрелгән. Авылларда сөт, бәрәңге кебек нәрсәләрне акчага бик җиңел табып була.

АВЫЛ СӘҮДӘГӘРЕ УШАКОВ

Без Гусиха авылында Ушаков исемле НЭП сәүдәгәренә очрадык. Ушаков элек вакытта фәкать сәүдә белән генә шөгыльләнгән. Шушы авылда аның зур кибете булып, аннан тыш, Спаста һәм тирә-яктагы базарларда да кибетләре булган. Еллык обороты 10-15 меңнәрчә хисапланган. Революция вакытында сәүдә эшләре тукталгач та, ул эшен туктатмаган. Бу хакта үзе дә яшереп тормый. «Бер җирдә нәрсә таба алмаган вакытта мин бөтен тирә-якны товар белән туйдырып тордым», – ди. Бу елларны аңар бик авырга туры килгән. Спастан товар белән кайткан вакытларда әллә ничә мәртәбә заградительный отряд туры килеп, малыннан язгалаган чаклары да булган. Шулай да, үзенең җитезлеге аркасында, ул НЭПка кадәр шулкадәр сакланып килә алган. Яңа икътисади сәясәт башлану белән үк, ул Спаста Потребсоюзга хезмәткә кергән. Үзе дә: «Анда бик яхшы җүнәттем, рәтләнеп калдым», – ди. Соңыннан, Союздан чистартып чыгарылганнан соң, үз кибетен ачып җибәргән. Хәзерге көндә аның обороты ның ни дәрәҗәдә икәнен белүе бик кыен. Кибет шүрлегендә товар асрап, салым түләп ятарга ул

бервакытта да риза булмаячак. Сәүдә итү тыелган вакытларда һәркөн килеп тентүчеләр дә аның складларыннан бернәрсә дә таба алмаганнар.

Ушаков сәүдә итү белән генә шөгыльләнеп калмыйча, аның хуҗалыгы авылдагы бөтен хуҗалыклардан өстен торды: 2 аты, бер пеләмәнни сыеры (сыер июль бәһасе белән 15 миллион тора), 10 башлап сарыгы, казы, үрдәге һәм тавыклары бар. Үзе, бер мәртәбә дә иген эшендә эшләгәне булмаса да, ни чәчәргә кирәген яхшы белгән – иң күп җиренә тары чәчеп тутырган. Тарыга бу ел яхшы килгәнгә күрә, ашлыгы авылда һәммә кешенекеннән күбрәк булып, шуның аркасында ул әле киләсе ел тагы да күбрәк чәчеп калдырырга, 2 атны 4кә җиткерергә, аның өстенә, беркадәр төп сәүдә суммасына өстәргә уйлый.

Совет хөкүмәтенә ул яхшы күз белән карый алмаса да, зарланмый. Попларны сүгә, чиркәүгә бармаганына ун еллап бар. Спастагы бөтен эш башындагы кешеләрне исемнәре, фамилияләре белән белә. «Салымны күп салмасалар, сату итүдән тыймасалар, безгә шушы власть ярый», – ди.

ИСКЕ БАЙ ГЫЙМАЗ ХАҖИ

Гыймаз хаҗи ул хәзер ачык сәүдә итми. Кибетләре юк, ләкин тик ятмый. Авылга кирәк-яракны ул «болай гына», кибет шүрлекләренә куймый гына җитештерә ала. Элек авылында зур мануфактурасы, бакалея кибете һәм зур-зур иген амбарлары булган. Бер яктан ул гаять киң рәвештә, әллә никадәр эшчеләр яллап иген иксә, икенче яктан сәүдә иткән. Бөтен тирә-якның игеннәре аның биек амбарларына очсыз вакытта кереп бикләнеп, икенче елның язында, бәһа күтәрелгәч, су белән Казанга һәм Нижнийга озатылганнар. Авылда гына түгел, тирә-як волостьларда да сәүдә эшендә аның белән тиңләшүче бик аз булган. Байлыгының көннән-көн артуына, сәүдәләренең уңышлы баруына шөкрана йөзеннән, ул хаҗга барып кайткан. Гыймаз хаҗи бу мөбарәк сәфәрен бик тәфсилләп сөйли: «Мин Кәгъбәтуллага барып кына калмадым, бөтен изгеләр зиратын тәваф итеп чыктым, Ибраһим һәм Исмәгыйль пәйгамбәрләрнең каберләрен күреп кайттым», – ди. Башка хаҗилар 500 сум белән йөреп кайтканда, Гыймаз хаҗи 2000 сум расход чыгарып кайткан, ләкин, ни өчендер, Ходай аның бу мәшәкатьле, расходлы саҗдәләрен кабул итмәгән: хаҗдан кайтып күп тә үтми, әллә нинди большевик дигән халыклар чыгып, аның бөтен планнарын зир-зәбәр китергәннәр. Бу эш Гыймаз хаҗига чиктән тыш начар тәэсир иткән. Аның, малы чыгу белән бергә, бөтен рухы, энергиясе чыгып, элеккеге мәһабәт, хәйләкәр, тәкәббер Гыймаз карттан тартынчак, җуаш кына, куркак Гыймаз картка әйләнгән. Хәзер аның эшләрен үз рухында тәрбияләп, үз язуларын үзләре генә танырлык мәктәп күрсәтеп үстергән уллары алып бара. Гыймаз карт хәзер өеннән генә торып ничек эшләгәндә күбрәк крәстиәннәрне алдарга мөмкин икәнчелек турында улларына киңәш биреп ята. «Ник кибет ачмыйсың? Сәүдә итмисең?» – дигән сөальгә ул: «Елларның бер дә рәте юк бит, хәзерге акча белән эш итүе бик читен», – ди. Аның акчадан куркуының да сәбәбен белдек. Эшләрнең җае китә башлагач, Гыймаз хаҗи үзенең бөтен байлыгын Николайның йөзлекләренә алмаштырып куйган икән, ләкин, шушы көнгә кадәр Николай кайтып, Русиядә тәртип урнаштыра алмаганлыктан, Гыймаз хаҗиның йөзлекләре дә өй кәгазьләреннән башкага ярамый торган тәти кәгазьгә әйләнеп калган. Шулай да күрше-күләннәреннән сорашып, без Гыймаз хаҗиның хәзерге көндә дә, тик ятмыйча, әкренләп алыш-биреш иткәләп ятканын белдек. Ул тәҗрибәле карт әле дә күп кенә иген игеп, авыл белән шәһәр арасында мал алмашып эш күрә икән. Гыймаз хаҗи кебек мондый кибетсез сәүдәгәрләрне башка авылларда да очраткаладык.

Дәвамы бар

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *һәм* ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

Шам татарлары

Ләлә Мортазина

«Шам-шәрифкәй дигән, һай, шәһәрдә
Кич ахшамсыз капкалар ябылмас...»
Халык җырыннан

Дөньяның татар булмаган почмагы бармы икән? Мөгаен, юктыр, булса да, бик аздыр. Язмыш җиле татар мөһаҗирен кайсын-кая илтеп ташлаган: кемдер ерак чит илләргә үз теләге белән, ирекле рәвештә күчеп киткән, кемдер тыныч тормыш, бәхет эзләп туган илен ташлап китәргә мәҗбүр булган. Сәүдә итү, мал арттыру өчен татарлар Финляндияне сайласа, һәртөрле эзәрлекләүләрдән – чукындыру, руслаштыру хәвефеннән, җир кытлыгы, фәкыйрьлектән качып, мөселман мәмләкәтләренә, Япония, Кытай кебек илләргә юл тотканнар. Россиядә мөселман мәктәп-мәдрәсәләренә басым арту, 1897 елгы халык санын алу да куркуга салган милләттәшләребезне. Шулай итеп, михнәт чигүдән туйган татарның бер дулкыны яхшы тормыш һәм ирек өмет итеп, ата-баба җирен ташлап китәргә карар кылган. Чит илләрдәге татарларның бер өлешен исә шул илләргә белем алырга китүчеләр тәшкил иткән. Алар арасында шунда төпләнеп калучылар да булган.

XIX гасыр ахыры-XX гасыр башларында Казан, Самара, Оренбург кебек татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдән Госманлы дәүләте кул астындагы Истанбул, Бәйрут, Мәккә, Мәдинә калаларына укырга китүче шәкертләр саны аеруча күбәя. Кайбер чыганаклар буенча, 1906 елда Истанбулдагы һәрбер уку йортында 5-6 татар шәкерте белем алган,

Салхия районының үзәгендә урнашкан Йосыф әл-Әзма (Юсеф аль-Азма) мәйданы

Мәрҗан лицеенда татар студентлары өчен хәтта махсус сыйныфлар оештырылган була[1]. Шуның өстенә, Төркия бик күп кенә башка мөселман илләренә, аерым алганда, Европа дәүләтләренә барып белем алырга теләүче татар шәкертләре өчен арадашчы вазыйфасын да үтәгән. Европа университетларында белем алган татарларның шактые сәфәрләрен Истанбулдан башлаганнар – биредә чит телләр (француз, алман, инглиз телләрен) өйрәнеп, сәфәрләрен дәвам иткәннәр. Татарлар Европаның атаклы Париж, Льеж, Фрайберг, Американың Сан-Франциско, Вальпараисо, Айова университетларында белем алганнар, Бәйрутта, Каһирәдә гыйлем эстәгәннәр. Заманында Госманлы империясе кул астында булган Сүрия, Шамдагы (Димәшекъ – Дамаск) атаклы уку йортларында да татар шәкертләре шактый булган.

Шамда яшәүче халыклар – төрекләр, гарәпләр татар мунчасын бик ошатканнар, хәтта үзләре дә моңарчы күрелмәгән, таныш булмаган могҗизаи бу мунчаны салырга тырышып караганнар, тик булдыра гына алмаганнар. Монда инде аларга татарлар үзләре ярдәмгә килгән.

Җырларда җырланган Шам-шәриф[2] каласында яшәгән татарлар турында мәгълүматлар әлегә әллә ни күп түгел. Мәрмәрә университеты докторы Исмәгыйль Төркуглының билгеләп үтүенчә, Мәккә, Мәдинә, Шам кебек изге шәһәрләрнең документларында казан татарлары турында еш искә алына. Милләттәшләребез Шамга нигездә 1890 нчы еллардан соң күчеп утыра башлый. Галимнәр татарларның күченеп килү өчен әлеге җирләрне сайлауларының төп сәбәбе – аның Нәкышбәндия тарикатенең бер тармагы булган Халидия тарикате үзәге булуында дип саныйлар[3].

Билгеле булганча, бирегә килеп төпләнгән татар мөһаҗирләре шундагы Салхия[4] дигән җирдә кечерәк кенә, егерме йорттан торган үз авылларын булдырганнар, тырышлыклары белән тирә-юньдә яшәгән төрек, гарәп халыклары арасында шөһрәт казанганнар. Йорт-җирләрен гел карап торган, үтә пөхтә һәм эшчән татарларны җирле халык хөрмәт иткән, хөкүмәт аларга хәтта йорт-җир салу өчен махсус урыннар да бүлеп биргән, ерак чит мәмләкәттән килгән мөһаҗирләргә яшәү өчен шартлар тудырырга тырышкан. Тик ватаннарында бар булган мал-мөлкәтен аз бәягә генә калдырып килгән милләттәшләребез яңа урыннарда җан-фәрманга яшәргә тырышсалар да туган җирләрен оныта алмаганнар, аның урман-күлләрен, иген кырларын, киң болыннарын сагынып-саргаеп яшәргә мәҗбүр булганнар.

Күренекле татар язучысы Атилла Расихның «Ямашев» романында Шам-шәриф каласының татарлар яшәгән әлеге Салхия дигән урыны искә алына. Әсәрдә кайчандыр бу җирләргә күченеп килгән, казан татарларын сагынып, көтеп яшәүче, Шам каласына килеп чыккан милләттәшләребезне булдыра алган кадәр кунак итәргә тырышучы Талип агай һәм шунда яшәүче башка татарлар турында бәян ителә. Талип агай Казан губернасыннан авыллары белән диярлек күчеп килгән татарлар белән яши. Аның төп вазыйфасы хаҗга баручыларны каршы алу һәм хәстәрләп озатудан гыйбарәт. Поезд килеп туктау белән, хаҗ сәфәренә чыккан юлаучыларны күреп алган Талип агай, иң беренче итеп: «Әфәнделәр, сез казанлылар түгелме?» – дип сорый торган була. Аның иң теләгән бер хыялы-өмете бар – ул да булса, туган җирне кайтып күрү. Тик Талип агай бу хыялның тормышка ашмаслыгын аңлый, шуңа күрә изге ватаныннан килгән

[1] Фәйзи Х. Садретдин бәйгә мөрәҗәгать // Әлфәт. – 1906. - №17.
[2] Шам-шәриф – данлы, шөһрәтле Шам.
[3] Исмәгыйль Төркуглы. XIX гасыр ахыры-XX йөз башы төрек-татар багланышлары // Чын мирас. – 2013. - №1. – Б.9.
[4] Салхия – Касьюн тавы итәгендә урнашкан өч районның берсе, Димәшекъның төп сәүдә урамы биредән башлана.

һәркемне кунак итәргә, аңа хәленнән килгәнчә хөрмәт күрсәтергә тырыша. Ул менә бу юлы да Казаннан килгән иң кадерле кунакларын үзе яшәгән урынга алып бара, аларны төз каралты-куралар тоткан татарларның тормышы-яшәеше белән таныштыра. Таш-балчыктан гына төзелсә дә, татарларның йорт-җирләре нык, төзек. Һәр ишегалдында бакча, җиләк-җимеш куаклары утыртылган. *«Без арттагы өйгә керәбез. Безне татар карчыгы каршы ала. Әйтерсең лә мин үз авылыма кайтып кердем. Шәрык өйләренә хас җыештырылган идәнгә мендәрләр тезелгән. Без чәй эчәбез. Җәмилә апа туган якны бик тә инде сагынганлыгын сөйли. Бер генә кайтып күрер идем, ди. Без, әби янында Фәүзияне калдырып, икенче якка – ирләр ягына керәбез. Монда инде туган яклардан килгән як-ташларны күрү өчен байтак мөһаҗир җыелган. Алар белән озак гәпләшәбез. Тыңлап туймаганлыклары миңа бик ачык»*, – дип яза автор Шам татарларының казанлылар белән күрешү мизгелен сурәтләп[5].

Шам татарлары турындагы икенче бер чыганак – Сүриядә укучы татар студенты Камалның 1914 елда «Вакыт» газетасында басылып чыккан мәкаләсе[6]. Анда Салхиядә яшәүче татарларның көнкүреше, уй-хыяллары, кызыксынулары, шөгыльләре һәм гореф-гадәтләре сурәтләнә. Бу мәкаләдә «Ямашев» романында тасвирланган күренешләр, искә алынган вакыйгалар, хәтта кайбер шәхесләр белән очрашабыз.

Милләттәшләребез, кайда гына яшәүләренә карамастан, һәркайда татарлыкларын, телләрен, диннәрен, гореф-гадәтләрен, милли ашларын һ.б. саклап калырга тырышканнар. Шам татарлары да туган җирләренең истәлеге булган милли ашларын, киемнәрен, традицияләрен югалтмаска тырышалар, туган авылларының киң болынлыкларын, «тәңкә кебек челтерәп агып яткан Идел, Сакмар суларын, басудан иген кырыннан арып кайткач күләгәсе астында тирли-тирли, рәхәтләнә-рәхәтләнә чәй, кымыз эчеп утыра торган каен, имән агачларын» эчке бер сагыш белән искә алалар, сагынып яшиләр. Гомер буе игенчелек белән шөгыльләнгән татарлар чит җирләргә килгәч су ташу, утын кисү кебек эшләрне башкарырга мәҗбүрләр. Кайсыберләре ватаннарында үзләштергән буяучылык, тимерчелек белән көн күрә. Ни белән генә шөгыльләнсәләр дә, алар үзләрен тырыш, булдыклы, оста, хезмәт сөючән халык итеп танытканнар, җирле халыкның традицияләрен алмыйча, киресенчә, аларны үзләренең гореф-гадәтләре, яшәү рәвешләре белән таныштырырга тырышканнар. Шамда яшәүче халыклар – төрекләр, гарәпләр татар мунчасын бик ошатканнар, хәтта үзләре дә моңарчы күрелмәгән, таныш булмаган могҗизаи бу мунчаны салырга тырышып караганнар, тик булдыра гына алмаганнар. Монда инде аларга татарлар үзләре ярдәмгә килгән. Салхиядә Сүриядә гыйлем эстәүче татар шәкертләре җыелып кунак булганнар, Россиядән ерак хаҗ сәяхәтенә чыккан кешеләр бик теләп тукталганнар, ял иткәннәр, мунча кереп, чын татарча ризыклар белән сыйланып, туган илләрен сагыну хисен басканнар. Ерак Сүрия илендә читтән килүчеләр, хаҗилар, сәяхәтчеләр өчен хәтта татар телендә «Шам мосафирларына юлбашчы» исемле китап та басылып чыккан. Мәкалә авторы белдергәнчә, киләчәктә булдыклы Талип әфәнде хәтта хаҗилар өчен махсус номер да ачмакчы икән. Татар, һәрвакыттагыча, кайда гына, кемнәр арасында яшәсә дә, төшеп калмаган, тормыш авырлыкларын җиңеп, ничек тә яхшырак яшәргә, үз эшен булдырырга тырышкан. Бу сыйфаты аны башка чит халыклардан аерып торучы, аны танытучы билгеләрнең берседер, мөгаен.

Сезгә тәкъдим ителгән мәкаләдә Талип әфәнде өендә узган туй мәҗлесе дә тасвир ителә. Язма авторы, туйда катнашкан кеше буларак, аны сурәтләүгә дә киң урын бирә. ■

---

[5] Атилла Расих. Ямашев // Казан утлары. – 1982. - №1. – Б.72-73.
[6] Камал. Гарәп мохитендә татар туе // Вакыт. – 1914. – №1499 (1 июнь).

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

Гарәп мохитендә татар туе

Камал

Шамның Касьюн тавы итәгендәге Салхия дигән мәхәлләсендә Эчке Русиядән һиҗрәт итеп [күчеп] килгән 20 йорт кадәр татарлар тора. Килгәннәренә бәгъзеләренең 10 ел булса да, 2-3 ел тирәсендә, хәтта узган ел гына күчеп килгәннәре дә бар. Болар Русиядән чыккан вакыт бик зәхмәт, мәшәкать вә кыенлыклар күргәннәр. Эчләреннән шулкадәр кыенлыклар күргәннәре бар ки, сөйләүләренә караганда, Кавказ аркылы, әллә нинди тау-таш түбәләреннән шуып, урман араларыннан яшеренеп-посып бик күп авырлыклар чиккәннән соң, Батум аркылы, Төркиянең Синоп, Самсон кебек диңгез читендәге шәһәрләренә килеп чыкканнар. Анда шулай җыйнала-җыйнала яхшы гына күбәйгәннәр. Мәхәлләләр, авыллар тәшкил иткәннәр, хәтта Бурса[1] вилаятендә тагы берничә авылның гел татарлардан гына гыйбарәт улдыгын сөйлиләр. Фәкать боларның күңелләрендәге саглам игътикад [чын күңелдән ышану] вә тәгассыб [үз милләтен артык ярату] «Әүвәл Шам ахир Шам» иманы әллә нинди, татарлыктан озак бер мохиткә – гарәп мохитенә өстерәп китергән.

Монда килгәч, Русиянең киң яшел сахраларын, матур табигый манзараларын, тирә-яклары болынлыклар белән капланган тәңкә кебек челтерәп агып яткан Идел, Сакмар суларын, басудан игеннән арып кайткач күләгәсе астында тирли-тирли, рәхәтләнә-рәхәтләнә чәй, кымыз эчеп утыра торган каен, имән агачларын күрмәүләре боларны бик пошындырган. Аның җиренә, Гарәбстанның ком чүлләреннән исеп килгән эссе җилләр, бераз эчкәрәк керә башласак, тел, гореф вә гадәтләренә ашна [хәбәрдар] булмаган, зур кара күзле, озын чәчле, габа [гарәпләрнең өске йон киеме] киенгән бәдәвам гарәпләргә очрау боларга бик нык тәэсир иткән, ахрысы, җыйналышып утырганда мотлакан [бернигә дә карамастан] Карамалы авылы, Бәләбәй, Минзәлә өязләре, Әлмәт волостьларыннан вә анда уздырган хәятләреннән бәхәс итәләр.

Иртүк торып пар алаша җигеп җир сөргәннәрен, иген уңган ел кода-кодагый булып сыйлашканнарыннан, үзләренең сулары илә тәмләп-тәмләп сөйләшә, аны искә төшерәләр. Искә төшердекчә: «Аһ!» – дип эчләрен чигеп: «Ул вакыт җирнең кадерен вә кыйммәтен белмичә сатып бетердек бит, хәзер булса иде...» – дип куялар. Ничаклы эчеңне чиксәк, ничаклы уйласак та, һәммәсе хәзер инде буш хыял гына!

Шулай җыйнала торгач, монда да күбәя башлап, 5-6 ел элек 5-6 ханә икән, хәзер 20гә җиткәннәр. Үзләрен мөһаҗир күрсәтеп, хөкүмәттән йорт-җир сораганнар. Хөкүмәт боларның мөселман, тырыш татар халкы икәнлеген назыйр игътибарга алып [күреп], Салхия дигән мәхәлләнең мөһаҗир кыйсеменнән [өлешеннән] йорт салырлык җир биргән. Аз да үтми, өй хуҗасы булып, эшләрен юлга салганнар. Хәзер аны да хөкүмәт бирми торган булды! Фәкать җир сөрү, ашлык сачу кеби эшләргә керешергә тугры килмәгәч, кайсы утын кисү, кайсы су ташу кеби кара хезмәтләргә керергә мәҗбүр, кайсылары Русиядә үк өйрәнеп калган тимерчелек, буяучылык сәнәгатьләре сәясендә «Кадам» дигән фабрикага керергә муафыйк булганнар. («Кадам» фабрикасы яхшы гына зур фабрика бу-

Мондагы татарлар моның белән генә калмыйлар, кыз алу-бирүдә дә үз канымызны башкаларга катнаштырырга теләмиләр, көлли үзебезнекен алда тоталар.

[1] Бурса – Төркиядәге зурлыгы буенча, Әнкара, Истанбул һәм Измирдан кала, дүртенче урында торган шәһәр.

Себеркеле мунча, казанда пешергән ашлары – хаҗиларның ике-өч ай күрергә интегеп йөргән нәрсәләредер. Чөнки хаҗилар төрек хаммамнарыннан ләззәт алмый, анда рәхәтләнеп юына алмыйча йөдәп бетә. Ашханә ашлары да аларга туклыклы булмый. Шуңа күрә хаҗилар гел бу татарларга төшәргә телиләр.

лып, Хиҗаз тимер юлына кирәк булган нәрсәләр җитештерә, ватык тимер ук вә вагоннарны төзәтә вә буйый.)

Буның илә бәрабәр һәртөрле милли гадәт, хосусатымызны бик нык саклап, читләргә бирешми килгәннәр; бу хосус телләрендә, киемнәрендә, өй эчләрендә, ятыш-торышларында бик ачык күренә. Хәтта бәйрәмнәрдә без үземезне Русиядә зан итәмез [уйлыйбыз]. Чөнки, бәйрәмгә әзерләнгән аш-су, чәлпәк, паштет бәйрәмләшеп йөрүләр бөтенләй гарәп мохитендә улдыгымызны онытталар. Шуның өчен мондагы шәкертләремез бәйрәмнең тизрәк җитүен телиләр.

Хосусан, ишегалларына салынган себеркеле мунчалары Русиядәге авыл мунчаларын, андагы тормышны хәтерләтәләр. Мунча ягып, тирәләрендәге гарәп вә төрекләрне чакырулар, мунчаның бик аз мәшәкать вә очсызлык илә ясалуы боларны кызыктырган. Шундый берәр мунча ясарга тотынып карасалар да, булдыра алмаганнар. Монда мотлакан берәр сер булырга, бу мотлакан татар кулыннан чыгарга кирәклеген икърар итеп, күрше татарларын чакырып, яңадан ясатканнар. Мондагы татарлар моның белән генә калмыйлар, кыз алу-бирүдә дә үз канымызны башкаларга катнаштырырга теләмиләр, көлли үзебезнекен алда тоталар. Менә якында гына беренче мәртәбә уларак, Шамда татар туе булып узды.

Һәрникадәр бу туйның гәзитә сәхифәләренә кирәклек әһәмияте булмаса да, татар мохитеннән озак бер җирдә булуы игътибар илә һәм бу мохитләрдә үзебезнең туйлар да әллә нинди аңланмый торган җазибә [үзенә тарта торган] вә сөемлелекнең әшкәрә [ачыктан-ачык] күренүе мине язарга иҗбар [мәҗбүр] итте.

Мәктәптә булынуымыз сәбәпле, мәһәр, никах мәҗлесләрен күрә алмадык. Фәкать кияү егете булып яки ишек бавы тотарга бардык. Туйның бәгъзе җәһәтләре төрекләрнекенә охшаса да, аш-сулар, өй җыештырулар үзебезнеке иде. Ишектән керү белән идәнгә җәелгән юрганнар өстендә безнең кеби кияү егетләре булып килгән татар яшьләре, үсмерләре тезелеп утыралар иде. Без дә шулар катарыннан [рәтеннән] урын тоттык. Исәнләштек. Өйнең эче яхшы гына җыештырылган. Акбур белән буялган стеналарда чөйгә эленгән тукыма, Казан сөлгеләре, шүрлекләрдәге татар китаплары, «Мөхәммәдия»ләр[2], гәзитләр, шкафларда күренгән чынаяклар, чәйнүкләр ... өй эченә ямь биреп, аның матурлыгын арттырып, бу өйнең татар өе идекен халь [хәл, торыш] теле берлә аңлатып торалар иде.

Озакламый кияү егетләре җыйналып бетү белән ике яшькә мәхәббәт теләп, кияүне яптык. Махсус әзерләнгән бүлмәгә чыктык. Анда түгәрәк тәбәнәк агач өстәлгә чүчпәрә[3] китереп куйдылар. Аннан мөтәгакыйб [бер-бер артлы килүче] бәлеш, каксу килде. Боларны бетереп, бераз истирахәттән [ялдан] соң чәйгә утырдык. Чәйдә кияү чәкчәге китерделәр. Бу безгә шулкадәр кадерле нигъмәт иде ки, дүрт сәнәдән [елдан] бирле күрә алмаган, аның ләззәтен онытып бетергән идек. Фәкать бу дәфга [кабат] безгә онытмаслык бер хатирә ясады.

Монда миңа нык тәэсир калдырган нәрсә – аш-сулар илә туйдагы ямьлелек. Чөнки гарәп-төрек туйлары күрсәм дә, бер тат, ямь таба алмаган идем. Соңра кызыл чырайлы,

---

[2] «Мөхәммәдия» – төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләбинең дини эчтәлекле, шигъри формадагы әсәре (1449). XX гасыр башларына кадәр татарлар арасында киң кулланылышта була, кадими мәдрәсәләрдә уку әсбабы буларак та файдаланылган.

[3] Кавказ һәм Урта Азия халыкларында төче камырдан эченә ит салып ваклап бөгеп, шулпага салып пешерелгән пилмән сыман ризык.

Касьюн тавы

тулы ук битле, тормышның дулкыннарына бирешмичә армый-талмый эшли торган татар эшчеләре илә, күзләреннән ут уйнатып торган, озаклыкка карамый мәхыз [бары тик] уку өчен килгән татар шәкертләренең бергәләшеп җыйналып утырышулары иде.

***

Бу татарларның һичвакытта хаҗиларымызга бик яхшылыклары, хезмәтләре тия, ба хосус себеркеле мунча, казанда пешергән ашлары – хаҗиларның ике-өч ай күрергә интегеп йөргән нәрсәләредер. Чөнки хаҗилар төрек хаммамнарыннан ләззәт алмый, анда рәхәтләнеп юына алмыйча йөдәп бетә. Кәза [шулай ук] ашханә ашлары да аларга туклыклы булмый. Шуңа күрә хаҗилар гел бу татарларга төшәргә телиләр. Хаҗиларга хезмәт иткән кешеләремездән Талиб әфәнде бар [туй аларныкы иде]. Бу әфәндедә татарларда мәүҗүд [булган] хасыйләтләрдәге тугрылык, сәбат [чыдамлык], мәтанәт [ныклык, куәтлелек] – һәммәсе җыйналган диярлек. Күреп кайткан хаҗилар да моны игътираф итәләр [өстенә алалар].

Шамга шушы вакытлар Яурупадан бик күп сәйяхләр [туристлар, сәяхәтчеләр] килеп, 5-10 көн торып китәләр. Үзләренең кулларында үз телләренчә язылган китаплары булгач, һичбер симсарга [арадашчыга], тәрҗемәчегә мохтаҗ булмыйча, Шамны йөреп чыгалар. Менә шуны һәм хаҗиларның чиккән зәхмәтләрен назыйр игътибарга алып, мәзкүр [алда искә алынган] әфәнде гарәп матбагасында татарча «Шам мосафирларына юлбашчы» исемле китап бастырды. Китапта Шамның мәшһүр зиярәт мәхәлләләре, мәшһүр урамнары, күреләчәк җирләре хакында мәгълүмат бирелгән. Моны укыган кеше симсарсыз Шамны зиярәт итә алачактыр. Хәзер мәзкүр китапны тагы зуррак рәвештә һәм Шамның харитасы, мәшһүр зиярәт җирләренең рәсемнәре илә бергә бастырып чыгармакчы. Талиб әфәнде, уңае килсә, хаҗга кадәр бер номер ачмакчы. Әгәр бу ачылса, гарәп мәркәзендә бер татар номеры булачактыр.

Вакыт. – 1914. – №1499. – 1 июнь.

*Текстны басмага **Ләлә Мортазина** әзерләде* ■



Риза казый нәселе

(Ризаэддин Фәхреддиннең кызы Әсма Шәрәф белән аралашу тарихы)

Рәфкать Шаһиев

Исәнме, туганым Рәфкать!

Безнең зур хәсрәт булды. Нык авырганнан соң, әннә вафат булды. Актыккы айны аяклары начар йөри иде. Кроватьтан ярдәмсез тора алмый иде. Соңгы көннәрдә сул аягы һәм сул кулы бөтенләй начар эшли башлады. Шимбә көннең (13/XI) төнендә әннә кроватьтан егылып төште. Кире яткыргач, бераз сөйләшеп ятты, аннан соң йокыга китте. Шимбә – көне буе йоклады, сулышы тирән һәм тыныч иде. Бәлки рәтләнеп китмәсме, дип уйлаган идем. Якшәмбе көнне әннә уянмады. «Скорая помощь» врачы, аңарда инсульт булган, дип әйтте. Бераздан сулышы туктады, өмет бетте...

Әннәне дүшәмбе көнне – 15/XI – Зәйнәб апасы янына күмдек. Туганнары, Марсель Әхмәтҗанов, минем эштән малайлар ярдәм иттеләр. Әннәнең теләге бар иде: Кичүчат мәчетендә берәр җомга намазыннан соң догалар укып, аның исемен искә төшерсәләр ярар иде, дигән сүзе.

Көтмәгән, авыр, күнегергә кыен хәл булды.

Арслан, 24.11.93.

Ахыры. Башы журналның 9,10 нчы (2018) саннарында

Исәнме, дустым Рәфкать!

Синең хатыңны (11.3.94) алдым. Бик озак килгән. Кичүчаттан Әлмәткә хәтле 12 көн барган.

Минем исәнлек әкренләп рәтләнеп килә. Февральнең уртасыннан эшкә чыктым. Зарланырлык булмаса да, тулысынча сәламәт хәлгә тиз генә ирешеп булмаска охшаган. Иртән зарядка ясыйм, витаминнар эчәм.

Ашарга әзерлим. Төшке ашка өйгә кайтам. Көннәр бик тиз үтеп китә. Ташкенттан хат килгән иде, Альмира апа, Диләрә апа исән-саулар.

Сездә музей ачылса, яхшы булыр иде. Җәл, әннә ул көннәрне күрә алмады. Ул эшнең мәшәкатьләре бик күп булыр әле. Казаннан ярдәм итмичә ул эшне урынына җиткереп булмас та. Туганнарыңа, Әнвәр абыйга, Самдун абыйга, Таһир абыйга сәлам, изге теләкләр.

Сәламәтлек теләп, Арслан.
31.3.94.

Исәнме, дустым Рәфкать!

Беренче Май бәйрәме котлы булсын! Минем март актыгында язган хатны алдыңмы? Синнән күптән хат юк. Мин беркөе эшләп йөрим. Сәламәтлек бик әкренләп төзәлә. Эштә хәлләр начар. Майның уртасына хәтле бөтен завод эшләми, эш хакы да түләнми.

Асия апа (әннәнең туганнан туганы, Кичүчатка бергә барган) мәчеткә мең сум садака җибәрмәкче иде, синең белән. Син хәзер генә Казанга килмәгәч, сиңа аның буш конвертын җибәрәм. Син ул конвертка мең сум сал да мәчеткә Асия апа исеменнән илтеп бир (акчаң булса, әлбәттә). Син Казанга килгәч, мин сиңа ул мең сумны бирермен. Почтовый перевод белән йөрисе килми.

Бөтен туганнарыңа, мине сораган танышларга сәлам әйт. Бөтенесен бәйрәм белән тәбриклим, сәламәтлек телим.

Сиңа да сәламәтлек, уңышлар телим.

Арслан, 30.4.94.

Исәнме, Рәфкать!

Синең хатыңны алдым. Сәламәтлегем беркөе. Әннәнең елын үткәрдек. Туганнар ярдәм иттеләр. Асия апа, Җәүдәт абый, Марсель Әхмәтҗанов, Булат Солтанбәковлар да килгәннәр иде. Әнвәр Хәйруллин больницада, диделәр.

Музейны урнаштырырга Казаннан кем килгән иде?

Зур калакны Зәйнәб апага туганнары бүләк иткәннәр, туган көненә. Бәләкәе, чәй эчә торганы – гаиләви кирәк-яраклардан. Андый зур калак бер генә. Ахрысы, аны комиссион кибеттән алганнардыр.

Туганнарыңа, танышларга сәлам.

Исәнлек-саулык теләп, Арслан.
28.11.94.

Брежневка хат

Бүгенге көндә туган-тумача, ата-бала арасында туганлык җепләре шактый бушады, сүтелеп бетте, дияргә дә мөмкин. Ризаэддин Фәхреддин нәселе бу яктан да күпләргә өлге булып торырлык.

1924 елда Риза казыйның институтта укыган кызы Зәйнәп белән кече улы Сәгыйтьне, дин әһеленең балалары, дип, институттан куып чыгаралар. (Ул елларда барлык дин әһелләренең балаларын шундый язмыш көткән.) Риза Фәхреддин,

нәселенең язмышына битараф карый алмаган ата кеше буларак, бу гаделсезлеккә каршы Мәскәүгә кадәр барып җитә, балаларының яңадан институтка алынуына ирешә.

Еллар уза. Совет хакимиятенең «кызыл кыршавы» галимнең игелекле хезмәтләрен бөтенләй кысрыклый башлый. Үзенә исә Советларга каршы шпионлык кылу яласы ягыла. Шулвакытта инде кызлары, Ризаэддин Фәхреддиннең намуслы исемен яклап, төрле оешмаларга мөрәҗәгать итәләр – хатлар юллыйлар, хаклык эзлиләр. Очрашуларның берсендә Әсма апа миңа КПСС Үзәк Комитетының генераль секретаре Л.И.Брежневка юлланган хатларының күчермәләрен биргән иде. Укучыларга да кызыклы булыр, дип, берсен игътибарыгызга тәкъдим итәбез. Оригиналлар галимнең туган авылындагы мемориаль музеенда саклана.

Уважаемый Леонид Ильич![1]

Обращаемся к Вам в связи с изданием книги З.А.Ишмухаметова «Социальная роль и эволюция ислама в Татарии» (Казань, Таткнигоиздат, 1979 г.), в которой дается ложное освещение деятельности нашего отца Ризаэтдина Фахретдиновича Фахретдинова (1859-1936).

В этой книге Р.Ф.Фахретдинов представлен как активный враг социалистического строя. Он обвиняется в антисоветской пропаганде, бегстве в Омск в 1918 г. и пособничестве Колчаку, в подрывной антисоветской деятельности, в проведении панисламистско-пантюркистской политики, в руководстве антисоветскими выступлениями мулл (стр. 64-73).

В книге приводятся ссылки на атеистическую литературу 1920-х годов. Об этих источниках можно сказать, что хотя они носили характер проявления бдительности, и в них нет утверждений об «антисоветской подрывной деятельности» Р.Ф.Фахретдинова, однако, они надолго затормозили объективное научное изучение творчества Р.Ф.Фахретдинова.

Не проявив критического подхода к атеистической литературе 1920-х годов с учетом современных требований объективности и законности, З.А.Ишмухаметов с твердой уверенностью утверждает виновность Р.Ф.Фахретдинова в тяжких контрреволюционных преступлениях.

Необходимо отметить, что Р.Ф.Фахретдинов известен как деятель дореволюционной татарской культуры, автор более 40 книг и брошюр, главный редактор журнала «Шура» («Совет», Оренбург, 1908-1918 гг.), историк-востоковед. Хотя взглядам Р.Ф.Фахретдинова свойственна историческая ограниченность, противоречивость, и у него были ошибки в оценке происходящих событий в 1918 г., деятельность Р.Ф.Фахретдинова не дает оснований относить его к врагам социализма. Членом каких-либо политических организаций он не состоял, политической деятельностью не занимался. Утверждение о том, что он выезжал в Омск с армией Колчака, является явно ложным.

В силу исторических обстоятельств жизнь Р.Ф.Фахретдинова была связана с религией. В 1891-1906 и 1918-1923 гг. он был членом Духовного управления мусульман в г. Уфе, в 1923-1936 гг. – председателем этого управления. Свои религиозные обязанности Р.Ф.Фахретдинов исполнял в границах действующих законов. Он не был судим, репрессиям не подвергался.

Наше обращение в Татарский обком КПСС с просьбой вскрыть ошибки З.А.Ишмухаметова не принесло желаемого результата. В ответе обкома 13 июля

[1] Хатның стилистикасы, орфографиясе һәм пунктуациясе оригиналдагыча бирелә. – Редакция.

1931 г. было выражено согласие с З.А.Ишмухаметовым. Нам кажется, что некоторые товарищи не вполне учитывают тяжести обвинений, выдвинутых З.А.Ишмухаметовым против Р.Ф.Фахретдинова.

Подрывная антисоветская деятельность, буржуазный национализм, руководство антисоветскими выступлениями являлись особо опасными уголовно наказуемыми деяниями. Такими деяниями занимаются компетентные органы государственной безопасности и правосудия, и только они (а не писатели-атеисты) вправе дать обоснованное и законное заключение о виновности человека.

Әсма һәм Арслан Шәрәф, Рәфкать Шаһиев. Казан, 1991 ел

Мы считаем, что обвинения против Р.Ф.Фахретдинова, содержащиеся в книге З.А.Ишмухаметова, не соответствуют действительности, не согласуются с линией Коммунистической партии на укрепление законности, противоречат статье 160 Конституции СССР, гарантирующей, что «никто не может быть признан виновным в совершении преступления ...иначе как по приговору суда и в соответствии с законом».

Мы обращаемся к Вам, уважаемый товарищ Л.И.Брежнев, с просьбой восстановить законность, дать компетентную и объективную оценку деятельности Р.Ф.Фахретдинова, воспрепятствовать распространению ложных сведений о его деятельности.

Фахретдинова Зейнаб Ризаэтдиновна,
Шараф Асьма Ризаэтдиновна,
23 июля 1981 г.

Йомгак урынына

Олуг Ризаэддин Фәхреддиннең кызы Әсма апа һәм оныгы Арслан абый бик яхшы, игелекле кешеләр иде. Ходай биргән озын гомерләрен бушка уздырмадылар. Әсма апа озак еллар буе Республика клиник хастаханәсенең физиотерапия бүлегендә шәфкать туташы булып эшләп, тәннәрне сәламәтләндерсә, үзенең җылы карашы, акыллы киңәшләре белән җаннарны савыктырып яшәде. Безнең күңелләрдә үзенең якты эзен калдырып, 1993 елның 14 ноябрендә бакыйлыкка күчте.

Арслан Шәрәф (1934-2003) Казан дәүләт университетының физика-математика бүлеген тәмамлап, лаеклы ялга киткәнче, инженер булып эшләде. Бик тыныч, сабыр, гаять миһербанлы угыл иде. Бабасы Ризаэддин Фәхреддиннең үзләрендә сакланган мирасын тулысы белән Кичүчат авылындагы мемориаль музейга тапшырды.

Икесе дә Казан шәһәренең Яңа бистәсендәге татар зиратына җирләнде. ■

Нияз хәзрәт Сабиров:

*«Тарикатьләр – экстремистик ислам агымнарына альтернатива»**

Безнең төбәктәге Ислам тарихы туры-дан-туры суфыйчылык белән бәйләнгән. Мөселманнар бер Аллаһка булган ихлас иманнарын күп очракта Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) рухи дәвамчылары аша кабул иткән һәм саклап калган.

Тәсаввуф-суфыйчылыкның Идел буенда бик күптәннән үк килгән тарихы, үзенчәлекләре бар. Идел буе Болгар дәүләтендә суфыйчылыкның төгәл кайчан барлыкка килүе турында әйтү кыен, ләкин XII гасырда болгарлар арасында Хуҗа Әхмәд Ясәви тарафыннан нигезләнгән ясәвия тарикате тарала башлый. XVIII гасыр ахыры-XIX гасыр башы татар тарихчысы Хисамеддин бине Шәрәфеддин Болгариның «Таварихе Болгария» («Болгар тарихы») китабында бу тарикать тарафдарларының исемнәре китерелә. Шунысын искәртергә кирәк: суфыйлар татарлар арасында Ислам дине таратуга шактый зур өлеш керткән.

Хәзерге мөселман яшьләре үз рухи традицияләрен, халкыбыз тарихын белми. Урта гасырлар татар шигърияте суфыйчылык белән тыгыз бәйләнгән. Күпчелек татар шагыйрьләре үз әсәрләрендә рухи һәм әхлакый камиллеккә ирешү турында язган. Тәсаввуф – ислам фәннәренең берсе, ул күңелне пакьләргә, камилләштерергә чакыра. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларындагы төрки-татар язучылары, шагыйрьләре әсәрләрендә без суфыйчылык образларын, принципларын очрата алабыз. Казан ханлыгы галимнәре ясәвия тарикате тарафдарлары булган. Алар арасында ихтирамга лаеклыларның берсе – Кол Шәриф. Тарихи чыганаклар буенча, ул 1552 елны руслар Казанны алган вакытта һәлак булган. Кол Шәриф шигъриятендә ясәвия традицияләре ап-ачык күренә. Мәсәлән, аның шигырьләренең берсе Сөләйман Бакырганиның улы Хөбби Хуҗага багышланган. Сөләйман Бакыргани (1111-1186) Әхмәд Ясәвинең шәкерте булган.

Казан ханлыгы яулап алынып, мәчет-мәдрәсәләр җимерелеп, үз ватаннарында дини белем алудан мәхрүм калган татарлар, ислам гыйлемен алу өчен, Урта Азиягә, аерым алганда Бохарага барырга мәҗбүр була. Ә Урта Азия – суфыйчылык киң таралган төбәк. Бабаларыбыз анда тәсаввуф юлына баса. Остазлары «яшерен белемнәр»гә ирешкәннәрнең кайберләренә рухи тәрбия эшен алып баруга рөхсәтнамә – иҗазәт биргән. XVII-XVIII гасырларда татар исламы күп очракта суфыйчылык идеяләре белән тиңләштерелә. Суфыйчылык, өстенлек итүче дини институт буларак, халкыбыз тормышының бар якларына да, гаилә мөнәсәбәтләреннән башлап, социаль-сәяси карашларга кадәр йогынты ясый.

*Апанай мәчете имам-хатыйбы, тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабировның бу мәкаләсе «Кулаткы укулары»ндагы чыгышы нигезендә әзерләнде.

XVII-XVIII гасырларда ясәвия традицияләрен Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди (1318-1389) нигезләгән нәкышбәндия тарикате алмаштыра. XVIII-XIX гасырларда күп кенә татар дин галимнәренең рухи остазлары нәкышбәндия тарикате тарафдары булган. Мәсәлән, шагыйрь, дин гыйлеме белгече Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834) – шәех Фәезхан әл-Кабулидан; мәгърифәтче, ислам галиме Габеннасыйр Курсави (1776-1812) – шәех Ниязкол әт-Төрекмәнидән; илаһият галиме, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) шәех Гобәйдулла бине Ниязколый, Габделкадыйр әл-Фаруки әл-Һинди, Мәзһәр бине Әхмәд әл-Һиндиләрдән рухи тәрбия һәм белем алган. Алар барысы да, шәригать нигезләрен өйрәнгәч кенә, тәсаввуф юлына басканнар һәм үз хезмәтләрендә: «Мөселманның беренче бурычы – хак иманга ия булу, икенче бурычы – фикһ мәсьәләләрен өйрәнү, бары тик аннан соң гына – тәсаввуф юлына басу», – дип язганнар.

1917 елдан соң татар мәдрәсәләре нәкышбәндия тарикатендә булган дин әһелләре тарафыннан күзәтүдә тотыла. Имам сайлаган вакытта халык лаеклы остазы булган намзәдкә (кандидатка) өстенлек биргән, ягъни суфый булмый торып, җәмгыятьтә абруй казанып булмаган. Совет чорында суфыйчылык татар халкының дини һәм милли үзенчәлекләрен саклап калуга хезмәт иткән.

XX гасырның 90 нчы елларыннан башлап, Россиядә суфыйчылык яңадан торгызыла башлады. Татарстанда традицион тарикатьләрнең тарафдарлары саны арта бара. Традицион тарикатьләр Исламның гүзәллеген һәм югары әхлагын чагылдыра, динебезнең әдәп принциплары таралыш алуга ярдәм итә. Тарикатьләр – экстремистик ислам агымнарына альтернатива.

Теләсә кайсы кешенең күңеленә ачкыч табарга була. Бу аны үгетләүче кешенең күңел пакьлегенә, аның халәтенә бәйле. Тарикать остазларының ихлас кичерешләре, белемнәре Исламның чын матурлыгын җиткерергә, Аллаһка, Аның Пәйгамбәренә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) булган саф сөюне тоярга ярдәм итә. Шуның өчен халыкның рухи традицияләрен торгызу, яшьләргә җиткерү аеруча мөһим. Нәкъ менә әлеге рухи кыйммәтләр татар мәдәнияте һәм сәнгатенең нигезен тәшкил итә дә инде – аларның берсен икенчесеннән аерып алу мөмкин түгел. Мәгълүм ки, ислам татар тормышының бар өлкәләренә дә – гаиләдәге мөнәсәбәтләргә дә, эшмәкәрлеккә, сәяси эшчәнлеккә дә йогынты ясаган. Татарларның тормыш рәвеше дин белән тыгыз үрелгән, ә дин әһелләре суфыйлар белән тиңләштерелгән.

Тәсаввуфның асылы – күңелләребезне сафландыру. XVII-XVIII гасырларда халкыбыз тормышы җиңел булмаган. Суфыйчылык, сабырлык, Аллаһы Тәгаләгә сыгыну, Аның рәхим-шәфкатенә өмет баглау кебек төшенчәләрне игътибар үзәгендә тотып, халыкта рухи ныклык тәрбияләгән. Бу карашлар безгә XVII гасырда яшәгән Мәүла Колый («Хикмәтләр»), XVII гасыр ахыры-XVIII башында яшәп иҗат иткән Суфый Аллаһияр («Сөбател гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк») китабы) кебек суфый шагыйрьләр иҗаты аша килеп ирешкән.

Мөселман – югары әхлаклы кеше дигән сүз. Намаз уку, ураза тоту, Аллаһка гыйбадәт кылуның башка төрләре безне яхшы якка таба үзгәртә, күңелебезне баета. Тәсаввуф рухи-әхлакый яктан камилләшүнең өстәмә ысулларын тәкъдим итә, безне тыйнаклыкка, сабырлыкка, игелекле гыйлемнәргә омтылырга өйрәтә. Хәзерге Кулаткы районының Яңа Зимничә авылында яшәгән мөдәррис Хәбибулла хәзрәт Хансөяров кебек тарикать остазларыбыз халыкны бервакытта да зөһедкә, бикләнеп ятуга өндәмәгән, киресенчә, җәмгыятьтә яшәргә, гаилә корырга, гомуми проблемалар белән көн күрергә, дөньяны яхшы якка үзгәртергә тырышырга, ләкин, шул ук вакытта, һәрвакыт Аллаһ белән булырга чакырган. Шәех Баһаветдин Нәкышбәнди болай дип әйткән: «Күңел – Сөеклегә (Аллаһка), ә куллар – эшкә». Аллаһы Тәгалә белән япа-ялгыз булуга караганда, Аллаһ белән җәмгыятьтә яшәү яхшырак. ■

КӘЧЕ ИЛЕ

Фоат Закиров*

КӘЧЕ ИЛЕ, ХИСМӘТ ҺӘМ ГАБДЕЛҖАББАР АВЫЛЛАРЫ

Казый Иле, Чура Иле, Тимерче Иле, Чыпчык Иле, Кәче Иле, Дәрвиш Иле кебек борынгы зур авыллар Казансу буенда урнашкан. Моның сәбәбе – үзара бәйләнешнең су юлы яки таулы елга ярлары буйлап салынган сукмак-юллар аша башкарылуында. Кәче Иле белән Иске Казанны Казансуның таулы уң як яры буйлап узучы җәяүле сукмак һәм ат юлы да тоташтырган. Бу юл безнең авылдагы Шамгал тавы буйлап та узган, аның эзләрен хәзер дә күрергә мөмкин.

Хәрәкәт өчен уңайлы җир булудан кала, әүвәлге кешеләр авылларга урынны чишмә, уңдырышлы елга үзәннәреннән, качу-ышыклану өчен җайлы һәм бер үк ва-

Кәче авылы күренеше

* **Фоат Дәүли улы Закиров** – авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, төбәкне өйрәнүче, Арча районының Кәче авылында яши.

ытта киек җәнлекләргә, җиләк-җимешкә бай урман-куаклык янынннан сайлаганын да онытмаска кирәк. Бу җир язгы сулардан өстәрәк һәм, күп очракта, кояш карый торган сөзәк тау битләрендә булгандыр.

Кишмәт, Абҗабар һәм Казансуга терәлеп үк торган Кәче Иле өчен дә бабаларыбыз гаять уңайлы урын сайлаган. Шуны да искәртик: Кишмәт һәм Абҗабар кебек урыс авыллары урынында Казан ханлыгы чорында татарлар яшәгән. *«Ул авылларның атамалары Хисмәт һәм Габделҗаббар исемнәреннән ясалган»*, – диләр иде бабайлар. Әлеге җирләрдә гарәп язулы борынгы кабер ташлары табылу да шул турыда сөйли. Калын, яссы ташларны, әзер төзү материалы буларак, урыслар өй фундаментларын салганда кулланган. Мәсәлән, Абҗабар авылы читендә, Түбән Аты авылы ягында яшәгән умартачы урыс карты, бер кабер ташын алып, йортының кайсыдыр җиренә яраклаштырган булган да Казан галимнәре кайтып, борынгы ядкәрне кире урынына куйдырган, дигән сүзләр йөрде безнең балачакта. Шул ук умартачы картның сөйләвенә караганда, һәр елда бәрәңге бакчасыннан кеше сөякләре чыккалаган. Әлбәттә, аларның борынгы бабаларыбыз сөякләре булуы бернинди шик уятмый.

Кишмәт татар зираты өстендә үк утырган, ә татар авылы бераз өстәрәк булган, диләр. Анда яшәүчеләр дә бәрәңге бакчасыннан кеше сөякләре чыгуы турында сөйли иде. Мәсәлән, Кишмәт авылында яшәүче бер кеше (исемен дә әйтергә була) гарәп язулы кабер ташын терлек абзары почмагынамы яки өенә керү юлынамы салган. Казан галимнәре кайтып, аны да кире урынына куйдырган, дигән сүз бар. Археолог Равил Фәхретдинов та: *«Кишмәт авылының нәкъ уртасында Казан ханлыгы чорының кабер ташы сакланган»*, – дип яза. Кызганыч, мал табибы Василий Иванович Карягин йорты каршындагы бу таш та, археологик ядкәрләр исемлегенә кертелүгә карамастан, вакытлар узу белән билгесез сәбәпләр аркасында юкка чыккан. Биредә кайчандыр зират булганын кабер урыннарыннан гына чамаларга мөмкин.

Кәче күршесендәге Бужа (Божа), Чулпан, Чүриле (Чура Иле) кебек борынгы татар авыллары да Казансу буенда, ләкин алар елганың сөзәк ягында, сул ярдан бераз өстәрәк, уңдырышлы кара туфраклы тигезлектә урнашкан. 1552 елда Казан яулап алынганнан соң, Казансу буендагы күп кенә татар авыллары бушап кала һәм алардан калган уңдырышлы җирләргә урыс алпавытлары, качкын крестьяннар килеп төпләнә. Явыз Иван гаскәриләре тарафыннан якындагы Арча каласы алынган вакытта һәм күрше-тирәдәге халык кырылганда, соңрак чукындырылганда да Кәче Иленең татар авылы буларак сакланып калуы гаҗәп күренеш. Хәзерге вакытта Бужа, Чулпан, Чүрилеләр (бу авыллар хәзер татарлашып бара) Арча шәһәренә якын булу һәм олы юл өстендә урнашу сәбәпле генә көн күрсә, Кәче күршесендәге Абҗабар һәм Кишмәтнең авыл буларак юкка чыгуына инде берничә ел.

КӘЧЕГӘ КАЙЧАН НИГЕЗ САЛЫНГАН?

1602-1603 еллардагы җан исәбен алу кенәгәсендә Казансу ***Каячий елгасы,*** дип язылган. Шуңа нигезләнеп булса кирәк, «Татар энциклопедиясе»ндә Кәче авылының нәкъ менә шул еллардан мәгълүм икәнлеге күрсәтелә. Әмма без бу фикер белән һич кенә дә килешмибез.

Кәче Е.И.Чернышевның тарихчыларга яхшы мәгълүм булган «Селения Казанского ханства (по писцовым книгам)» мәкаләсендә Арча юлы өстендәге авыллар белән бергә телгә алына. Шуннан өзек китерик: *«Если направляться вверх по Казанке, то первым населенным пунктом ее были две деревни Кульсеитова, Бурнашева, три деревни Шапши, дер. Ямучино и пустошь Шапша, Кабиковская. Далее следует деревни Клетни, Ямашурма, Ащерма, Сосмаги, Урмат, Куркачи. За ними дер. Иски Казань, Ка-*

маева, Чурилино, Бурнаш, Урсек, Бужа, Чулпаново, ***Качклня*** *и Хайван. Все эти деревни расположены по левому берегу р.Казанки до гор. Арск».* Мәкаләнең азагындагы «Список населенных мест периода Казанского ханства» дигән кушымтада исә авылыбыз ***«Кичель-Качелина, дер., Ар.д.»*** дип язылган.

Хисаметдин әл-Мөслими әл-Болгариның «Тәварихы Болгарийа» китабына мөрәҗәгать итик. Анда 1478-1487 елларда Казан белән идарә иткән Илһам хан һәм вәзирләренең Казансу башындагы Иштирәк Байтирәк углы, Курсадагы Гадел Әбдәл углы, **Кәче Иле**ндәге Зөлмөхәммәт хаҗи Мөхәррәм углы һәм башка авыллардагы изгеләрнең каберләрен зиярәт итүе турында язылган. Зөлмөхәммәт хаҗиның кабере авылыбызның борынгы өлешендә, Казансуның уң ярындагы зиратта яки якынтирәдәге башка каберлектә булган, дип уйлыйбыз.

Казан ханлыгында Кәче Иленең булуын 1548 елгы вакыйгаларны сурәтләгән «Хаҗи Гәрәй» дастаны да ачык дәлилли. Шуннан бер өзек китерик: *«Сәнә 954 җөмади әл-ахир аенда Солтан Илендә Солтан Гали углы Колчура башлык, Уймас Иленең Балтач бай бер ун кеше,* ***Кәче Иленең Кушай оста бер ун кеше****, Сәрдә Иленең Кылый Гали бай бер ун кеше, Чыпчык Иленең Ямгурчы билә Карил Курт бер ун кеше, Шабша Иленең Җан-җура бәк бер ун кеше, Вәнтә Иле белән Нурма Иленең Колурус, дагый Галикә бер ун кеше, Шәехзадә Иленең Кулуш мирза бер ун кеше, дагый бер ун ак чура, Туртөйле кибәк җирмеш Мөхәммәтбик бер ун кеше, Иске Йортның Ядкяр бай, Касыйм сәет бай бер ун кеше, Кара Дәүләт Иленең Кунак оста бер ун кеше, Хәерби Иленең Хафиз бер ун кеше, Кара Гайшәнең Тушанак бер ун кеше, Тимерче Иленең оста углы Нугай бер ун кеше – бу кем ирсәләр Хаҗи Гәрәй ханны падишаһлыкка алып килеп хан ясадылар».* Язмадан Кәче Иленнән ун кешедән торган гаскәри берәмлек тупланганы, гаскәрбашы, ягъни унбашы булып Кушай оста сайланганы ачык аңлашыла.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» исемле мәшһүр хезмәтендә Иванай бине Усай турында: *«Казан төбәгендә Кәче авылында имам вә мөдәррис булып, 1100/1689 елларда вафат иткән. Казан якларында нәселе күп. Мәшһүр Юныс әфәнде бу затның угылы булган»*, – дип яза. Ш.Мәрҗани мәшһүр имамның нәсел шәҗәрәсен дә искә ала: *«Иванай бине Габделхаликъ бине Шаһнәсәб бине Габделкадыйр бине Габделкәрим бине Габдеррәхим бине Габделмәннан бине Габдулла бине Мәсгудь бине Әбүзәр. Безнең гасырыбыздагы токымының гөманына караганда, нәсел-нәсәпләренең җеп очы изге сәхабәләрдән булган Әбүзәр әл-Гаффарига барып тоташа».* Кабер ташы турында болай дип яза: *«Бу вакытта Кәчедә Фулад бай дигән бер кеше була. Ахун һәм әлеге бай, яңа каберлек билгеләнгәч: «Кайсыбыз элек вафат булса да, шул яңа каберлекктә җирләргә», – дип, үзара килешкәннәр һәм икәве дә бер ел эчендә бер-бер артлы вафат булып, шул каберлектә күмелгәннәр. Каберләренә таш куелган, исемнәре, туу һәм вафатларының тарихлары язылган. Фулад байның 1101 (1689) елда вафат булганлыгы куелган ташыннан ачык билгеле булып тора. Әмма Иванай хафизның ташы искергән, вафаты 1100 (1689) елда микән, әллә 1102 (1690) елдамы дигән шик туа».* Иванай шәҗәрәсендә буыннар саны – 9. Кәчедә Ш.Мәрҗанигә мәгълүм кабер ташы 1689 елда куелганын искә алсак, Әбүзәр 1460 нчы елларда, ягъни Казан ханлыгы заманында Кәчедә яшәгән кеше булып чыга. Әмма аның чит төбәктән күчеп килгән булу ихтималын да инкарь итә алмыйбыз. Шунысы игътибарга лаек: Юныс бине Иванай (Иманай) әл-Кәчевинең нәсел вәкилләре әле бүген дә Башкортстандагы Кирдәс авылында яши икән. Күптән түгел генә Юныс бабасының эзләре буйлап унтугызынчы буын оныгы – Әхтәр Мәгазь улы Гайсин Кәчегә килеп, зиратта, Хәсәншәех җирлегендә булды һәм безгә үзе язган «Максют Юнусов и его потомки» китабын бүләк итте.

«Татар энциклопедиясе»ндә күрсәтелгән дата белән килешмичә, без Энциклопедия институтының төбәкләр тарихы бүлеге җитәкчесе Айдар Ногмановка хат яздык. Менә аның җавабы: *«По моему мнению, даже дата 1602-1603 гг. в Татарской энциклопедии слишком удревнена. Просмотрел источники 16-17 веков. Самое раннее упоминание о Качелино (в источнике Качелня) встречается в Переписной книге Арской дороги Казанского уезда 1678 г. Судя по книге, деревня была основана на несколько десятилетий раньше, т.к. пострадала во время эпидемии чумы 1650-х гг. Самый ранний надгробный камень на сельском кладбище датирован 1684/1685 г. Я предполагаю, что нынешнее Качелино возникло не раньше 1640-х гг., но на него могли наложиться исторические предания более раннего времени»*.

Әлбәттә, бу җавап та мине канәгатьләндермәде. Якын-тирәдәге иң кечкенә авыллардан саналган, бер урамлы Боҗа авылы да Казан ханлыгы чорында билгеле булганда, аңа караганда өч-дүрт мәртәбә зуррак, шул ук вакытта Казансуның уң ярындагы шактый уңайлы, күп чишмәле, зур болынлыклары, уңдырышлы туфрагы булган Кәче Иле ничек инде бу заманда булмасын ди?!

Кызганыч, Илһам хан вәзирләре белән зиярәт кылган Зөлмөхәммәт хаҗи Мөхәррәм углы каберенә һәм 1689 елда вафат булган Фулад бай, 1689-1690 елда бакый дөньяга күчкән Иванай хафизга куелган кабер ташлары хәзерге көнгә кадәр сакланмаган. Фулад бай һәм Иванай хафизлар җирләнгән яңа зиратның өске, уң почмагында тагын бер кабер ташы булуын мин дә хәтерлим. Аны мәрхүм укытучы Юныс абый Дәүләтшин: *«Бу кабер ташы мулла каберенеке. 1530 нчы елда җирләнде»*, – дип укыганы исемдә. Димәк, әлеге каберләрне искә алып кына да Кәче авылының Казан алынганчыга кадәр булганлыгы турында әйтә алыр идек. Кабер ташлары сакланмаса да, авылның иң әүвәлге урынындагы, Казансуның уң ярындагы зиратны тагын да борынгырак булган, дип гөман кылырга да нигез бар. Кызганыч, кабер ташлары бүгенгә кадәр сакланмау сәбәпле, андагы мәгълүматны тарихи чыганак буларак файдаланып булмый.

Хәзерге вакытта Кәче авылының яңа зиратындагы иң борынгы ташъязма 1685 елда вафат булган Корбан углы Сарбай каберенә куелган. Бу тарихи таш Казан-Арча юлы читендә, зират коймасына терәлеп үк тора. Ядкәр элекке эпиграфик традицияләр нигезендә эшләнү сәбәпле, Кәчедә әүвәлгерәк чорларда, ягъни Казан ханлыгы дәверендә дә шуңа охшашлы ташлар булганлыгы шик уятмый.

Сакланып калган язма чыганаклар һәм элек булып та хәзерге көндә юкка чыккан кабер ташы материалларына нигезләнеп, Кәче XVгасырның икенче яртысыннан ук, ягъни Казан ханлыгында билгеле авыллардан булган, дип уйларга тулы җирлек бар.

БАБАЙЛАР СҮЗЕ ҺӘМ БЕЗНЕҢ ФАРАЗ

Археолог Равил Фәхретдиновның Казан артына оештырган археологик эзләнүләре вакытында Кәче авылы яныннан болгар чорына нисбәтле чүлмәк ватыклары табыла. Археологик әдәбиятта, болгар чорына, ягъни XII гасырга нисбәтле Боҗа, Чүриле авыллары белән бергә, «Качелинское местонахождение»нең дә булуы турында әйтелә. Бәлки, чыннан да, Кәче болгар чорыннан ук яшәп килгәндер. Бу фикерне дә исбатлап карыйк.

Болгар дәүләте исламны рәсми кабул иткән 922 елдан соң, динне тарату өчен, Казан арты, хәзерге Арча-Балтач төбәгенә гарәп сәхабәләреннән гыйлем алган тәбигыйннар – Хәсән шәех Кадер углы, Балтач шәех Нәдер углы, Салавыч шәех Әбайдан углы, Исмәгыйль шәех Әбзан углының килүе риваятьләрдән мәгълүм. Алар тарафыннан Хәсәншәех, Балтач, Салавыч һәм Исмәил авылларына нигез салынган, имеш. Безнең

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

Кәче авылы кешеләре. Хәсәншәех җирендә корбан чалганнан соң

Кәче белән Кишмәт авыллары арасында (авылдан 2-3 чакрымда), Казансу елгасы буендагы Шамгал тавы итәгендә «Хәсәншәех» дигән изге җир бар. Гарәбстан тарафыннан килеп, безнең яклардагы халыкны ислам диненә дәгъвәт кылып йөргән ике кешенең берсе әлеге тау итәгендә вафат булып, шунда ук җирләнгән, диләр иде бабайлар.

Кәчедә электән калган бер йола бар. Авылдашларыбыз ел саен җәй башында изге урын – Хәсәншәехтә нәфел намазы укып, корбан чала. Бу йола хәтта совет чорында да онытылмады. Хәсән шәех турындагы риваятьнең бабайлар хәтеренә сеңеп, буыннан-буынга сөйләнә килүе һәм кәчелеләрнең әлеге тарихи урын белән рухи бәйлелекне тоеп, әрвахларны хөрмәт белән искә алулары безнең авылның Болгар дәүләте чорында ук булуына ишарә түгелмени?!

Җәүдәт Нәзировның әйтүе буенча, «Хәсәншәех» җирлегендә сазлык астында калып юкка чыккан чишмәләр булган. Кишмәткә таба сузылган Шамгал тавы уртасыннан бераз югарыда да чишмә бар. Шул чишмә тирәсендә борынгы бабаларыбыз яшәп, Кәченең борынгы зираты да шунда булган, диләр. Юкка гына «Хәсәншәех» җирлеген «Йорт асты болыны» дип атамаганнар инде. «Йорт асты» яки «йорт өсте» дип, гадәттә авылның элегрәк урнашкан урынына әйтәләр. *«Анда (ягъни «йорт астында») Касыйм дигән кеше яшәгәнен картлар хәтерли иде»*, – дип сөйләде безгә Җәүдәт абый. Рәфикъ Гайнетдинов та: *«Болынлыкка төшкән тау юлының уң ягында бер йорт урыны барлыгын хәтерлим»,* – ди. Әйе, өлкәннәр сөйләве буенча, борынгы авыл шунда булып, узган гасырның башына кадәр анда кешеләр яшәгән. XVI гасырда яулап алынган төбәккә, шул ук Хисмәт һәм Габделҗаббар авылларына урыслар килеп төпләнә башлагач, мөселманнарның бер өлеше читкәрәк китеп, хәзерге Кәче белән кушылган булса кирәк. ■

Ризаэддин Фәхреддин *гыйбарәләре*

● Сүз сөйләү вә тик тору тиешле булган урыннарны белергә кирәк.

● Сүз сөйләүдә булган бөтен хасият вә мәгънә – тәэсир бирә алудадыр. Сүзнең әсәре булмаслыгын белә торып, сүз сөйләүдә мәгънә юк.

● Тик тору сәбәпле сүз төзәлми, бәлки бозыла. Тик тору сәбәпле хәтер зәгыйфьләнә, хис начарлана. Тел никадәр күп селкенсә, шулкадәр яхшылана, остару хасил итә, тик тору сәбәпле ялкаулана, эшлексезләнәдер.

● Кирәк чакырылып вә кирәк чакырылмый килгән булсын, кунакка хөрмәт итү – Ислам дине каршында гүзәл холык.

● Бер аш мәҗлесендә ике, бәлки өч сәгать кадәр гомер үткәрү вә килмәгән кешеләрне көтеп утыру, сөйләнә торган сүзләрнең сафсата вә лаклакадан гыйбарәт булулары – иң күңелсез вә мәгънәсез нәрсәләрдер.

● Күршеләрне сүз яки гамәл белән рәнҗетү вә аларны җәфалау – Ислам хөкеменә күрә гөнаһ бер эштер.

● Исерткеч эчү, әфьюн йоту вә гомумән, һәртөрле бозыклыкларга дучар булучыларның күпләре – башка иптәшләре хәтере вә юлдашларының күңеле өчен моңа керешеп тә, соңыннан шуларга әсир хөкемендә калган кешеләрдер.

● Бик күп адәмнәр балаларын бер мәктәпкә яки бер мөгаллимгә тапшыру белән бала укыту хакындагы өсләрендә булган бурычның тәмам булганлыгын игътикад итәләр. Бу игътикад – ялгыш. Мәктәпкә вә мөгаллимгә тапшыру белән генә бала укыту хакындагы бурычның уннан бере генә табылган буладыр. Моның тугыз өлеше исә – ул бала мәктәпкә йөриме, сабакларын калдырмыймы, дересләрен белеп вә аңлап барамы, тәрбиясе вә әхлагы урынындамы, бозык иптәшләргә кушылмыймы вә шуның кебек хәлләрне тикшерүдәдер.

● Яхшы хатыннар күктән төшмиләр, диңгездән чыкмыйлар, бәлки үз арабызда үсәләр. Яхшы хатыннар җитештерер өчен, яхшы тәрбия вә зур иҗтиһадлар кирәк. Бу вазифа исә ирләр өстендәдер.

● Гаилә әхвәле төзек булмаган, гаилә хәяты урынына урам хәятын ихтыяр иткән, чәй вә мәйханәләрдә бушка гомер, мал сарыф итүгә гадәт кылган милләттә хәят вә дәвам тәрәккый ихтималы юктыр.

● Яхшы хатынга очраган кеше шуны Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте дип белергә вә һәрвакыт шөкрана кылырга тиешле.

● Хатыннарны бозучылар вә яман хатын исеме алуларына сәбәпчеләр – күбесенчә, бозык вә оятсыз ирләрдер.

● Дин белән дөньяның бергә җыелулары мөмкин. Әмма гыйлем белән дөньяны бер вакытта җыю мөмкин түгел. Ошбу хикмәт өчен дә гыйлем белән шөгыльләнүчеләр күп вакытта фәкыйрь булалар.

● Зарурат булмаган вакытта мөфти вә казыйлар, имам вә мөәзиннәр, мөдәррис вә мөгаллимнәр халык ярата торган формада йөрергә, аеруча, тәфсир вә хәдис, сиярәт вә фикъһе фәннәреннән мөгаллимлек итә торып, Пушкин вә Лермонтовка охшау нияте берлән ачык, пумала баш булып йөрмәскә тиешле. Дин мөгаллиме белән гимнастика мөгаллиме арасында, землемерное училище шәкерте белән дини мәдрәсә шәкерте арасында азрак аерма күрелергә тиешле.

ЯЗУЧЫ ХӘБИР ИБРАҺИМГА – 60 ЯШЬ

Дөнья гаме – садә җанында

Ләбиб Лерон

Олыгаябыз, ахры. Әле кайчан гына, туган авылы Борнаш урта мәктәбен, аннары Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлаган, берара Апас мәдәният йортында методист булып эшләп, халык театрында уйнап йөргән, шулчакларда, моны мин дә булдырам бит, дип әллә ни артык һаваланмый гына, әмма максатчан үҗәтлек белән кулына каләм алып, каударланып, илаһи мизгелләр кичерә-кичерә, тәүге драматик әсәрләрен язарга тотынган, шул ук вакытта, ыгы-зыгылы тормыш мәшәкатьләрен үз көенә җайлаштыра-җайлаштыра, ныклы адымнар белән Әдәбият Капкасыннан түргә, бер очтан шигърият бакчасына да, хикәя-хикәят болынына да үз сукмагын салган Хәбир дә – безнең замандашыбыз, каләмдәш дустыбыз Хәбир Ибраһим да! – «җилле яшенә», кем әйтмешли, пачти гомеренең алтын көзенә якынлашкан бит, әй! Әмма, никтер, моңа бер дә ышанасы килми. Ышанмаска саллы дәлил дә бар сыман – үз яшеннән артык яшь күренә Хәбир: кем әйтмешли, гәүдә – ыспай, йөреш-хәрәкәт – җитез, йөз-кыяфәт – кәртинкә. Ләкин, нишләмәк кирәк, бу – факт. Фактны һәм вакытны алдап булмый, диләрме әле?! Әйе, чынбарлык нәкъ Мөдәррис Әгъләм күзаллаганча шул: «Килеп төшә вакыт, яньчә генә...»

Мөдәррис Әгъләм, дигәннән, әлеге күренекле шагыйребез – Хәбир Ибраһимның рухи вә мәгънәви остазы. Хәбирнең иҗади эшчәнлегенә, аерым алганда, аның шигъриятенә тәүге уңай бәяләмәне биреп, заманында ул болай дигән иде: «*Гадәттә, башлап язучылар фикерләренең һәр кисәген дүрт юлга сыйдырырга тырышалар. Аларны моңа тәҗрибәсезлек, мәҗбүри рифма кануны куып кертә. Беренче шигырен укыганда ук мин аның нәкъ әнә шул кысалардан чыга алу мөмкинлеген күрдем:*

Төнгә чыксам,
Төннәр мине яклый,
Сердәшләрем алар, кунагым,
Үз-үземә бәхет даулый-даулый,
Каләм алам кулга, уйларым
Талгын гына җирдән күтәрә дә
Алып китә мине еракка...

Шигырь, строфа эченә генә сыймыйча, көчле агым булып дәвам итә, бу шагыйрь өчен бик тә һәйбәт сыйфат».

Яшь каләмдәшенең шигырьләрен тәфсилләп укыган олуг шагыйребез, алда әйткәннәрен куәтләп, мондыйрак гомумиләштерү дә ясаган иде: «*Хәбир, нигездә, мәхәббәт лирикасы шагыйре. Безнең соңгы җитмеш-сиксән еллык шигъри хәрәкәтебездә бу төр каләм ияләре ятим вә ятимәләр кебек кагылып-сугылып килделәр. Моңа, әлбәттә, безнең өстә торган тоталитар системаның кануннары гына гаепле түгел иде. Дөрес, бу кануннар халыкны шундый шартка куйды ки, аның шагыйрьләре дә дәүләткә, аның юлбашчыларына, кызыл бәйрәмнәргә мәдхия җырларга мәҗбүр иделәр.*

Шулай да татар шигърияте Кол Галинең «Йосыф-Зөләйха»ларыннан, Кандалыйның «Сәхипҗамал»ларыннан килгән Олуг Мәхәббәт лирикасын читкә тибәрмәде. Ул Бабичта чәчәнлек белән үрелеп яңгыраш алды. Шуннан ялганып, Рәдиф Гаташ, Равил Фәйзуллин, Зөлфәтләрдә яңа төсмерләр алып баеды.

Алда әйткәнемчә, шагыйрьләр эчке хисләрен яшерергә мәҗбүр иделәр, чөнки башкалардан ким-хур булмыйча дөнья көтәргә кирәк иде. Хәбир моны үзенең шигырендә гаҗәп оста тота алган:

Сөйгән ярым, без соң нишләдек?!
Кайда калды яшьлек җилкәне?
Ах, без бушка гомер үткәрдек:

Дөнья кудык,
Дөнья җитмәде...»

Олпат остазының, шулай ук, Ркаил Зәйдулла (*«Аның шигырьләре – тын су кебек... Ләкин төп агым аста – ул бер алгысына, бер сүрелә...»*) һәм Мансур Вәли (*«Аның өчен иң мөһиме – эчкерсезлек, садәлек, хәтта гадилек...»*) кебек могтәбәр әдипләребезнең этрафлы бәяләмәләре дә Хәбир Ибраһимга иҗат дөньясында үз юлын, үз кыйбласын табуда зур этәргеч булды, дип шикләнмичә әйтергә ярыйдыр.

«Аһәң» дигән шигъри китабын укыган вакытта, шәхсән, игътибарымны Хәбирнең ошбу дүртьюллыгы аеруча җәлеп иткән иде:

«Мин авылның һәрбер талын беләм,
Беләм һәрбер кошның оясын.
Мин авылның яшәү серен беләм,
Килә инде җанын тоясым!»

АВЫЛның, шул нисбәттән, анда гомер итүче БАРЧА КЕШЕнең дә – олысын-кечесен бердәй якын күреп, *җанын тоясы килү*, ягъни Галиҗәнап Табигатьнең вә Тереклек-Яшәешнең асыл нечкәлекләренә *төшенергә омтылу* – һәр талантлы әһле каләм иясенең дә һәм, әлбәттә, Хәбир Ибраһимның да изге мәсләгән, М.Әгъләм әйткәнчә, Ак Максатын анык белдергән, чынбарлыкка әверелү ихтималы булган хыялый бер ЯКТЫ ТЕЛӘКТЕР ул.

Шундый теләк белән януы Хәбирнең киңкырлы иҗатында аеруча чагылыш таба.

Беренче шигырьләре 1990 елда «Идел» журналында дөнья күргән Хәбир Ибраһимның шигъриятенә беркадәр басым ясавым тикмәгә түгел. Әдәбиятта чын мәгънәсендә *шигъри сүз* әйтә алган шагыйрьләр бихисап. Әмма алар арасында, башка жанрларны да бердәй якын күреп, игътибарга лаек әсәрләр тудыручылар бармак белән генә санарлык. Хәбир, һичшиксез, соңгылар рәтенә керә.

Апас районындагы Борнаш урта мәктәбенең 5 нче сыйныфында укыганда. Өченче рәттә сулдан беренче – Хәбир Ибраһимов. 1971 ел

Заманында аның театр уйнап йөрүе (үзе оештыручы да, үзе режиссер да, үзе артист та!) эзсез үтмәде, әлбәттә: Хәбир, берзаман, чын-чынлап пьесалар язарга тотынды, ул да булмады, яшь драматургның «Җырлап керәбез, җырлап чыгабыз» дигән беренче әсәрен режиссер Рөстәм Фатыйхов үзе оештырган «Адым» театр студиясе сәхнәсенә алып менде...

Хәтерлим әле, Хәбир берара Казан телевидениесендә редактор булып эшләп алды. Шулвакытларда бик популяр булган «Җомга көн кич белән» һәм «Афәрин» тапшыруларын әзерләүдә катнашты ул. Бу күркәм эшләрнең үзәгендә кайнаулар Хәбир Ибраһимның тагын бер сәләтен – аның журналистлык талантын ачуда билгеле бер роль уйнады, дип саныйм. Хәер, бусы сүз уңаеннан гына әйтелде. Менә шул телевидениедә эшләгән чорында Хәбирнең пьесалары буенча «Калай этәч», «Дәмдинов һәм Дәмин маҗаралары» исемле телеспектакльләр төшерелде. Шуннан соң яшь драматургның «буасы ерылды»: 1993 елда Әлмәт татар дәүләт драма театры аның «Артык гомер» (режиссеры – З.Туишева) исемле әсәрен, 1996, 1998 һәм 2005 елларда Минзәлә татар дәүләт драма театры «Кызыма килер йөз кеше» (режиссеры – Л.Садриев), «Газиз ярым» (режиссеры – Б.Бәдриев), «Җиденче кияү» (режиссеры – М.Мөбәрәков) дигән комедия һәм драмаларын сәхнәгә куйды. К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры исә Хәбир Ибраһимның «Бәхетле килен» (режиссеры – З.Харисов) комедиясен, шулай ук, Г.Кариев исемендәге Яшьләр театры белән Түбән Кама драма театры «Килмешәк» (режиссеры – А.Зарипов) һәм «Канатлы бозау», «Хатыным-алтыным», «Мөхлис һәм Иблис» драмаларын сәхнәләштерде. Уфа, Эстәрлетамак һәм Оренбург театрлары да драматург белән һәрдаим иҗади элемтәдә булды. Һәм хәзер дә алар үзара дустанә мөнәсәбәттә, дип беләм.

Хәбир, Г.Камал театры оештырган «Татар пьесасы» конкурсында катнашып, күп мәртәбәләр лауреат булды. Каләмдәшебезнең әлеге уңышларын – аның драматургия өлкәсендәге талантын янә бер кат раслаучы дәлилләр, дип аңларга кирәктер.

«Ялгыз тәкәрлек» – авторны киң катлау укучыларга һәм күп санлы тамашачыларга таныткан әсәр исеме бу. Җөмләмдә тамашачыларны телгә алып ялгышмадым: Татарстан телевидениесе 2002 елда драматургның шушы әсәре буенча өч серияле фильм (режиссеры – Г.Ширгазин) төшергән иде. Фильм һәм анда яңгыраган «Син – минем бердәнбер» җыры (көй авторы Гөлнара Исмаева фильмда, Гөлсирин ролен башкарып, әлеге җырны үзе җырлады) халыкта үз вакытында киң яңгыраш тапты:

«Төнге ай нурында, якты күл ярында
Яктык без яшьлекнең учагын.

Казан мәдәният институтында укыган чак. Беренче рәттә сулдан икенче – 276 нчы төркемнең академҗитәкчесе Шамил Зиннур улы Закиров, икенче рәттә сулдан беренче – Хәбир Ибраһим. 1977 ел

Дуслары янында. Сулдан уңга: Ркаил Зәйдулла, Хәбир Ибраһим, Рамил Төхфәтуллин, Ләбиб Лерон. 2008 елның мае

Син – минем бердәнбер, мин – синең бердәнбер,
Кил, бәгърем, кил, ачып кочагың.

Тәкәрлек, тавышың үзәкне өзәрлек,
Бир канат очарга, күкләрне кочарга.
Юк чамам түзәрлек, бир канат очарга,
Күкләрне кочарга, кочарга...»

Фильм турында матбугат битләрендә байтак уңай фикерләр әйтелде. Бу урында шулардан берсен – Хәбир Ибраһимның күренекле якташы, Татарстанның халык шагыйре **Шәүкәт Галиев** әйткәнен искә төшерү урынлы булыр: *«Фильмдагы вакыйгалар безнең яшьлек чорындагы хәлләрдән башлана. Бүгенге яшьләрне бер искәртү кебегрәк тә бу: нинди генә заманда яшәмәсен, кеше үзен – җанын-вөҗданын сакларга тиеш! Уйландырырлык тема...»*

Нәстә-нәстә, кәҗәгә – кәбестә, дигәндәй... Уйландырырлык темаларны табарга оста Хәбир дус. Ул темаларны ачарга, чишәргә үзенчәлекле таланты да, үткен каләменең карасы да җитәрлек аның.

«Нафига ханым», «Ялгыз каен күзе», «Утрау» кебек соңгы елларда иҗат иткән пьесаларын яисә «Тояклы җен», «Төнге шаяру», «Хәләфчик» дигән бәяннарын, «Арыш арасыннан йөгерүче бала», «Соңгы кыңгырау», Илаһи зат» исемле хикәяләрен генә алыйк – бу әсәрләр барысы да темаларының актуальлеге, мавыктыргыч эчтәлекләренең фәлсәфи тирәнлеге, төрле катмарлы вакыйгалар чолганышында калган персонаж-геройларның тормышчан сурәтләнүе белән укучы игътибарын үзенә җәлеп итә. Быел Татарстан китап нәшриятында аның «Бәхетсез җаннар» дигән яңа китабы дөнья күрде.

Сүземне йомгаклап, алдагы көннәрең – ямьле, тормышың, иҗатың һәм, әлбәттә, садә җаның һәрвакыттагыча гамьле булсын, Хәбир дус, дигән теләктә калам!

Редакциядән:

Танылган драматург, прозаик һәм шагыйрь Хәбир Ибраһимны ихлас күңелдән гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Аңа сәламәтлек, иминлек белән хәерле озын гомер һәм тамашачыларны, укучыларны әле озак еллар буе яңа әсәрләре белән сөендерүен теләп калабыз. ■

«БУА ТАЛИЯСЕ»

Миләүшә Хәбетдинова

Буа шәһәрендә икенче ел инде «Буа Талиясе» дип аталган театр лабораториясе уза. Аның атамасы, бер яктан, юнаннар мифологиясендәге комедия һәм җиңел поэзия алиһәсенә ишарә ясый. Икенче яктан, гарәп теленнән «зәвыклы», «якын», «ягымлы» дип тәрҗемә ителгән һәм татар кешесе өчен гаять үз булган кеше исемен белдерә. Лабораториянең максаты – хәзерге заман комедиясенең форматын һәм мөмкинлекләрен күзаллауны арттыру.

Бу көннәрдә театр яңарыш кичерә, көндәлек мәшәкатьләреннән арынып тора. Ул коллективка читтән чакырылган режиссерлар белән эшләп карарга, яңа форматтагы спектакльләрне сәхнәгә куярга мөмкинлек бирә. Тәнкыйтьчеләр шунда ук әлеге тәҗрибәгә карата фикерен һәм мөнәсәбәтен белдерә, ә бу, үз чиратында, театрга дөрес нәтиҗәләр ясарга һәм үзенең үсеш юлын чамаларга, ачыкларга ярдәм итә. Лабораториянең соңгы көнендә Буага башка театрлардан артистлар, режиссерлар, драматурглар, тәнкыйтьчеләр, Мәдәният министрлыгы, район хакимияте, матбугат чаралары вәкилләре җыела. Әлеге театр чарасы шәһәр тормышының мөһим вакыйгасына әверелә.

Лабораторияләрнең төп идеологларыннан булган Олег Лоевский репертуарлы театр өчен мондый форматның чистарыну – «клизма» ролен үтәвен ассызыклый: *«Репертуарлы театрның тормышы һаман бертөрле: пьеса сайлау, репетиция, премьера, прокат. Мәгънәсез интригалардан һәм хакимият алышынудан гайре, театр һичнинди яңалык кичерми. Лаборатория шул кимчелекне бетерергә, тынчулыкны җилләтергә, сафландырырга алына. Бу эш драматургиядән башлана...»* [1]

[1] Лоевский О. Опыт театральных лабораторий // Все о культуре Бурятии // URL: http://minkultrb.ru/news/detail.php?SECTION_ID=95&ELEMENT_ID=4865 (мөрәҗәгать итү вакыты: 09.09.2018)

ВАЛ

«Буа Талиясе»нең идеологлары булып Алексей Вислов (Мәскәү), Нияз Игъламов (Казан) һәм Раил Садриев (Буа) тора.

Быелгы, тәртип саны буенча икенче лаборатория Ркаил Зәйдулла әсәрләре буенча эшләнгән «Мылтык» («Мишәр хикәяләре») эскизы белән ачылды. Режиссер Егор Чернышов, спектакльне куйганда, Буа театры артистлары өчен сәхнәдә уйнауның яңа шартларын тудырырга тырышты.

Сәхнә алдыннан өскә үрләтелгән баулар әлеге гаилә-көнкүреш кыйссасы геройлары чорналып беткән пәрәвез җепләрен хәтерләтә. Менә җәймә артыннан әкренләп хатын – ир – балдыз «мәхәббәт өчпочмагы» контуры сиземләнә башлый; геройларның хисләре исә соңгы чиккә җитеп ташый. Яшәеш / үлем пространствосы котылгысыз рәвештә өчпочмакны хәтерләтә: аның үзәгенә йә җайсыз *сиртмәле карават*, йә тупас юнылган *утыргыч* урнаштырыла. Герой әлеге кысалардан ничек чыгып качарга белмичә изалана. Тормыш торгынлыгы сәхнәдә нәкъ Антон Чехов рухында сурәтләнә. Мылтык көнкүреш деталеннән маскулинлык (чын ирлек) символына әйләнә. Әлеге тенденция Ирек Гайнетдинов героеның кием детальләрендә дә чагылыш таба: солдат ботинкалары, свитер... Хатын-кыз персонажлары системасында капма-каршы кую принцибы хакимлек итә. Гөлназ Гыйззәтуллина тудырган хәрәкәтсез образга яшәеш энергетикасы таратучы Диләрә Садриеваның җилбәзәк-шаян образы каршы куела. Мондый вакыйга теләсә кемнең тормышында булырга мөмкин. Дөньяның теләсә кайсы почмагында шундый хәлләр булып тора да. Тамашачы күз алдында барган гаилә

драмасының сюжетын исә «Ай булмаса, йолдыз бар, апасы үлсә, балдыз бар» дигән халык мәкаленә сыйдырып була. Сәхнәдәге персонажлар татар аңындагы мишәрлек төшенчәсенә берничек тә тәңгәл килми[2].

«Сөеш, көмешкә һәм шайтан тартмасы» эскизы Максим Курочкин драмасы нигезендә туган. Әсәрне танылган драматург Хәбир Ибраһим тәрҗемә иткән. Без бу эскизны ремейк дип атау яклы, чөнки тәрҗемәче әсәрнең сәнгати ягын кабатланмас татар юморы һәм татар язучылары арасында йөргән мәзәкләр, гайбәтләр белән баеткан. Төп герой – язучы, урта яшь кризисының чираттагы корбаны (Раил Садриев). Ул тамашачының күз алдында үзенең өч начар гадәтеннән арынырга тиеш: Көмешкә – Ильяс Юнысов, Сөеш – Рамил Шәйхетдинов, TV – Тимур Шиһапов. Режиссер бу образларны җиңел танып алырлык типажларга әверелдергән. Шул рәвешле, арык «очкарик»ның Шайтан тартмасы булуы аңлашылып тора, мәкерлелеге белән дә сөйкемле тоелган Юнысов персонажында – Көмешкә ачык чалымлана; тотнаксызлык, үзен артык иркен тоту – Сөешкә хас. Вакыйга үсә-үзгәрә барган саен драма фарска әверелә бара. Режиссер Алсу Галина (Уфа) актерларны *яңа драма* юнәлешенең төп күрсәткечләреннән булган *автодеконструкция алымына* нигезләнгән комедия белән таныштыра.

Гадәттә әхлаклылыкны чагылдырган язучы образы әлеге эскизда әхлаксызлык күренешенә әверелгән. Күзгә бәрелеп торган антиэстетизм гомум картинаның принцибы булып җитешкән. Актерлар эшендә бу аерата ачык күренә, алар сәхнәдә тудырган образларны ничек тә әдәпсезрәк, тупасрак итеп уйнарга тырыша. Эскизда табигый йомышларны үтәү кебек гамәлләр дә «уйнала».

Тәрҗемәче Хәбир Ибраһим әсәрнең татарча вариантын оригиналда очраган сүгенү сүзләреннән арындырырга тырышса да, кайбер сүзләрнең аерым урыннарда әйтелеп китүе (мәсәлән, «мандовошки») тамашачыларны дертләтеп алгалады.

Персонажларның диалоглары кәрт сугуны хәтерләтә: араларыннан кайсысы уеннан очып чыгачак? Үткен репликалар атышу бик кызу һәм экспрессив рәвештә бара. Вазгыять ташкыны төп геройны әвәрә китерә *(куласа мотивы)*, ул аңа һични сайларга мөмкинлек бирми. *Куласа* структура оештыручы образга әйләнә. Режиссер кысалау алымыннан бик уңышлы файдалана. Без *тормыш куласасы* (биредә куласа – фокус) бозылганга күрә тирән кризис кичергән кеше белән танышабыз. «Мин кем?»; «Алга таба ничек яшәргә?» кебек интим, фәлсәфи сорауларга җавапның шулкадәр гади рәвештә, примитив һәм тупас образлар (костюмнар) аша табылуы тамашачыны тетрәндерә.

Өченче эскиз актерларны иммерсив театр белән таныштырды. Шуңа күрә «Централ-парк Вест»ның куелышы (режиссер – Степан Пектеев, Санкт-Петербург) шәһәр паркында булды. Нәтиҗәдә, тамашачылар спектакльгә тулысынча күмелә алды. Актерлар локацияне һәрдаим алыштырып торды, «операторлар», кадрга туры китерергә тырышып, тамашачыларны бер урыннан икенче урынга күчереп йөртте. Шашынулы авазлар өермәсендә сүзләр еш кына аңлашылып бетмәде. Оригиналтекст күп урында бөтенләй инкарь ителде. Спектакльдә, артистлар белән бергә, театр түгәрәгенә йөрүчеләр дә катнашты – артистизмнары гаять табигый тоелганга, тамашачылар аларны үз итте. Көндәшләрнең (К.Шәрифҗанова, А.Җаббарова) фонтан эчендә сугышулары халыкны телдән яздырды. С.Пектеев бер-берсен ишетергә теләмәгән затлар арасындагы мөнәсәбәтләр проблемасын җиткерергә теләсә дә, бәхетсез кешеләрнең мәңгелек көрәше тамашачыны илһамландырмады, киресенчә, ялкытты гына. Ул эскиз эшләнеп бетмәгән, дигән тәэсир калдырды.

---

[2] 30 октябрьдә Буа театрында «Абага» («Мишәр хикәяләре») спектакленең премьерасы булды. Хәбетдинова М.М. «Инкыйразга йөз тоткан» мишәрләр (Ркаил Зәйдулланың «Абага» спектакленә рецензия // Мәдәни җомга. – 2018. – №41. – Б.14.

Фотолар
Буа театры
архивыннан
алынды

«Буа Талиясе»нең аерым игътибарга лаек өлеше Гогольнең «Өйләнү» әсәре буенча эшләнгән эскиз иде (режиссер – Антон Безъязыков, Кемерово). Туй сюжеты, тамашачы өчен көтелмәгәнчә, офис пространствосына күчерелгән. Тәгәрмәчле офис урындыклары (офис «планктоны» символы) спектакльдә декорацияләр вазыйфасын башкарды. Режиссер ихтыярына буйсынып, алар әле сәхнә үзәгенә чыгарылды, әле артка этәрелде. Эскизның структура оештыра торган кисәге – татарча бишек җыры, тәгаенрәк әйткәндә, аның да балага матур киләчәк, яхшы һөнәр юраган өлеше булды. XX гасыр офис урындыклары һәм борынгы бишек җыры Гоголь әсәренең бүген дә актуаль булуын, исәп-хисапны күздә тоткан никах проблемасының беркайчан да юкка чыкмаячагын ассызыклады. Эскиз структурасына вакыт-вакыт үтеп кергән пантомима күренеше тамашачыларны ихлас көлдерде. Үзләрен икенче ел артист сыйфатында сынап караган Н.Игъламов белән А.Висловны халык аеруча җылы кабул итте. Җөмләдән, татар сәхнәсендә А.Висловның елдан-ел остара баруын искәртеп узыйк: Мәскәү кунагының татарчасы тагын да шомара төшкән иде.

Узган елгы беренче лаборатория бик күркәм нәтиҗә бирде: «Концлагерьчылар» эскизы, тулы канлы спектакльгә әверелеп, Буа театрының репертуарына алынды.

Быелгы, икенче лаборатория беркадәр сагайтты, дисәк, ялгышмабыз: ашыгыбрак эшләү, «штурмовщина» рухы сизелде. Лабораториянең «чит» драматургия материалына таянуы да шөбһәләндерми түгел (хәер, моны бүгенге милли театрлар кичергән «репертуар ачлыгы» белән акларга мөмкин). Шулай да, әлеге эскизлар Буа театры сәхнәсен баетырлык спектакльләр булып оешып бетәр, дип ышанасы килә. Татар язучылары да мондый лабораторияләрдә катнашса, хәзерге заман драматургиясенең үсеш тенденцияләре белән якыннанрак танышса, яхшы булыр иде, дип уйлыйбыз. Чөнки икенче һәм дүртенче эскизларның уңышын, нигездә, татар тәрҗемәчеләренең (Хәбир Ибраһим, Габдулла Шамуков) тырышлыгы тәэмин итте. Чакырылган режиссер милли драматургия материалын начар аңлый, сәхнәдә чын татар әсәре тудыра алмый. Ул проблематиканы гомум кешелек дәрәҗәсенә чыгара. Бу исә, ни кызганыч, татар театрын милли мәдәниятне саклау бурычыннан читләштерүгә китерергә мөмкин. Мондый проектта читтән чакырылган режиссерларның татар язучылары белән бергә, берлектә эшләве, безнеңчә, «Буа Талиясе» кысаларындагы хезмәттәшлекнең нәтиҗәле үрнәге була алыр иде.

*Урысчадан **Миләүшә Талипова** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

МАНЬЧЖУРИЯ

Бу җирләр рәсми яктан Кытай дәүләтенә керә. 17 декабрь көнне мин менә шул Маньчжурия станциясенә килеп җиттем. Биредә дә безнең дус-иш бар икән. Чиләбедән Маньчжуриягә кадәр, Себерне дә кертеп, 4473 чакрым юл үттек. Һаман да дус-иш арасында идем. Бер генә чит-ят кеше дә юк. Тел мәсьәләсендә дә бер кыенлык та күрмәдем. Һаман да Себер дөньясына сибелгән төрки кавемнәр арасында, тагын да төгәлрәк итеп әйтсәм, үз йортыбызда идек. Маньчжуриягә килеп җиткәч, вагоннан төшүгә, яныма бер егет йөгереп килде, кулымны үпте, сумкаларымны күтәреп алды да: «Рәхим итегез!» – дип алдыма чыкты, көтеп торган фаэтонга утырдык. Абулла әфәнденең Акчура углы өенә килдек. Кытай илендә булсак та, барыбер үз йортыбызда идек.

Маньчжуриядә тимер юл хезмәткәрләре нигездә руслар, кытайлар да бар, ләкин бик аз. Бирегә килеп җиткәнче, юлларда, шәһәрләрдә кытай кешесе бик сирәк очрый иде. Тик монда, әле тимер юл станциясендә үк, беренче булып күзгә чалынучылар озын чәчле кытайлар иде.

Монда чик үтү эшләрен оештыручы ике төрле идарә бар икән. Русиядән килә торган тауар һәм әйберләргә бары тик Кытай чик идарәсе карый, алдан салым билгеләнгән тауар төрләреннән чик үтү түләве алына һәм дә Кытай хөкүмәте ала. Икесе дә Маньчжуриядә. Кытай чик эшләре идарәсендә хезмәткәрләрнең күбесе кытай кешеләре булса да, башлыклары – инглизләр. Инглизләр, гомумән бөтен Кытай илендә диярлек, үзләрен бер васый[1] кебек тоталар икән. Берәр җирдә нинди дә булса бер табыш килә торган эш булса, ул эшнең башында, һичшиксез, бер инглиз кешесе тора. Маньчжурия дә Русия чигендә урнашкан, үзенә күрә бер табыш капкасы кебек. Биредә, әлбәттә, бер генә түгел, берничә инглиз кешесенең булуы шарт, чөнки бу – Русия чиге.

Маньчжурия үзе – Русия чиге итеп тимер юл салынган вакытта руслар төзегән кечкенә генә шәһәрчек. Рус-япон сугышына кадәр бу җирләр Русия дәүләте идарәсендә булган. Ул вакытларда чик үтү рәсмияте юк, тулысынча Русия илендәгечә мөгамәлә күрсәтелгән. Япон сугышыннан соң, бөтен илләрнең чик сызыклары билгеләнгән вакытта, русларның карталары һәм чикләре бу җирләрдән чигендерелгән.

Маньчжуриядә чик билгеләнгәннән соң, инде рус түрәләре дә биредән күчеп китәргә мәҗбүр булган, сәүдәгәрләренә

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Васый – кешенең үләр алдыннан әйтеп (язып) калдырган васыятен тормышка ашыруны оештыру, күзәтү эше йөкләнгән кеше, хезмәткәр (*тәрҗ. иск.*).

дә чик үтү рәсмияте һәм түләве каралган. Маньчжурия базары тора-бара торгынлык чорына кергән һәм бу хәл рус сәүдәгәрләренең эшен нык какшаткан. Сәгате-минуты белән әлеге җирләргә япон маллары китерелә башлап, рус сәүдәгәрләренә, малларын төяп, Русиягә кайтып китүдән башка чара калмаган.

Маньчжурия, гомумән, руслар тарафыннан төзелгән. Биредә руслар белән бергә алты йорт булып, безнекеләр – Русиянең эчке төбәкләреннән күчеп килгән мөселманнар да яши. Маньчжуриядәге Русия сәүдәгәрләренең иң байлары да нәкъ менә шулар – мөселманнар.

Маньчжурия шәһәрчегендә төпләнеп яшәүче шул алты йорт мөселман кешесенең үз мәктәбе, мәчете бар. Мин, гомумән, башка берни белән дә кызыксынмыйм, бөтен игътибарым мөселманнарның дин һәм мәгариф эшләренә юнәлгән, ул эшләр тагын да алга китсен, дигән теләк белән, кайда мәктәп күрсәм – шунда укучыларны сынаудан, укытучыларны имтиханнан үткәрәм, карыйм, тикшерәм. Ерак Көнчыгышта да вазыйфам шул иде, Маньчжуриядә дә вазыйфам шул булды.

Рус-япон сугышыннан соң чикләр сызылып, Маньчжурия кытайларның малы һәм мәмләкәте булып калуга, руслар шәһәрчекне калдырып китә башлаганнар. Ун мең, егерме мең, утыз мең сумлык йортларын 300 сумга сатарга карар кылган булсалар да, алучы таба алмыйлар. Руслар, *каддимул-хуруҗ каблел-вулуҗ* [кергәнче, чыгарыңны уйла], дигән кагыйдәгә буйсынмаганнар, сугыш вакытында һавадан килгән, ягъни тир түкмичә табылган акчаларына сарайлар салганнар. Бүгенге көндә исә, бер тиенсез ташлап китәчәкләре ап-ачык билгеле. Мин Маньчжуриядә бары тик бер генә көн кундым, икенче көнне үк юлга чыктым һәм Цицикарга[2] килдем.

ЦИЦИКАР

Маньчжуриядән Харбинга кадәрге тимер юл руслар тарафыннан төзелгән булса да, рус-япон сугышыннан соң Кытайга калдырылган. Шул сәбәпле «Кытай көнчыгыш поезд юлы» дип аталып йөртелә, озынлыгы Харбинга кадәр 876 чакрым тәшкил итә. Биредәге тимер юл хезмәткәрләренең барысы да руслар, ләкин алар әлегә китмиләр, тимер юлны тапшыру эшләре тәмамланганчы биредә калачаклар. Күп җирдә инде тапшыру эше тәмамланган да, станцияләр бөтенләе белән кытайлар кулына күчкән. Бөтен юлның хәрәкәт җәдвәле (расписаниесе) кытайларныкы, русларныкы түгел.

Цицикар Маньчжуриягә 623 чакрым ераклыкта урнашкан, Кытай хөкүмәтенең зур гына хәрби үзәге булып тора. Кытай иленең бер өлешен беренче тапкыр монда күрәм. Бу җирләр Русия чигендә урнашканга, әһәмиятле хәрби зоналарның берсе булып санала. Цицикарга килеп җитәрәк, юлда бер татар кешесе, яныма килеп, сәлам бирде. «Вәгаләйкемәссәлам», – дидем һәм кул биреп күрештек. Шуннан соң безнең арада минем соравым белән башланып киткән шундый сөйләшү булды:

– Сез кем, кая барасыз?

– Мин – сәүдәгәр, бәйрәм намазы укырга дип Цицикарга барышым.

– Бик яхшы, мин дә шунда барасы идем, очрашуыбыз яхшы булды. Инша Аллаһ, бергә барырбыз. Станциягә барыр өчен ат ялларга кирәк, шулай түгелме?

– Әйе, атта барырбыз. Станциядә минем сәүдәханәм бар, бу кич Сезне шунда кунак итәрбез. Бәйрәмнең кайсы көн икәнен белмим, чөнки бу кытай мөселманнары, айны үз күзләре белән күрмичә, кабул итмиләр. Ай башында исә берничә көн күк йөзе бик болытлы

---

[2] Цицикар – бүгенге көндә Кытайның төньяк-көнчыгышында урнашкан, алты миллион кеше яши торган шәһәр. Шәһәрнең атамасы монгол теленнән «шәһәр-бакча» дип тәрҗемә ителә. (*тәрҗ. иск.)*

иде. Карарбыз, безнең кибеттә эшләүче егетләрнең бәлки хәбәрләре бардыр.

– Минем исәбем буенча зөлхиҗҗәнең 8е булырга тиеш.

– Белмим, Кытайдагы голәмә (рамазан аен һәм бәйрәмнең көнен билгеләүдә) башка хисапны һич кабул итми. Алар фикеренчә, айны үз күзең белән күрү шарт.

Юлдашым булачак сәүдәгәр Абдулла әфәнде мине электән танып белә икән. Рәхәтләнеп сөйләшә-сөйләшә, Цицикар станциясенә кадәр килдек. Абдулла әфәнденең хезмәтчеләре безне каршы алды. Әле станциядә үк бәйрәмнең кайсы көнне булачагын сорадым: «Әле биш көн бар икән», – диде.

Бик аптырадым, ышанасым килмәде. Шулай итеп, Абдулла әфәнденең өенә килеп җиттек, бүген биредә куначакбыз. Бу станциядә тимер юл хезмәткәрләре, берничә кибет хуҗасы гына яши икән, башка йортлар, авыл-фәлән юк.

Икенче көнне иртүк фаэтон яллап, Цицикар шәһәренә киттек. Станция белән Цицикар арасы 25 чакрым икән, нәкъ ике сәгать дигәндә килеп җиттек.

Әле шәһәргә кергәнче үк, зур-зур казармалар, атлы, барчасы да озын чәчле, җәяүле гаскәриләр очрап торды. Юлның һәр ике ягында да гаскәриләрне өйрәтү белән мәшгуль инглиз офицерлары да күзгә чалынып-чалынып калды.

Иң әүвәл, Цицикар шәһәр капкасы – алда рәсемен куячакмын – игътибарымны җәлеп итте. Бу капка – рәсемдә күрерсез – зур урам уртасында тора. Кереп чыгар өчен түгел, матурлык өчен ясалган. Мондый капка ясап кую Кытайда борынгы заманнардан бирле килә; бик зур капкалар ясыйлар һәм бу бөтен шәһәрләрдә дә бар икән. Кайбер урамнарда икешәр-өчәр капка да торырга мөмкин. Урам башларына куелган капкалар аеруча күркәм, бизәкле, матур була икән.

Без монда Абдулла әфәнденең дусты Ку-Эн исемле бер сәүдәгәрнең өенә кунак булып төштек. Ку-Эн – Цицикар мөселманнары арасында могтәбәр сәүдәгәрләрнең иң дәрәҗәлеләреннән берсе икән.

Кытай мөселманы өенә минем беренче керүем. Ку-Эн җанапларының өе гаять гади, урамга чыга торган ишеге өстендә *Йа мүфәттихәл-әбваб* [Әй, ишекләрне



Цицикар шәһәр капкасы

ачучы!] гыйбарәсе гарәп хәрефләре белән язылган иде. Соңыннан белдем: мөселман өйләренең һәммәсендә дә ишек өстендә йә «кәлимә-и тәүхид» [Лә иләһе илләАллаһ], йә «бисмилла-и шәрифә» [бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим] яисә *Йа муфәттихәл-әбваб* кебек бер гыйбарә мотлак гарәп хәрефләре белән язылган була. Бу исә, мәҗүси өйләре белән чагыштырганда, алардан аерылып тору билгесе вазыйфасын үти. Кибетләр арасында исә, мөселманнарның кибетләре, мәҗүсиләрнең кибетләреннән бер «комган» рәсеме белән аерылып тора, бигрәк тә аш-су, ризык сатыла торган кибетләр мотлак аерып билгеләнә.

Ку-Эн – бик тә мөлаем мөселман кешесе, гарәпчә исеме Йосыф икән. Кытай мөселманнары, гомумән, ике исем йөртәләр, берсе – Исламга бәйле, икенчесе – гомуми исем, кытай телендә һәм кытай гореф-гадәтләре буенча бирелә. Тик болар, күбесенчә, Ислам белән бәйле исемнәрен кулланмыйлар, хәтта шул дәрәҗәдә ки, ике бертуган, мәсәлән, бер-берсенең мөселман исемен белмиләр. Барысы да кытайча исемнәре буенча гына беленә.

Ку-Эн әфәнде безне зур ихтирам белән кабул итте, атасының өендә бүлмә хәзерләтте. Атасы да бик мөлаем карт, йөзендә һәрвакыт ниндидер бер сөенеч галәмәте сизелә, нур сирпелә иде. Кызганыч ки, бу карт белән самими карашуларыбыздан башка төрле аралаша алмыйбыз, чөнки үз теленнән башка тел белми. Ку-Эн исә русча бик яхшы сөйләшә. Ку-Эн әфәнденең өендә бераз аралашып танышканнан соң, безне голамә белән күрештерүен үтендем. Мәчеткә барырга киңәш итте һәм мин мәчеткә киттем.

Монда гомеремдә беренче тапкыр Кытай мәчетен күрдем. Мәчетнең капкасы төбенә килеп җиткәнче, ерактан: «Менә шул мәчет инде», – дисәләр, мәчет өстендәге сурәтләрне күреп: «Бу әллә бер потханәме?» – дигән сорау туар, яисә баштан: «Нинди төзек потханә!» – дигән уй йөгереп узар иде. Ләкин капка янына килеп җитүгә, биредә *Лә иләһе илләАллаһ мөхәммәдән рәсүлуллаһ* җөмләсе язылган булуын күрдек. Мәчет капкасыннан керүгә, таш түшәлгән матур ишегалды, гаҗәеп чисталык – болар, һичшиксез, Ислам гыйбадәтханәсе икәнен күрсәтеп тора иде. Мәчет ишеге дә әлеге ишек алды мәйданына карый. Бу мәйданда мәчеттән башка әле тагын шактый санда төрле оештыру-идарә йортлары бар. Башта шуларның берсенә кердем. «*Сәламун аләйкум*», – дидем – *Хәл фикум мән йа'рифу лисанел-'араб*? [Арагызда гарәпчә белүче бармы?]», – дип сорадым. Араларыннан берсе: «*Әнә, йа'ләму кәләмун 'араби* [Гарәби гыйбарә белер мин]», – дип җавап бирде. Шул дүрт сүздән гарәп телен ничек белгәне аңлашылды, аның белән сөйләшә алган кадәр сөйләшергә тырыштым. Бу йортның – мәдрәсә, әфәнделәрнең исә шәкертләр икәнлеген аңладым. Миңа бик гаҗәп тоелды: мәдрәсәдә унбишләп шәкерт бар, араларында әйтәсе фикерен әйтеп бирә алырлык тел белүчесе юк. Ихтыярсыздан, остазлары турында сорадым: «*Ахун 'араби йа'ләму кәсиран* [Ахун гарәпчә бик яхшы белә]», – диделәр.

Чынлап та яхшы белсә, сөйләшеп, бик күп мәгълүмат алырмын, дип уйладым. Ахун янына киттек. Ул да шунда ук, үзе өчен билгеләнгән бүлмәдә икән. Сәламләшкәннән соң, кул биреп күрештек. Ахун миңа: «*Әнтә рәҗүлүн алим?* [Сез галим кеше, әйеме?]», – диде. Мин исә: «*Әнә хадимул-улема* [Мин галимнәрнең хезмәтчесемен]», – дип җавап бирдем.

Ахунның да шәкертләреннән әллә ни аерылып тормаганлыгы аңлашылды. Бераздан аның китапларын карап чыктым: «Кудури», «Хидайә» һәм кулдан язылган мусхаф-ы шәрифләр бар, «Мухтасарүл – Мә'ани»-фәлән, барысы

да – гарәпчә китаплар, барысы да – кулъязма нөсхәләр. Бу китапларга караганда, әйтәсе килгәнен әйтә алучы табылырга тиеш иде югыйсә, тик шәкертләр турында әйтеп торасы да юк, ахуннары да хәтта ике сүз кушып гарәпчә сөйләшә алмый. Биредә мин шулкадәр өметсезлеккә бирелдем ки, эчемнән генә: «Әй, бичара Исламият! Ни хәлләргә төшкәнсең?! Шаккатмыйча мөмкинме?!» – дидем.

Ул көнемне кичкә кадәр мәдрәсәдә үткәрдем. Корбан бәйрәме булганга, шәкертләр дә укымый, ял итәләр иде. Ләкин шәкертләрнең икесе-өчесе китә, икесе-өчесе килә, килгән саен бу әфәнделәр күпләп, кызыл кәгазьгә төрелгән нәрсәләрдер китерәләр дә үзара бүлешәләр иде. Нәрсә икәнен сорагач: «Сәдака», – диделәр. Игътибар белән күзәттем, бөтенләй аңлашылмый торган нәрсәләр күп иде. Ул кәгазьгә төрелгән нәрсәләрнең вак акча икәне аңлашылды. Шәкертләрнең хәл-торышларына игътибар белән караган саен, җаһиллекләре тагын да ачыграк аңлашыла иде. Кичке намаздан соң, Ку-Эн әфәнденең өенә кайттым. Кичке ашны ашагач, бик нык арыганымны аңладым, йокларга яттым. Һава суык иде. Кытайларда кирпеч мич тә юк, тимер мич-мангал да юк, өйләр төтен белән җылытыла – моны да дөньяда һич күргәнем юк – һәм дә гап-гади агач төтене белән. Торбасыз мичкә ут кабызып җибәрүгә, бөтен өйне төтен баса. Аякка торып басып булмый, төтеннән баш әйләнә. Шулкадәр начар нәрсә ки, безнең мәмләкәттә кара мунча дигән мунча бар, биредә өйләр менә шул кара мунча кебек. Мин бу ис-корым эчендә, урын-җиремдә боргаланып ята-ята таң аттырдым.

Икенче көнне иртән шәһәр карарга чыктым. Бераз йөргәннән соң, тагын мәдрәсәгә килдем. Гарәпчәне ватаҗимерә сөйләшүче шул кичәге шәкерт белән аралашырга маташа идем, рус телен белүче бер кеше табып китерделәр. Безнең бу тәрҗемәченең русчасы бик үк яхшы булмаса да, бераз сөйләшә алу мөмкинлеге туды. Аллаһ бәрәкәт бирсен, бу кеше эшебезне аз булса да җиңеләйтте. Ләкин бу да бик мәшгуль кеше булып чыкты, яныбызда бары тик ике сәгать кенә кала алды. Цицикар никадәр генә зур шәһәр булса да, биредә мөселманнар бик аз икән. Бары тик ике мәчет кенә эшли, мең ярымга якын мөселман гаиләсе бар. Мөселманнарның күбесе җир эшкәртү белән шөгыльләнә, сәүдәгәрләре берничә генә, вак-төяк һөнәрчеләре исә байтак икән.

Мәдрәсәләре шул без барып күргән бер мәдрәсә икән, анысының да унбиш шәкерте бар. Икенче мәчетнең имамы – бозык мәзһәпле, җаһил, диделәр дә, миндә, никтер, кызыксыну уянды. Тәрҗемәчегә: «Шул бозык мәзһәпле имамны бергә барып күрик, үтенәм Сездән», – дидем. Башта: «Мин анда бара алмыйм», – дигән иде, аннары ничектер ризалашты. «Ярый, бары тик Сезнең хакка гына барам», – диде. Икенче мәхәллә мәчете дә якында гына икән. Бардык, урам капкасыннан кердек. Ишек алды балалар тавышыннан чыңлап тора иде. Мәдрәсә ишегеннән керүгә, биредә 20-30 баланың белем алганлыгы аңлашылды. Кулына озын таяк тоткан бер кеше балаларга кычкыруга, тегеләр барысы бергә: «Әссәламү галәйкүм», – дип кычкырып сәлам бирделәр. Минем күзләремә яшь тулды. «*Хәл әнтүм та'ләмүнә лисанел-'араб* [Сез гарәпчә беләсезме?]» – дип сорадым. «*А'ләму калилән* [Бераз беләм]», – дип җавап бирде. Ишеткәннәрем шунда ук исемә төште дә, эчемнән генә: «Бу кешедә бер хикмәт бар», – дип уйлап куйдым.

Дәвамы бар

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Алишны халык онытмый

Быел 15 сентябрьдә каһарман язучы, атаклы әкиятче Абдулла Алишның тууына 110 ел тулды. Шушы уңайдан әдипнең туган ягында – Спас районының Көек авылында А.Алишның бюсты яңартып куелды. Шәһри Болгарда исә мәшһүребезгә музей ачылды.

22 октябрьдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов җитәкчелегендәге бертөркем язучылар Спас районына барды һәм әлеге истәлекле урыннарда булды. Спас районы мәдәният йортында исә А.Алиш юбилеена нисбәтле әдәби-музыкаль кичә узды. Әлеге зур чарада танылган шагыйрь һәм прозаик Факил Сафинга Абдулла Алиш исемендәге премия тапшырылды. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

ЙОРТ ИЯСЕ – ЙОРТ ТОТКАСЫ!

Татар халкының җирле сөйләшләрендә борынгы катламны тәшкил иткән мифологик лексика үзәк урынны били. Безне уратып алган һәрнәрсәнең, табигать күренешләренең, йорт һәм каралты-кураның, елга-күлләрнең үз иясе бар. Әлеге мифик иянәр, ышану-йолаларга, фантастик күзаллауларга нигезләнеп, төрле авыл һәм калаларда үзенчәлекле чагылыш таба һәм хәзерге көнгәчә сакланып килә. Халык

традицияләрендә «түбән катлам» мифологиясенә караган, кешенең көндәлек тормышы, йорт-җире, каралты-курасы белән бәйләнешле йорт ияләрен фәнни яссылыкта тикшерү аерым бер мифик персонажны халык күзаллавында, хәтерендә, фантазиясендә торгызырга мөмкинлек бирә. ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан үткәрелгән күп санлы экспедицияләр төрле төбәкләргә сибелеп яшәгән, шул исәптән Татарстан татарларының мифологик лексикасын барларга, теркәргә, эзлекле фәнни яссылыкта тикшерергә, шулай ук үткән һәм бүгенге көн ноктасыннан якын килеп өйрәнергә мөмкинлек тудыра. Төрле төбәкләргә сибелеп яшәүче татар халкында киң таралган һәм хәзер дә кулланылышта йөргән, фольклор-диалектологик жанрларда гына сакланып калган, гаять дәрәҗәдә кызыклы архаик лексик катламны тәшкил иткән бай мирасыбызны – мифологик лексиканы җыеп, фәнни әйләнешкә кертеп, киләчәк буынга тапшыру әйтеп бетергесез әһәмияткә ия!

Йорт төшенчәсе, гаилә мөнәсәбәтләрен, гаилә иминлеген, бәрәкәтен, бөтенлеген һәм муллыгын гына чагылдырып калмыйча, аерым бер халыкның, милләтнең сыйфатларын ачып бирә торган, киң мәгънәне үз эченә сыйдырган символ ролен дә үти. Халык ышануларында, йолагадәтләрендә өйнең бәхете, иминлеге һәм бәрәкәте йорт ияләренә бәйләп аңлатыла. Төрки халыкларда һәм татар теленең диалектларында «*ия*» компонентын үз эченә алган персонажлар җирле мәдәниятләрдә төрле вариантларда чагылыш табалар: *ия* себ. «ия, хуҗа»; *ыйа, ыйа иййе*, чув., нуг., каз., к. калп.; кырг. *ие*. Мари һәм удмурт телләрендә *ия* «җен, явыз көч» дигән мәгънәне белдерә. Билгеле булганча, халык телендә тирә-юньне уратып алган һәрнәрсәнең үз иясе бар: *абзар ийәсе, җорт-җир ийәсе, ихата ийәсе, койо ийәсе, лапас ийәсе, мал ийәсе, урман ийәсе* һ.б. *Йорт ийәсе, җорт ийәсе, ихата ийәсе* өй һәм хайваннар хуҗасы буларак билгеләнә. Халык телендә йорт иясе йонлы битле, зооморф кыяфәтле итеп сурәтләнә: бәр. «*Җорт иясе элек күзгә күренгән ич, җонлы битле, куркыта торган булган*». Шулай ук халык текстларында антроморф үзенчәлекләре дә күзәтелә: «*Җорт ийәсе бала түри, ди (балалый)*». Халык телендә йорт иясенең бары тик хайваннар, мал-туар яшәгән йортта гына тереклек итүе әйтелә. Тормыш-көнкүрештә йорт иясенең кешегә уңай һәм тискәре мөнәсәбәтен дә күрергә мөмкин. Шуңа күрә халыкта «җорт иясен ризалату», аңа багышлап корбан чалу йоласы да яшәп килә. Йорт иясенә багышлап дога укыла, аңа багышлап хәер бирелә: бәр. «*Җорт иясенә дога кылмасаң, ул тыныч нигез булмый, диб әйтәләр*». Йорт иясен ризалату максатында, хуҗалар берәр җиргә киткән очракта, өйгә тастымал элеп, он калдыралар. Темн. «*Анда-монда киткәндә ызбаңда өстәлеңә он куй, әләгә тастымалыңны элеп куй, изба ийәсе ашый да кулын сөртә икән*». Йорт иясе хуҗасын ератса, сыерның бозаулавы яки көтүдән

«Моң иясе»

кайтуы турында хәбәр бирә. Яратмаса, берни эндәшми. Касыйм сөйләшендә, йорт иясе яхшы мөнәсәбәттә булсын өчен, тозсыз коймак пешерәләр. Тозсыз-төче коймак белән сыйланган йорт иясе малларга тими.

Думавай – йорт иясе, мифологик хуҗа һәм шул ук вакытта өйне саклап торучы, хуҗалыкны карап торучы ия, гаилә башлыгы, татар теленең мишәр диалектында еш кулланыла. Өй тирәлегендә гомер итү – думавайның төп сыйфаты. Халык традицияләрен чагылдырган фольклор-диалекталь язмаларда думавай мифик персонажына бертөрлелек хас. Ул хатын-кыз кыяфәтендә сурәтләнә. Думавай, нигездә, мич аралыгында, өй почмагында, түбәдә, баз астында, сарайда тереклек итә. Керәшен татарлары думавайны *кырсут* дип атап йөртәләр. Кырсутның да яшәү тирәлеге мич аралыгына, хайван лапасына бәйле. Кырсут йорт хуҗасына охшаган була: *«И, кырсут, синең җаныңа җатыйм әле, айакларым туңды, җөткергәлим дә»,* – *димен. Әллә күзгә күренде, үзем төслук»*. Шулай ук кырсут халыкта хатын-кыз белән дә тиңләштерелә: *«Кырсут ул – җырт хуҗасы, кыз-катын җанында, ди. Кырсутсыз җырт салкын, диләр»*. Керәшен татарлары кырсут өчен аерым ботка да әзерли, кайбер урыннарда аны икенче төрле *«кырсут боткасы»* дип атап йөртәләр: *«Кырсут боткасы ашарга утырыгыз. Каралтыларга, абзарларга, лапасларга да куйам кырсут боткасын»*. Кырсут булган йортта тату торалар, өй эчендә җылылык була. Шуңа күрә, халык арасында *«кырсут – җорт тоткасы»* дигән әйтем йөри: *«Кырсут – җорт тоткасы, диләр,*

«Ташлар иясе»

«Юл иясе»

Әхсән Фәтхетдин рәсемнәре һәм сыны

кырсут булмаган җорт бетә». Хәзерге чуаш мәдәниятендә кырсут образына *хертсурт* мифологик образы тәңгәл килә. Чуашларда әлеге мифологик образ хуҗалыкны карап торучы, гаилә һәм йортны саклаучы булып тора. Чуаш ышануларында, әгәр дә әлеге ия өйне ташлап китсә, өйдә талаш башлана, өйнең бәрәкәте бетә, гаилә таркала, хуҗалык бөлгенлеккә төшә. *Хертсурт* йорт эшләрендә ярдәм итә һәм кичләрен йон эрләргә ярата.

Татар традицион мәдәниятендә думавай образы *әби, әбей* мифологик персонажында да чагылыш таба. Әби, әбей образы берничә вариантта яшәп килә: *абзар әбие* нокр.т., *өй әбие* нокр., *гулмич әби*, *ашыру әбиләре*, *мича әби*, *су әбийе*, *кор әбийе* һ.б. «ия, багучы, үләнче әби». Әби мифик образы кулында тастымалы булган, мич пумаласын тоткан алъяпкычлы хатын-кыз образы буларак күзаллана. Шулай ук Глазов локаль вариантында йорт әбисенең хуҗасына охшап килүе дә ассызыклана. Антроморф сыйфатларга хас *әби, әбей* образның уңай һәм тискәре сыйфатларга да ия булуы билгеләнә: «*Хайваннарга бәйләнә абзар әбей, аптырата, мучит итә, арыкыйлар хайваннар*». Шуңа күрә әби кешеләргә яхшы мөнәсәбәттә булсын, хайваннарга тимәсен өчен, иянең күңелен күрергә кирәк. Әбине тынычландыру ритуалын халык арасында *абзар әбиен йушату* дип атыйлар: срг. «*Әпәй-тоз куйалар йорт анасына: Син хайванга тимә инде. Мин сиңа аш-су китердем.*

Хайваннарымны рәнҗетмә»; влгг. «*Йорт анасы, йорт анасы. Мә сиңа калач белән тоз. Безгә тынычлык бир. Риза бул йорт анасы»*. Кайбер җирле традицияләрдә думавайга коймак пешереп китерәләр: *«Әбекәем белен пешерде, бер чеперәккә чырнады да сарай башына чыгарып куйды»*.

Глазов татарларында өй иясен *Гулмич әби, Гулбич, Гөлбәч* дип атыйлар. *Гулмич* сүзе рус телендәге «голбец» сүзенә бәйләнешле. Фольклор-диалекталь текстларда Гүлмич әбинең яшәү урыны баз асты булуы аңлашыла: «*Өй әби гулмичиә тора, имеш»*. Гүлмич әбинең уңай һәм тискәре вазыйфалары билгеләнә. Уңай вазыйфалары яңа йортка күчкәндә башкарыла торган йолага бәйле. Традицион җирле мәдәнияттә яңа йортка күчкәндә Гүлмич әбине чакыралар, аның белән бәйләнешле йола үткәрәләр: «*Әйдә, йаңа өйгә чыгабыз», – дип алып чыкканнар»*; «*Өй сатабыз. Безгә әйтә: «Өй әбиегезне калдырып китегез. Йә безнең белән барма, менә хузәйкәгез. Гулбичне калдырып китегез»*; *«Пич йагарбыз, пич тартырбыз, өйне җылытырбыз, син бездән калма», – дип»*. Шулай ук Гүлмич әбинең гадәттән тыш көчкә ия булуы да билгеләнә: «*Йаман йангыр йауса, ишегалга пумулуны чыгарып бәргәләделәр. Имеш, Гулмич әби туктата яңгырны»*.

Гүлмич әбинең яңа туган баланы алыштыра алуы билгеләнә: «*Гулмич өстенә пычак салып калдыралар. Йәнә гулмәчтән Гулмич әби чыга да бәбәйне алыштыра. Йаңга туган баланы йаңгыз калдырма, йарамый, диделәр»*. Халыкта алыштырылган баланы «*Гулбич әби алыштырган»*, дип атыйлар. Гүлмич әби алыштырган баланың исемен дә алыштыралар: *«Балага Гөлбәч әбисе тигән, диләр. Кулмәген төшереп җәяләр гөлбәчкә. Исем алыштырганнар: «Гөлбәч әби йаратмый», – дип»*.

Татар мифологиясендә Бичура образы – думавай, явыз, «түбән көчләргә» карый. Бичура – өй каралты-курасында, сараенда, шулай ук урманда яши торган катлаулы образларның берсе. Бу демонимның халык арасында төрле атамалары йөри: *Бисура*, *Писура, Писюра* һ.б. Халык текстларында Бичура бик куркыныч кыяфәттә сурәтләнә һәм кешеләрне куркытуы билгеләнә: нгб. крәш.«*Бичура ул шоннок йәмсез, килбәтсез була»*. Шулай ук Бичураның теше булмый. Традицион татар мәдәниятендә Бичураның тышкы кыяфәтендә зооморф билгеләр чагылыш таба. Кайбер текстларда аның койрыгы булуы да ачыклана: бараб. «*Бичура ул кеше куркытып та җөргән. Үзе койрыклы да булган»*. Кайбер җирле вариантларда исә Бичура йә тәкә кыяфәтендә, йә булмаса эт кыяфәтендә сурәтләнә. Фольклор-диалекталь текстларда Бичураның мич арасында яшәве дә билгеләнә: нгб. крәш. «*Бичура ул пич аралыгында йәши, ди, аралыкта. Шунда җылы була аңа»*. Татар табышмакларында да Бичураның яшәү урыны мич арты булуы тәгаенләнә: «*Мич артында мичура билен буып утыра (себерке)»*. Фольклор-диалекталь текстларда Бичураның уңай һәм тискәре вазыйфалары да күрсәтелә: «*Аңга – Бичурага ботка пешереп ашатсалар, ул сингa әллә ниләр ташып тора, дигәлләр. Бүрәнә кирәкме сингa, утын кирәкме, капчыклы ризык кирәкме»* каз. арты с. *«Бичура гына байытты инде боларны, – диделәр. – Бичура ташыды», – диделәр»*. Бичураның тискәре сыйфатлары да билгеләнә: минз. с. «*Бичура җен була ул, иблис. Курыксаң, чирлисең, курыкмаска кирәк»*. Йорт иясе, думавай йорттагы хайван, кош-кортны карый, хуҗалыкта ярдәм итә. Йорт хуҗалары Бичураны үпкәләтсә, баланы алыштырырга да мөмкин, хайваннарны котырта ала, йортка зыян сала башлый.

Минзәлә ягы керәшен татарларына караган фольклор-диалекталь материалларда *Абзар ийәсе* абзарда яшәүче мифологик персонаж, мал иясе буларак тасвирлана: «*Абзар ийәбезнең исеме Зәнки баба, аңына әйәт укырга кирәк, шулай тиешле. Йортларыбызны, хайваннарыбызны саклар өчен»*. Халык материалларында абзар

иясенең яшәү урыны абзар тирәсе, каралты-кура дип билгеләнә. Әлеге мифик образның уңай һәм тискәре вазыйфалары да күрсәтелә. Халык абзар иясе малны яки хуҗа кешене яратмаган очракта, *төс булмады, төс бирми, төсе килешми, кулга килми* дигән гыйбарәләрне куллана. Әгәр абзар иясе хуҗасын яратса, хуҗалыкта да ярдәм итә, дигән фикер яши: «*Абзар ийә, абзар хуҗа йаратса, мал симез була, тей, абзар ийә үзе карый, ти ул. Әти әйтә, куркытмаң азбар ийәне, азбар хуҗаны, туйдырсын, дийә ийе*». Малларны яратса, абзар иясе атларның ялларын үрә. Ләкин шунысы да бар – кайвакыт үргән ялларны сүтәрлек булмый: «*Ул үргән йалларны бер кеше сүтешле булмый*». Абзар иясе кеше кыяфәтендә дә, хайван кыяфәтендә дә тасвирлана: «*Абзар ийәләре булды. Кеше булып йөреде. Менә ап-ак бозаукай булып сыйырым янында тора*». Абзар иясе ап-ак сакаллы бабай буларак та сурәтләнә: перм., нокр., глз. т.я- крш. чст. «*Азбар ийәсе бар. Безнеке абый, олосы абый тышка чыгам, тей, башка каплады тунны, тей. Ап-ак сакаллы бабай, тей, өстендә ап-ак, тей*».

Даими авторыбыз Гүзәлия Сәйфулла кызы Хаҗиева докторлык диссертациясе яклады. Аны ихластан котлыйбыз һәм хезмәтендә яңадан-яңа уңышларга ирешүен телибез!

Каралты-курада абзар иясенең зыяны тигән очракта, халык аның белән аралашырга мәҗбүр була. Мәсәлән, төньяк керәшен татарларында, абзар, каралты-курага кергәндә, абзар иясенә эндәшеп керү, аны сәламләү киң таралган. Абзар иясе мал-туарны яратмаса, аңа зыян сала башлый, мал тиз арада ябыга, чирләп китәргә дә мөмкин. Шуңа күрә, абзар иясен куркыту өчен, дегет, күмер куялар яки тәрәзә рамнарын дегет белән буйыйлар. Казан артында исә, абзар иясе малларга тимәсен, дип, куркыту максатында, мондый йоланы башкаралар: «*Маллар мантымый башласа, менә болай итәләр ийе. Бер бәләкәй бидерәдә арба майлый торган дегет булды. Аның пумаласы булды тәкәрмәчләр майлый торган. Шул дегетле савытны абдарга элделәр*». Алдарак билгеләп үткәнчә, абзар иясе хайваннарны яратсын, каралты-курага зыян китермәсен өчен, Зәнки бабай рухына аять укыла: «*Абзар иясе, яратмаса, Зәнки бабай рухына дип аять укырга кирәк*»; «*Мал орамый (үрчеми), абзар ийәсе бардыр, дип әйтә торганнар ыйы элек. Хәер биргән булалар, абзар ийәсенә бирәбез, дийеп*». Шулай ук халыкта, абзар иясенә, дип, абзарга ботка кую йоласы да яшәп килә: «*Бер белдекле карчыкны алып кайтып, бутка пешереп, дүрт почмакка кашык белән бутка салып чыкканнар*». Абзар иясе малларга тынычлык бирсен өчен, абзарның дүрт почмагына «Аятел-Көрси» догасын укып, тимер акча салу йоласын да үтәү халык арасында киң таралган була.

Шулай итеп, йорт ияләрен өйрәнү, бер яктан, адәм баласының яралтылуына баглы мифларны барларга, икенче яктан, «теге дөнья» хакындагы күзаллауларны анык бер шәкелдә тасвирларга, өченчедән, әлеге мифик персонажларда йортны саклау, яклау вазыйфасын тәгаенләргә мөмкинлек бирә.

Гүзәлия Хаҗиева,
Флера Баязитова,
филология фәннәре докторлары ■

РОМАН УЙЛАНДЫРА*

Аяз Гыйләҗев

Ниһаять, ун елдан артык гомер багышланган хезмәт тәмам. Соңгы нокта куелган – Мәхмүт Хәсәнов үз исемен әдәбиятыбыз тарихында теркәп калдырырлык әсәр иҗат иткән. Темасы, чорларның кискенлеге, кырыслыгы, образлар сайлаган язмышның гаять чуарлыгы автор алдында авыр, олы юл булып торган. Минемчә, М.Хәсәнов үз өстенә алган чамасыз авыр йөкне теләгән ноктасына кадәр илтеп җиткергән. Хәзер бер-ике талпынасы да, җиң сызганып, бер-ике мәртәбә алга ыргыласы да... тәмам!

Аяз Гыйләҗев

Һәр әдәби әсәрнең автор күңелендә билгеләнгән, әсәрне иҗат итү дәвамында ирешкән югарылыгы була. Стиль дип шуны атыйлармы әллә? Юк, бу стиль генә түгел, бу әсәрнең сулышы, адымы, югарылыгы. М.Хәсәнов үтә кызыклы язмыш-

*Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романына (күләме – 43 табак) рецензия.

лар табып, романын билгеле бер югарылыкка күтәргән, бик күп урыннарда ул шул «югарылыгын» саклый, сулышы киң, тавышы көр булып кала аның. Шушы югарылык романның тонын, сүз җебен, ныклы логикасын билгели. Әсәрне бербөтен итеп беркетеп торткан шушы югарылык ноктасыннан чыгып караганда, әсәрнең кайбер сәхифәләренә безнең тарафтан кайбер эшлекле тәкъдимнәр дә булыр. Автор сюжетны оста корган. Иргали, Гази, Гөлүсә, Рәхимҗаннарның язмышы – укучының игътибарын һәрчак сак тотарлык дәрәҗәдә оста язылган. Иргалинең бер гаепсезгә ерак, күңелсез сәфәргә хөкем ителүе, анда да югары кешелек сыйфатларын саклап кала алуы, Себер юлында аларга Шаһи белән Шахбәзнең ияреп китүләре, себер татарлары белән мөнәсәбәтләр, Газинең әсирлектә кичергәннәре, ниһаять, Мәскәү комиссиясе составында килеп чыккан Анатолий Степановичның Газине партизан отрядында күргән булуы, аның әсирлектәге батырлыкларын шаһит итүе сюжетны җанландырып баралар. Башта күксел томан гына булып шәрехләнгән фактлар да тора-бара мәгънә алалар, югалмыйлар.

Мактауларның кирәге юклыгын белеп, эш өчен, нәшрият һәм автор өчен файдалы булыр дип исәпләп, турыдан-туры тәкъдимнәргә күчәм.

Иң әүвәл, һәр бүлек алдыннан килгән «хәзерге заман нефтьчеләр тормышыннан эпизодларга» күз салыйк. Романның күләме артык нык сузылган дигән хакыйкатькә ышансак, бу «кереш сәхифәләр»не кискен рәвештә кыскартырга кирәк булачак. Роман авыр башлана. Гади генә, әмма укучыны кызыксындырырлык итеп башлап җибәреп булмыймыни?.. Әйтик, автор, көтмәгәндә-уйламаганда, Мәскәү комиссиясе белән Чулман буендагы шәһәргә барып чыга. Газинең монда икәнен белми әле ул, эшләр белән мавыгып, соңгы елларда әллә ни уйламаган да... һәм шунда юлдашы, әлеге Анатолий Сепановичның сукыр эчәгесенә ашыгыч операция ясарга кирәк була да... автор баш врач белән Гази арасындагы низагка шаһит була... Боларны өч-дүрт җөмлә белән бәян итеп булыр иде. Монда сузуның кирәге юк, 16-17 бит, автор һаман Газиның серлелеген хәбәр итүдән уза алмый. Баш врач Хәмзин образының эзлеклелеге турында да уйлыйсы бар. Бораулау мастерының үлеме Хәмзин белән Газинең чәкәләшүенә сәбәп булырга тиеш. Югарыдан: «Мастерны-депутатны саклап калыгыз!» – дип боерык бирсәләр дә, врачлар аның гомерен алып кала алмыйлар. (Мастерны соң китергәннәр, ә соңару сәбәбе ачыкланмаган. Моның сюжетка файдасы тиюе бар: депутат, дип, кайсы больницага алып барырга белмичә, бәхәсләшеп вакыт уздыралар ялагай бюрократлар!)

Хәзер больницасына Мәскәү кешесе тап булгач, Хәмзин курка кала. Скандалдан шүрли! Әгәр бер-бер хәл булса, депутатның үлеменә тагын кара күләгә ялганачак... Хәмзин әлегә артык ачык, артык дәрҗәдә җүләр.

Шунда ук без Дисә белән танышабыз. Нигә Дисә? Нинди исем бу?! Автор үзе дә бутала, кай урында аны «Ниса» дип уза. Хәмзиннең Дисә белән сөйләшүләренә дә җитдилек һәм тормышчанлык җитеп бетми. Дисә дә образ буларак бөтен үк түгел әле. Аның Казаннан чыгып китү сәбәпләре җитди, шуңа күрә Хәмзингә эш сорап кергәндә ул үзен чак кына башкачарак тотарга мәҗбүр түгелме? Бу турыда да уйларга ярыйдыр, минемчә.

Роман шактый озын, вакыйгаларга катнашучылар исемлеге бай, сюжет тармаклы, шуның өчен күзәтүләрне авторның каләменә тотынып ясасак, барыбыз өчен дә кулайрак булыр, дип саныйм. Димәк, автор артыннан алга!

Дисә белән Гази мөнәсәбәтләрендә романда җылылык туа, сюжет җанланып ала (65-67 битләр). Ниһаять, күңелгә Гөлүсә иңә, аның аша без Иргали юлына чыгабыз. Ачлык еллар, НЭП заманы. Авылда хәлләр катлаулы. Укытучы, избач Хәят төнлә

Мәхмүт Хәсәнов

җыелыштан кайтканда каршысына кемдер чыгып, аңа яманлык кылырга ниятли, яный. Хатын көчкә качып котыла. Мөһим вакыйгамы? Әйе! Хәятнең Бәһрам янына кара таңнан килеп җитмәве, шушы хәбәрне җиткермәве аңлашылмый. «Авыл советы рәисе дә «бу хәбәрне бик тыныч кабул итте», – ди автор. Ни өчен? Дошманнардан курыкмыймы Бәһрам?.. Әллә башка сәбәпме?!. Хәят килгәч тә шактый утыралар әле алар, озаклап утыргач кына: «Хәят кичәге вакыйганы сөйләп бирергә кирәк тапты», – ди автор. Моннан да олырак вакыйгалар бармы авылда. Аңлашылмый кала.

Авыл советыннан әллә ни ярдәм таба алмаган кичәге солдат Иргали хәзрәткә тап була. Иргали белән хәзрәтнең сүзләре артык сузылган, әһәмиятсез ваклыклар. Гази, Хәмзин, Дисә тирәсендәге әһмиятле вакыйгаларны ерагайталар. Бу урында шуны да искәртергә кирәк. Баш врач Хәмзингә нечкәлек, дипломатия җитеп бетми сыман, ул Газинең узганнары турында кирәгеннән артык күп сөйли, бөтенләй зарури булмаган очракларда да үзенең кемлеген бик тиз ачып сала. Мәсәлән, 177 нче биттәге «ләкин бит чын совет кешесе булу өчен ул гына җитми» дигән җөмлә артык демагогик булып яңгырый. Безнең көннәрдә «баш кешеләр», шул җөмләдән, баш врачлар да болай сөйләшмиләр инде, бу – бүтән чор сөйләү формасы, хәзерге заманда шулай уйлаган бәндә дә башкача сөйләшергә кирәген яхшы үзләштерде. Автор моны үзе дә яхшы белә, берничә ел узуга, «кеше тормыш шартларына бары тик яраклаша гына бара», ди. Хәмзин – яраклашучы. Газины үткәннәре белән адым саен битәрләп тора икән, ул – тар күңелле демагог, куркыныч бәндә. Мондый типтагы кешеләр роман битләрендә әле алда очраячак, нефтьчеләр арасында да күрербез без аларны, НКВД тикшерүчесе сыйфатында да очрар ул безгә, әлегә Хәмзин – берсе, беренчесе. Шуның өчен бу типны да алдагыларына законлы рәвештә ялгар өчен, Хәмзиннең осталыгын, мөртәтлеген, ике йөзле булуын оста күрсәтәсе иде. Хәмзин – яраклашуның мастеры. Хамелеон. Авыруларны түбән кастага һәм «номенклатурныйлар»га бүлә торган хәзерге заманның иң куркыныч врачы. Ул шул бәһане алсын иде.

Автор «беренче рекомендациясендә» Бәһрамның «белеме сай» дип беркетеп уза. Баксаң, сүздә Бәһрам оста лекторлар кебек сиптерә. Блокның «а покой только снится нам!» дигән тәгъбирен урынлы куллана. 202 нче биттә Иргали белән кабат очрашуын гына карыйк. «Матурлык һәм бәхет гимны авазларын ныграк ишетәм кебек!»

– дип җиффәрә. Бәһрамның 203 нче биттәге «бәхет» турындагы фәлсәфәсе дә авыл агае өчен соң дәрәҗәдә «хикмәтле». Гомумән, бу образның эчке логикасы ачыкланып бетмәгән. Иргали кулга алынгач, аның НКВДга барып җитүе дә, тикшерүче белән парма-пар ызгышып, «права печать» итеп маташуы да җитәрлек нигезләнмәгән.

Иргали беренче «чыгышларында» рухы сынган, көчсез кеше. Ул туган ягында мондый ук бөлгенлекне көтмәгән иде. Иргали аптырашта. Бу аптыраш халәте озынгарак китә түгелме? Рухы сыну озак дәвам итә, ниһаять, 203 нче биттә генә без аны эш өстендә күрәбез. Дөнья бер Бәһрам белән генә чикләнмәгәндер лә?! Заманында офицеры Клячкинны газдан коткарган Иргали бит ул! Большевик Акимга куркыныч янагач, «өермә кебек ябырылып, Акимны яклаучы солдатлар арасына барып кергән», тормышын куркыныч астына куйган солдат бит ул (221 бит). Ниһаять, автор 379 нчы биттә «Иргали ифрат үткен, гаярь холыклы» дип тәкъдим итә. Офицерын коткарган, Аким өчен тартышның уртасында булган кеше, гаиләсенең аяныч хәлен күргәндә, мондый ук битараф, көчсезләнеп җебеп төшәрме икән?!

Ниһаять, Иргалиның хәтеренә офицеры Клячкин төшә. Ул, ярдәм эзләп, Казанга барырга ният кыла. Инде Иргали тәвәккәлләде, инде чыгып китте, яңа вакыйгалар уртасына кереп китте, дисең, юк, автор гел кирәкмәскә, аның юлына киртәләр кора. Чыгып киткәндә буран башлану әсәргә хаҗәтме? Икеләнүен күрсәтергә кирәксә, икеөч көн вакыт, хатыны белән нык кына бер сөйләшеп алу җитмиме?! Сүзнең кадере югала, характер төссезләнә, сюжет сөрлегә, авызның тәме бетә. Менә кая илтә әсәрне тиешсезгә суза башласаң!

Иргали сәфәргә чыгуга авторның «икенче сулышы» ачыла, эпизодлар кызык-кызык төен булып ялганалар, фикергә җан-хәрәкәт бирәләр. Роман 300 нче биткә кадәр җанлы бара! Тик ике очракта шик белдерәсе килә: берсе – Клячкиннар йортында Ксениянең Иргалигә пычрак ишарәләрен күрәсе килми. Йорт-кешеләре әйбәт булып хәтердә калсын иде. Икенче шик шактый җитди, ул төпле уйлауны, нигезле чишелешне таләп итә. Динис артык юмарт, соң дәрәҗәдә мул куллы кеше. Ни өчен эшли ул бу яхшылыкларны? НЭП чоры, онытмыйк: кешеләр психологиясендә аерым бер урын тоткан заман. Динис – Клячкиннар түгел. Әле ул кеше кулындагы фигура гына. Төп фигура Кузьма-Бурлак исемен әйтеп котылып кала. Разбойниклар арасында исеме пароль урынына йөргән бу сәер кешене бер-ике сүз белән ачыграк беркетеп киткәндә реалистик роман битләренә килеп кергән серлелек сүтелеп калыр иде.

Иргалиның тормыш яхшырды. Ә авыл халкы, күпчелек ни хәлдә? Бу хакта да берникадәр ачыклык керткәндә ярар иде кебек. Иргалиның мулла белән мөнәсәбәтләре кызыклы гына борын төртеп куйса да, бу бәйләнышның да үсеше күренми диярлек.

«Өченче төн» акрын туа. Авторның хәзерге көн күренешләре хәтердә калмый. Газинең уйлары тагын Гөлүсәгә барып тоташа... Шул җәһәттән без колхозлашу елларына аяк басабыз. Күмәк хуҗалыкка бик озаклап мәдхия укый автор, арага Шәвәли образын китереп кертә. Шәвәли белән колхозлашу еллары процессы авыр берләшәләр. Автор гомум билгеле фактлардан ары узмый, дисәк тә ярый. Бүген коллективлашу чоры турында Шолохов үрнәгендә язарга ярыймы? Әллә аның башка яклары да булганмы? (Әлерәк кенә «Роман-газетада» бөек Василь Быковның «Знак беды» повесте басылды. Яңа сүз! Кыю сүз! Тарихта ачыш булып кала торган сүз!)

Инде җирдә тернәкләшеп килгән Иргалидә рухи үзгәреш, яңарыш булыр дип көткәндә автор кайта-кайта һаман аның Җиргә мәхәббәте турында сөйли (358-360 нчы битләр). Артыкка китмиме?

Хәзер романдагы иң четерекле урыннарның берсенә килеп җиттек.

Автор: «Иргали эшләп баеды», – ди. Бу тезис, һичшиксез, берьяклы. Димәк, ярлылар ялкау булганга, юньләп эшләмәгәнгә ярлы дигән караш туа (361 б.) Шәвәли шушы фикерне үзе дә раслый: «Чөнки без ялкаулар, булдыксызлар», – ди (364 бит). Ярлылыкның социаль нигезен кире кагу килеп чыга түгелме? Массаларның социаль изелүе, экономика законнары бер якка тибәрелеп калдырылмыймы? Әйе, тырышкан – табар. Ләкин һәр очракта да түгел.

Автор бу хакта «тел ярышлары» ачып җибәрә, мәйданга Шәвәли, Иргали һәм Халәп дигән адәмнәрне чакыра. Алар озаклап-озаклап, вакытның кадерен онытып, «пар нарат арасында» бәхәсләшәләр дә бәхәсләшәләр. Бәхәс кенә тумый, чөнки бәхәснең җирлеге юк. Сүзләр артык акыллы да кебек, хәзерге заманчарак яңгырыйлар, мәсәлән, Иргалинең язучыларга биргән бәясен автор бүгенге карашлардан алган (377-378 нче битләр).

Иргали Клячкиннар ярдәмендә тернәкләнде, ниһаять, баеды. 382-383 нче битләрдә тагын шуны туглауның зарурлыгы бармы? Иргали Халәпне дә сынап карарга тели: «Ярдәм итим үзеңә, акча биреп торыйм», – дигән сүзе ачыклауны сорый. Шаяртамы Иргали, җитдиме? Әгәр җитди икән, бер Халәпкә акча биреп кенә тирә-ягындагы бөлгенлектән чыга аламы халык? Образ ирексездән кечерәя. Чөнки шик туа: ярдәмнең бердәнбер юлы шулмы? Фәкыйрьлектән һәркем Иргали методы белән котылырга тиешме?.. Күмәкләшү турында ил буйлап сүз барганда мондый ансат сүзне ычкындырырмы Иргали? Һәм шушы сүз чыкканда моңарчы тинтәгрәк булып күренеп калган Халәпнең җавабы Иргалинең тәкъдименнән өстенрәк, акыллырак яңгырый. «Намусны әҗәткә алыштырмыйм!» – ди Халәп. «Бер ирек куйсаң, күңел байлыкка нәфесләнә», – дип өсти. Иргали психологиясенең тирәнлеген автор өстән-өстәнрәк уза. Тормыш дөреслегенә, образның мөмкинлегенә тугрылык саклыйк, дисәк, монда җитди сөрәсе буразналар чи калган. Байлык – кайсы чорда гына булмасын, кешенең психологиясен тиз һәм тамырдан үзгәртә. Байлык – иң каты тимерне дә күгәртә ала торган чир! Авторның Иргалине өзелеп яратуы факт. Шуның өчен ул аны корымлы казан яныннан да чип-чиста хәлдә уздырырга тырыша. Иргали берчакта да байлыкка кызыкмады, ул чиста килеш калды, дип раслый. Әгәр Иргали автор сызыгыннан чак кына тайпылып алса?.. Сюжет файдасы сыйдырган кадәр генә?.. Җитмәсә, моңа мөмкинлекләр бар. Җитәрлек! Халәпнең: «Комсызланып, хатыныңны кешелектән чыгардың, гарип итеп калдырдың!» – дигән хөкеме хак ич! Әсәр агышыннан, тормыш логикасыннан чыгып, мин дә бу фактны нәкъ шулай кабул иттем. «Бу кадәресен, мондый аяусыз-шәфкатьсез сүзләрне Иргали көтмәгән булса кирәк», – ди автор. Димәк, ул да уйланырга мәҗбүр, ул гадел хөкем ишетте. Кулына байлык кергән Иргалинең күңелендә юшкын утырып калмадымыни? Аның бик озак еллар колхозны санга сукмавы шуны раслый түгелме?

Халәп – куркыныч кеше. Аның дәвамы бүгенге көннәргә килеп җитә. Доносчы, анонимщик аның бүгенге аты. «Язу-сызуны белә, аңа дәшеп, ник дәштем көненә төшүең бар», – ди автор. Аны яктыгарак чыгарасы иде...

Печән өсте күренешләре мастерларча, авылны белеп, эшне-хезмәтне сөеп язылган. Гази белән Гөлүсәнең ирексездән сәяхәте, ярык көймә астында уздырган төн күренешләрен сокланып укыдым. Мәхмүт Хәсәнов прозасы үскән, ныгыган, җегәр һәм ышандырырлык көч алган.

Кызганычка каршы, «дүртенче төн»нең кереш аккордлары шактый ук тонык тора. Газинең пленда булуын автор да чәйнәргә тотынгач, бераз артыкка китә. Җитмәсә, ул бу фактка икеле-микеле бәһа бирә. «Нинди генә батырлыклар күрсәтсә дә, әсир – әсир инде ул!» – дидем мин үзсүзләнгән булып!» – ди (429 бит). Ни өчен «үзсүзләнә»?!

Күңелле мизгел: Мәхмүт Хәсәнов хатыны Мәрьям белән

Әсирнең тамгалы булып калуын яклыймы Фәйзи, әллә аның уе башкачамы? Өзеп бер фикер әйтсә, ни зыян? Кем файдасына бу серлелек?!

М.Хәсәнов нефтьчеләрне, алар хезмәтенең кызыклы ваклыкларын белә. Әмма фактлар роман тукымасына кереп, сеңеп бетеп бармыйлар. Романның шул тармагы – хәзерге заманга багышланган өлешләре бераз кайтышрак язылган. Яхшы җирлектәге ямау сымаграк тормыйлармы алар? Әле генә сокланып укыган Гази-Гөлүсә дуэтыннан соң бу юллар колакны яра...

Югарыда әйтелгән бер фикергә кайтыйк. Әсәрнең төп сызыгыннан төшеп-төшеп киткән моментлар байтак очрый. Юрист булырга укып йөргән Һадинең авылга кайтып, аны-моны да аңышып тормастан, җәнҗал кубарып, сугышып төрмәгә эләгүе ышандырып бетерми. Көнләшсен дә, ди. Кайтсын да. Чыдары шартлап сынып, чәкәләшеп тә алсыннар. Тик боларны психологик ышандырырлык итәсе иде. Һади белән һәр очрашу хәтердә кала болай. Аның Айзәре белән очрашуы, капчык асып, авылга кайтып керүе мавыктыргыч язылган...

Иргалинең баш очында аяз көнне яшен яшни: аны Халәпне үтерүдә гаеплиләр. Монда кызык бер момент бар. Авыл халкы арасыннан: «Хәрәмнән килгәнне тормыш һәрчак каза белән түләтә!» – дигән хөкем авазлары яңгырый. Димәк, авыл халкы Иргалинең баюына кул чабып кына тормаган икән! Сюжет һич көтелмәгән мөһим якка борыла. М.Хәсәнов сюжет койрыгын оста тота. Ниһаять, Иргали япа-ялгыз калуын, аның ачылыгын аңлый (472 бит). Соңарып төшкән акыл! Автор: «Иргали колхоз кадәр колхоз белән ачыктан-ачык ярышып, көч сынашып яшәде», – ди. Кыю фикер. Кыю кеше. Заман диңгезендә чайкалган ялгыз җилкән. Тик без моны алдарак, Иргалинең баю, мал артыннан куу чорында күрергә тиеш идек инде. Иргалинең сыну моменты элегрәк күренсә иде. Логика шуны сорый! Романның югары сыйфаты шуны таләп итә. Автор һаман Иргалине акшарлый: «Комсыз кеше түгел иде Иргали», – ди. Комсыз түгел иде, ди, – комсызланды». Шулай әйткәндә, дөресрәк булмасмы?

1934 ел җиткән. Әле аның колхозга кергәне юк. Сәбәп нидә, кирелекнең тамыры кайда? Монда ачыклык, чын заманча аңлату сорала. Иргалинең НКВД тикшерүчесе Миңнеханов белән сөйләшүе авыл кешесенә хас түгел. Дөнья күргән кеше Иргали, мәгәр ГПУ-НКВДлар белән өркеп яшәгән бер чорда Миңнеханов Иргалигә шул сүзләрне әйттереп торамы? Әйткәнемчә, Бәһрамның НКВДга кереп койрык күтәреп

йөрүе дә гади калай этәчләнү генә. НКВД – зур көч. Заман кискен. Бәрелешләр, хөкем чоры. Аерым кеше – агымдагы нәни йомычка. Бар, төрмәгә кереп, Иргали сыман Котан батыр булып маташ син! Автор һаман Иргалине алтынга мана, ул төрмәгә кереп, хәл үтә кискенләшкән мәлдә дә аның юмартлыгын, авыл халкына күрсәткән файдасын саный (523-529 битләр). Иргали Миңнехановның икенче допросында да үзен үтә белдекле батыр итеп тота. «Каян килеп оялыйлар шушындый урынга сезнең эше хашәрәтләр!» – дип резюме ясаудан да курыкмый. Ул елларда шушы сүзләре өчен Иргалине чыгаралар да аталар иде. Бердән, ул мондый сүзне әйтә алмый. Төрмә, кеше үтерде, дигән гаеп, ипи белән су, гадәттән тыш шартлар. Болар бер дә Иргалине какшатмыйлармы? Каян килгән шундый ныклык-ышаныч аңа? Колхозга кермәгән нэпман, өендә ялчы тоткан диярлек, гарип хатыны белән гарип Рәхимҗанның күз алдында зина кылып бала ясаган ир... Куркырлыгы бар! Нибуч калтырарсың монда! Ә ул тикшерүченең үзеннән яман сүгенә, һөҗүм итә...

Газинең әсирлектә узган чуар юллары тәэсирле каләм белән иҗат ителгәннәр... Гыйбрәтле хәлләр, гадәти булмаган язмыш. Шушы язмышның юлын тасвирлаганда автор күпсүзлелек бизгәге белән кат-кат авырып ала. Мәсәлән, Һадиның Таҗины эзләп Азнакайга, райком бинасына килүен өч-дүрт сүз белән белдереп булыр иде. Муза Мәхмүт! Сүз – мәгънәне тудыра да, үтерә дә. Ачы хакыйкать. Без алда да М.Хәсәнов образларының озын-озын монологлары белән танышкан идек инде. Салиха апа да (774), Гаделша карт та (760-766 битләр), озын сөйләп, сюжет агышын акрынайталар. 668 нче биттә хөрмәтле «нефть магнаты» да монолог сөйләп ташлый. Гәрчә, момент кискен! Очрашу урыны җаваплы. Таҗи әлерәк кенә райкомның беренче секретаре итеп сайланган, һич көтмәгәндә, төрмәдән Һади кайтып төшә. Таҗи үзе дә, хатыны да сагаерга, Һадидан тизрәк котылу юлын эзләргә тиешләр иде кебек. Таҗи – номенклатурный работник! Андыйлар «бывший ристаннарга» бары тик сагаеп кына карый алалар. Шәңгәревнең Һади язмышын хәл итәргә алынуы да артык кинәт башлана. Кем өчен һәм ни өчен тырыша?

Илгә кайткан Рәхимҗан хикәяләре аша Иргалинең озын, газаплы сәфәре белән якыннан танышабыз. Рәхимҗан хикәяләре кызыклы, образлы, тере. Ул хикәя-фаҗига моңарчы безнең әдәбиятта күренмәгән, күренә дә алмаган кыю юлларны – тормыш яңалыгын китапта саклап калдырырга иде! Руслар ул чорга да әдәбиятларында кыю рәвештә үтеп керә башладылар. Безгә дә вакыт, вакыт! Афәрин, Мәхмүт, дип кычкырасы килә! Иргалинең «кыр батыры, тәвәккәл» икәнлеген ачарга киң мәйдан ул Себер сәяхәте. Автор шулай эшли дә. Иргалинең кешелеклелеген арттырган сыер сатып алу вакыйгасын Сираҗиның баласы үлүгә бәйләргә кирәк. Олауларда башка күкрәк балалары да булгандыр ич?!

Сюжет, әйткәнемчә, тыгыз үрелеп бара, Шаһи, Шаһбәзләр арага кергәч, тагын да куера, кискенләшә.

Укый-укый романның эчке бер хасияте ачыла: ул бик күп монологлардан тора икән. Иң әһәмиятле урында Гази монологлары. Аның эчке халәтенә аваздаш булып, Гаделша монологлары кушылып китә. Бик күп җитди проблемаларны күтәрә йөз яшәгән карт! Аның табигатьне саклауга, экологиягә караган фикерләре чын-чынлап сискәндерә. «Искелек калдыкларының нигезе» турындагы тапкыр соравы да үтә урынлы яңгырый, уйландыра. Кешеләр бер-берсе белән бәхәсләшкәндә дә күп очракта монологлар сөйлиләр. Мәгыйшә-Иргали, Тикшерүче-Иргали, Гаделша-Гази һ.б. Кадыйр Надыйров та, тәүбәгә килергә вакыты җиткән гөнаһлы җан кебек, Гази алдында ачыла. Кадыйр Надыйровның монологын тыңлаганнан соң, Гази: «Адәм баласы шултикле дә кара эчле, каты бәгырьле булыр икән», – дип хәйранга калды», – ди

автор. Кырык үлемне, мең батырлыкны, йөз хыянәтне күргән, адәм улларының меңгә төрләнә алуының тере шаһиты Гази алай уйлый алырмы хәзерге хәлендә?.. Аны бары тик туган илебездә андый кара күңелләрнең каян килеп чыгуы һәм ничек яши алулары гына гаҗәпләндерә алыр кебек. Җәүһәрия кебек изге җаннар, Кадыйров кебек кара эчле бәндәләр Газины төрле яктан ачарга ярдәм итәләр... Урыны-урыны белән агым акрыная, Фәйзи, Рәисә, Һади катнашкан күренешләрдә тәмам өзелеп тә кала.

Автор инде чишелеш, инде йомгак көткәндә Һади кебек авыр кешеләрнең табигатен ачарга тотына. Йомгакны укучы үзе ясый ала, чөнки ул роман битләрендә кеше язмышларының төрлесен күрде ич... Һади язмышына йомгак кирәккәнгә генә тагын производство ваклыкларына кереп китү урынлымы икән?!.

Романны тарап, бик нык кыскартып, беркадәр ачыклап чыкканда сыйфаты тагын да яхшырыр иде, дигән ышанычым бар. Әлбәттә, аны китап итеп чыгарырга кирәк. Автор: «Зәйтүнә кирәккә-кирәкмәскә дә «лар-ләр»не өстәргә ярата», – дип искәртә. Бер Зәйтүнә генә сөйләшсә икән алай! «Лар-ләр»не, күплек билгеләрен сызарга кирәк. Телдәге чатакларны, мул сибелгән рус сүзләрен өлешчә текст өстендә билгеләп бардым. Кайбер фикерләр дә анда теркәлгән.

Автор кайберәүләрнең күкне-җирне, суны-җырны «рус каены, рус камышы» дип тамгалап баруын хөкем итә. Ифрат дөрес фикер. Ләкин һәр дөрес сүзне китап бите күтәрә алырмы икән? Бу турыда тарихта сүз, гадел хөкем булыр, аны русның акыллы кешеләре күтәреп чыгармы, башкача хәл ителерме – безгә сабыр гына көтәргә кала...

Роман йөрәк кылы чыңлап өзелеп бетә. Колак төбендә Гөлүсәнең әрнеп кычкырганы иңрәп кала. Әсәрнең шулай бетүе яхшы да! Ул укучыны сискәндерсен – гомер итү майлы ботка ашау түгел. Заман-чор бериш кешеләргә, гали затларга, Гази-Гөлүсә кебекләргә һәрчак аяусыз, мәрхәмәтсез. Хәмзин озак яшәячәк. Газилар янып, дөрләп үлә бара.

Роман уйландыра. Фикерләр күп. Фикерләр кирәкле. Ләкин бик күп очракта алар ком арасындагы алтын бөртекләре кебек югалып та калалар. Әсәрне баштанаяк бик нык, акыллы күз белән кыскартырга кирәк. Роман әлегә бик күп сүзле. Сүзнең иге-чиге юк! Авторның теле матур, урыны-урыны белән искиткеч йөгерек, образлы. Сүзләр ишелеп килеп кенә телне авырайткан урыннар байтак. Иң беренче чиратта, романның һәр бүлеге алдындагы нефтьчеләргә кагылышлы өлешләрен кысарга кирәк.

Монологлар берсе дә гади түгел, алар серле. Һәрбер монологта кеше-образ исеменнән чор сөйли. Мәгънә кадере артсын өчен, сүз кадере өчен көрәшергә иде! «Язгы аҗаган»нар ике урында очрый. Бу хакта да уйлыйсы бар. Автор кабул итсен, ул җәһәттән дә тәкъдимнәрем әзер. Сүз озынга китә, дип, язудан туктыйм.

Кабатлыйм, романның зур, олы һәм бик кирәкле әсәр булырга тулы мөмкинлеге бар. Автор тагын бер ыргыла да... Тәмам булачак!

Мин кульязманың өченче нөсхәсен укыдым. Чепи күзле, сукыр битләр бик күп. Чиксез көчем, бихисап күз нурым түгелде. Ә, тагын бер фикерем калган: табигать күренешләре артык шомлы, яңгыр да кар, боз да җил. Бара-бара бертөрлелек күзгә ташлана... Тагын нидер әйтәсем дә бар иде, ярар, җитеп торсын...

Авторга уңыш телим!

16 февраль 1985 ел, Казан. Кич. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

МӘГЫЙШӘТ*

Садри Максуди

I

Халид агай, сату-алуга булганлыгы, алыш-бирешкә осталыгы аркасында, картлыгына таба зур байлыкка ирешеп, тормышы иркенәйгән, эшләре юлына салынган иде. Аның төп сәүдәсе тире-яры илә булып, Къ шәһәреннән тире илә сәүдә кылучыларның иң бае һәм әлеге эшнең иң остасы иде. Ул елларда Къ. шәһәрендә тирече күп булмаганга, тире кәсебе бөтенләй мөселманнар кулында кеби булып, файдасы да бик яхшы иде. Шуңа күрә Халид абзый 60 яшьләренә килгәндә, дүрт-биш йөз мең сумма иясе була алган иде. Халид агай симез генә бәдәнле, түгәрәк йөзле, җонласрак кына бер адәм иде. Бу яшьләренә килгәндә сакалы, саче, мыегы һәрбере яртылай агарса да, йөзенең рәвешендә агармый калган төкләреннән әүвәлдә дә кара төкле бер кеше булганыны белергә мөмкин иде. Халид абзыйның кыяфәте тугры, тәкъва-и саф күңелле кешеләр кыяфәте иде.

[...] Бик зур бер дәүләт өстенә бу яхшы сыйфатлары да җыелганга, шәһәр халкы арасында сүзе үтә торган игътибарлы кешеләрнең иң зурысы булып, кайда гына бер мәҗлес булса, Халид агай булыр, кайда гына бер сүз чыкса, Халид агай катышыр иде. Халид агай яхшы күңелле булганга, кеше өчен кайгыручан, халык файдасын төшенүчән иде: сүзе үткән кешеләргә һәрвакыт вәгазь-нәсыйхәттә, Халид агайның вәгазе, димләгән нәрсәсе – искелек иде. Дөньяда искелектән сөйгән нәрсәсе юк иде. Һәр эштә искечә булуны, әүвәлгечә торуны ярата иде. Аның уенча, халыкның ярлылануында, азуында сәбәп – яңа чыккан нәрсәләр, имеш. Үзенең бу уен дөрескә чыгарырга төрле дәлилләр дә сөйли, әлбәттә, дәлилләре дә фикере төсле үк иде. Халид агай үз фикеренә бик ышанган, үз гакылына бик инанган бер кеше булып, һәр эштә, һәр турыда үзенең фикерен дөрест, уен тугры дип уйлый иде. Шуңа күрә үзенә хас булмаган эшләргә дә катышып, киңәш бирү, мәслихәт сөйләү – гадәте иде. Яшьтән сәүдәгәр булганга, сәүдә хакындагы сүзләрен, мәслихәтләрен тугры санарга яраса да, башка тугрыларда күп сөйләшүе, билгеле торуы бик урынлы түгел иде. Хосусан, мәдрәсәләр, укулар-укытулар хакындагы сүзләре бер көлке генә иде, чөнки үзенең аз-маз язу чамаларлыктан артык гыйлем булмый торып, галим бер адәм (педагог) кеби гыйлем эшләрен тикшерүе галим адәмнәргә бик кызыклы тоела иде. Халид агай үз мәхәлләсендәге мәдрәсәнең фәхри мөдире (попечителе) булып, утын, керосин, кизүләренең яллары һәрбере аның акчасы илә үтәлә иде. Мәдрәсәгә моннан башка рамазанда зәкят кертү, ашларга чакыру кеби күп яхшылык кыйла иде; шуңа күрә шәкертләр Халид агайны яраталар иде. Яту-тору, ашау-эчү кебек эшләрдә Халид агай теләгәнчә булырга, аңа каршы килмәскә тырышалар иде. Алай булса да, Халид агай илә шәкертләр арасында күбесенчә низаглар да булгалый иде, чөнки Халид агай шәкертләрнең тормышларының үзе эстәгәнчә булуы илә генә дә канәгатьләнмәй, укуларының-укытуларының да үзенең надан фикеренә муафыйк булуын телидер, котыртучы кешеләрнең сүзләренә карап, мәдрәсәгә барып, укуларын килештерми, шәкертләрне төрлечә борчый иде. Мәсәлән, бер шәкерт мантыйкны яманласа, иртәгесен кереп, «кирәкмәс, мантыйк укытмагыз, кирәк нәрсә түгел, күңел каралтып, фәлән», дип шаулап йөрер иде. Берничә вакыттан соң мантыйк яхшы

*Роман кыскартып бирелә.


محرری : صدرالدین بن ملا نظام الدین المقصودی

معیشت

ملی رومان

هر حقوق محررینه عائددر

Татарстан Җөмһүриятенең
Милли китапханәсе
Национальная библиотека
Республики Татарстан

Дозволено цензурою С.-Петербургъ. 7 Мая 1900 г.

КАЗАНЬ.
Типографія ТорговагоДома Братьевъ Каримовыхъ.
1900 г.

Садретдин бине мелла Низаметдин әл-Максуди. Мәгыйшәт. Милли роман. – Казан, Борадәран Кәримевләр матбагасы, 1900 ел

Хәзрәт һәр эштә Халид ягына ятып өйрәнгән иде, эшнең алдын-артын уйламаенча, төрле китапларда күргән кыйссаларны сөйләп, фәлән падишаһның фәлән кадәр хатыны булган, фәлән солтанның фәлән кадәр хатыны, шулкадәр кәнизәге булган кеби сүзләр илә, Халидкә яшь хатын алуны, түгел мөмкин, дөрест кенә, бәлки тиешле бер күркәм эш итеп чыгарды.

гыйлем, бик кирәк нәрсә, фикер ача, фәлән, дип мактасалар, «укытыгыз мантыйкны, бәхәсләшеп укыгыз, мантыйк кешенең зиһенен ача», дигән булып, кеше сөйләгән сүзләрне сөйләп йөрер иде.

Халид агай һәрвакыт «мин надан кеше», дияр иде, [...] ләкин наданлыгын теле илә әйтсә дә, эченнән үзенең наданлыгын белми иде, чөнки күңеленнән наданлыгына ышанса, надан кеше катышмаслык эшләргә тыгылмас иде.

[...] Шәһәрдә Халид агайга буйсынмаган бәгъзе яшь кешеләр дә булгалый иде, ләкин андыйларга Халид агай, ничек булса да, бер җай чыгарып, ачуын алырга, аларның алга киткән эшләрен юлдан чыгарырга тырыша иде. Тәкъва исемен күтәргән бер кешегә бу холык бик килешеп тормаса да, гаеп буйсынмаучыларның үзләрендә булганга, мондаен яшьләрдән ачу алу, дошман итү Халид агайга, гаепкә саналу кайда, киресенчә, Халид агайны сөйгәннәр арасында: «Менә фәлән Халид абзыйга исе китмәгән булып, киңәшләргә килми йөргән буладыр иде, Халид агай үзен нишләтте?! Халид абзый, ачуы булып, алмыймы соң!» – дип, бер зур гайрәт итеп сөйләнә иде. Һәм дөресте дә, булганрак бер егет, Халидкә бик иеләсе килмәенчә, үз алдынарак эш кыйлса, Халид бай шуңаниләр итсә итеп, бер зарар китерергә тырыша иде.

[...] Чит кешеләр һәрьяктан килгән, дип мактасалар да, бик якыннары бер холкын бер дә килештермиләр иде. Ул холкы да хатын-кызга артык һәвәслелеге иде. Тугрысы, Халид агайның бу холкы бер дә килештерерлек түгел иде. Бөтен эшләрендә үз-үзен никадәр тота белсә дә, хатын-кызга бик ваксынучан иде. Очраган хатын-кызга күз салмый китү Халид агай өчен мәхәл, хәтта мәчеткә барышлый-кайтышлый юлыккан хатын-кызга карау карт байның гадәте иде. Яше алтмышларга йиткәч, бала-чага атасы

булгач, Халид агайның бу сыйфаты да булуын кем ошатсын?! Кайсы кешеләр Халид агайның болай булуына сәбәп җәмәгате Хәлимә абыстай илә ике араларында мәхәббәт булмавыдыр, дип уйлыйлар иде, ләкин яңлышалар, чөнки Хәлимә абыстай Халид агайны сөйгән кебек, Халид агай да Хәлимәне чын күңелдән ярата иде. Халид Хәлимәне ни өчен сөймәсен? Хәлимә абыстай кыз вакытында ук яхшы холыклы, күркәм йөзле, җайлы сүзле иде; Халид агай Хәлимә абыстайга өйләнгән вакытта артык дәүләт иясе түгел иде – Хәлимә абыстай килгәннән соң, һаман ачылып, эше алга китте. Чөнки Хәлимә абыстай күңелгә шатлык, җанга рәхәт бирүче җайлы йорт хатыннарыннан берсе иде... Халид агай Хәлимә абыстайны алганда, дәүләте ул дәрәҗә булмаган кеби, тәүфыйгы да уртача дәрәҗә иде. Хәлимә абыстайны алуы илә тәүфыйгы төзәлгән кеби, хәяте дә алга китте. Хәлимә абыстайның атасы Халидкә караганда күп бай иде, алай булса да, Халидкә кызын бирде, чөнки Халид егет вакытыннан ук сату-алуга осталыгы, кеше белән эш кыйлырга булганлыгы белән мәшһүр иде. Хәлимә абыстай атасына бердәнбер кыз булганга, атасының вафатыннан соң утыз мең акча, йорт-йирләр һәркайсы аның исеменә калган иде. Халид агайның сумасы 7-8 меңнән артык булмагандыр, шуның өчен, эшен зурайтасылары килеп, Хәлимәгә калган мирас акчасының азрагын банкага салсалар да, күбесен суммага кушып йибәргәннәр иде. Асылда, Халид агайның эшләре зураеп, сатуның җайга китүе шул көннән башланды, юкса, коры осталык белән 5-6 йөз мең суммаларга ирешмәк булмас иде. Халид агай, Хәлимәнең тәүфыйгына, эшләренең алга китүенә, зураюына сәбәп булганын үзе дә беләдер иде. Күп вакыт тәмле сүзләр илә тәшәккүр итә белмәсә дә, «рәхмәт, сиңәйтим, минем бәхетем ачылуына син сәбәп булдың», дип әйткәлидер иде. Халид агайның, югарыда сөйләдегемчә, хатын-кызга шулкадәр хирыс булып та, моңа кадәр яшь хатын алмый торуы бары шул яшьтән яраткан, бәхете ачылуына сәбәп булган җәмәгате Хәлимәнең ригаясе хакына иде. Әүвәлдәрәк Халид, үзе никадәр яшь хатын алу исәбендә булса да, моңача ул фикерен йорт-җәмәгатьләренә белгертмәскә тырыша иде. Мәхәббәтле җәмәгате Хәлимәдән ояла, ләкин бу оялулар, ригаяләр Халид агайның дәүләте арткан саен кимиләр иде; бу ахыргы елларда ригаяләр бөтенләй күтәрелеп, Хәлимәнең үзенә дә күп вакыт: «Өйләнәм, разый буласыңмы? Мин сине рәнҗетү өчен алмаем ләбаса, ник разый булмыйсың?» – дигән кеби сүзләр илә борчый башлаган иде. Чөнки бу елларда байлыгы камиллегенә йитеп, саф 4-5 йөз мең суммасы булган иде; шуңа күрә Халид агай эченнән: «Аллага шөкер, байлыгым йитәрлек булды, инде байлыкның рәхәтен күрергә дә кирәк, дөрест, Хәлимә өстеннән өйләнү бик килешеп тә йитми, ни эшләмәк кирәк, Хәлимәнең картаюы хак бит, юкса, мәхәббәтем юктан түгел, Ходай беләдер, Хәлимәнең миңа булган файдаларын онытасым юк, Ходай бу кадәр байлык биргәч, рәхәтен дә күреп калырга кирәк. Гомерне бер хатын белән генә үткәрү минем кебек бай кешегә үзе дә килешеп җитми инде, Хәлимәне ригая кыйлам, дип, әле дә бик күп чыдадым: иншаллаһ, мин бу эш өчен гөнаһлы булмасам кирәк», – дип уйлый иде. Ләкин Халид агай шуны уйлый белмидер иде ки: Ходай Тәгалә байлыкны өйләнү өчен генә бирмәенчә, кешегә зарары тими торган кәефләр илә рәхәтләнер һәм хәер эшләргә сарыф итәр өчен бирмештер...

[...] Акрынлап Халид агайның бу фикере чигенә җитте. Һәрвакыт телендә өйләнү, яшь хатын алу була башлады: «Анагыз картайды, яшь хатын алам», – дигән сүзләре илә бара торгач, карт бай балаларын үзеннән биздерә башлады. Шуңа күрә боларның бу йорт эчләрендә ата-ана, бала-чага чөкердәшеп, сөешеп көн итүе юк иде: боларның йортлары гүя хәсрәтле бер йортка әверелде. [...] Хәлимә абыстай исә кырык ел ул яшь күңелен, мал-мөлкен, җәмален фида иткән сөеклесенең бу көндә ташлаячагын уйлап кайгыра [...] Халид бик күркәм кеше булмаса да, Хәлимә шулкадәр матурлыгы белән

дә Халидне кимсенми, үзенең насыйбына разый булып, [...] үзен аңа фида иткән, бар күңеле илә Халидкә ярарга тырышкан, тырышу илә Халидкә һәм ярап, ничә еллар аңа рәхәт гомер итешкән. Бар кайгысы сөеклесе Халиднең кәефен китерү, аның күңелен шат тоту булган. Шул рәвешчә 30-40 ел кичкәннән соңра, Халид агай аның бу яхшылыкларына каршылык, өстеннән яшь хатын алмак буладыр.

Халид картта бу өйләнү фикере һаман үсте, балаларының җалынычлары, җәмәгатенең хуш күрмәве – һичбере картны бу уйдан туктата алмады. Берничә вакытлардан соң бу вакытка кадәр уйда гына булган әлеге фикерен чынга чыгармакчы булып, халкымызның гадәте илә, иң әүвәл бу мәсьәләне хәзрәткә киңәште. Хәзрәт ни дисен? Хәзрәт һәр эштә Халид ягына ятып өйрәнгән иде, эшнең алдын-артын уйламаенча, төрле китапларда күргән кыйссаларны сөйләп, фәлән падишаһның фәлән кадәр хатыны булган, фәлән солтанның фәлән кадәр хатыны, шулкадәр кәнизәге булган кеби сүзләр илә, Халидкә яшь хатын алуны, түгел мөмкин, дөрест кенә, бәлки тиешле бер күркәм эш итеп чыгарды. Гаҗәеп безнең иске хәзрәтләрнең фикере! Хатын күп алуны ислам динендә мактаулы бер эш дип саныйлар. [...] Халид агай менланың үзенә җагымлы сөйләгәнен күргәч, бөтенләй кайдан алырга кирәген үк сорый башлады. Кайда кыз барын, кайдан өйләнергә кирәген белү менла эше булмаса да, Габделлатиф хәзрәт моны аермыйдыр, үзеннән ни генә сорасалар да, җавап бирергә үгрәнгән иде. [...] «Син, Халид, әлбәттә, өйләнгәч инде, яшь кыз алырга тели торгансыңдыр да, чибәр кыз алыйм, дисәң, тирече Хөсәен кызына йибәреп кара. Безнең остаз бик мактыйдыр, төскә-биткә дә күркәм, имеш, укымышы да бик яхшы», – дип, җаучылык та итеп куйды. Халид бай, хәзрәттән яхшы киңәш ишеткәннән соң, эшне озакка калдырмады: ике көн соңра җаучы хатын йибәрелде.

II

Тимерханов Хөсәен агайларга һич уйламаганда бер көн җаучы килеп керде. Хөсәен бай, җәмәгате Латифә абыстай Маһруйны күрү илә, кызлы кешенең гадәте билгеле инде, каушабрак өенә кабул итте, сөйләшә торгач, Маһруй абыстай җайлы гына үзенең Халид агайдан җаучылыкка килүен белгертте. Латифә абыстай бу сүзне ишетү илә, кызыма бик бай кешенең углыннан җаучы килде, дип, бик шатланып: «Фатихны өйләндермәкче була микәнни?» – диде. Моңа каршы җаучы: «Әле Фатихка өйләнү кая, ни кая?! Имгән сөте авызыннан кипмәгән дигән кеби, әле аның сызыкка кереренә дә бер-ике еллап бар бугай. Юк! Фатихка түгел, атасы Халид агай үзе яшь хатын алмакчы була», – дип, Латифә абыстайның яңа гына ялкынланган шатлык утын сүндерде. Латифә абыстайның кызына карттан җаучы килүенә бик кәефе китсә дә, Маһруйга аны-моны сиздермәде: «Мин, Маһруй абыстай, үзеннән башка бер сүз дә әйтә алмыйм. Ярый, әйтеп карармын, ай-һай, бердәнбер кызымызны картка бирергә разый булыр микән», – дип җаваплады.

[...]Җаучы китеп озак тормаенча, Хөсәен агай кайтып, Латифә абыстай иренә Маһруй абыстай килгәнлеген сөйләгәч, араларында шушы сүзләр йөрде:[...]

– Хи-хи, Халид агай үзе өйләнмәкче буламени? Күптәнрәк исәбе бар иде аның.

– Әйе шул, үзе өйләнмәкче була, имеш. Йа Рабби Ходаем, аш ашаган, яшь яшәгән, моңа кадәр гомер иткән карт көнендә бу эш нигә кирәк?!

– Һәркем үз эшен үзе белә, синең ни эшең бар?!

– Анысы шулай... Бирүен бирмәмез лә, атасы, ул карт юләргә?

– Алай ук өзеп бетерә алмыймын, бик зур сөйләшергә ярамый, без әллә кем түгел. Җаучының килеп торуы үзе бер куаныч, Халид агай начар кеше түгел, тәүфыйклы, булдыклы кеше, яшь-ябагай тагы түгел. Зурларга киңәшеп карарга кирәк.

– Әй, атасы, алай дия күрмәсәнә, аның суфилыгы илән әллә ни эшләп булмый,

яшьләрнең дә картлардан тәүфыйклысы буладыр. Минем кызым алай кыю түгел көндәш өстеннән кияүгә барырга, әллә нинди чая кызлар да, яшь хатын булып баргач, уңгайсызланалар. Ходайга шөкер, кызыбызның аты-суы чыкмаган, яше узмаган, Алла насыйп итсә, үзе кебек яшьләр дә табылыр.

***

[...] Хөсәен абзый бар күңеле белән баюга бирелгән бер кеше иде. Баю юлында никадәр читенлекләр күрсә, түзәчәк, никадәр авырлыкларга очраса, күтәрәчәк иде. [...] Иткән сәүдәсе, Халид агай кебек, тире-яры илә булып, ләкин аңа караганда эше күп кечкенә иде. Хөсәен агайның өстенә кигән киемнәре, һәркөн базарда тире илә чуалганга күрә, шомарып, ялтырап беткән киемнәр иде. Үзе юандак гәүдәле, чыгынты корсаклы, җалтырабрак торган битле, тәбәнәгрәк кенә бер адәм иде. Үз эшләрен яхшы йөртә белсә дә, халык илә катышырга осталыгы юк, тупас бер адәм иде. [...] Хөсәен агай җәмәгатеннән Халидтән җаучы килүен ишетүе илә, эченнән бирергә уйлады. Халидкә якынаю, аның ышанычына керү бик кыйммәт торадыр иде, чөнки Хөсәен агай, Халид бай илә катышып китеп, үзенең җаныннан кадерле булган байлыгын тагын да арттыру ихтималы бар иде. Хөсәен агай күптәннән Халид илә дустланырга хәйлә таба алмаенча йөридер иде.

[...] Бердән, гадәт булганга, икенчедән, хатынына җавап булсын өчен, бу эшне Хөсәен агай авылда хәзрәткә киңәште. Хәзрәтнең әйтәсе сүзе билгеле инде: баштан үзе димләп булдырган бер эшкә каршы килү ихтималы юк. Хәзрәт, Хөсәен эшне аңлаткач та: «Хөсәен, бер дә аңга-моңга карама! Замана бозылган, тәүфыйклы кеше табуы бик читен. Яшь кешенең баена да ышаныр хәл юк! Халид агай – сыналган тәкъва адәм. Төбәп сораткан, кайтарма, бир, иншаллаһ, уңарсың. Минем киңәшем шушы», – дип, Хөсәенне кыздырды.[...]

III

[...] Әткәсенең бу эше, бөтен өй җәмәгатьләреннән бигрәк, Халид агайның йиткән углы Фатихның кәефсезлегенә сәбәп булды. Фатих көләр йөзле, шат күңелле, бер мәҗлесен күргән кеше икенчегә күрергә теләрлек бер егет иде. Фатих, татарчадан башка, русча укырга-язарга, сөйләргә белгән кеби, госманлыча да укырга-язарга бер дәрәҗә беләдер иде. Һәрвакыт, «Тәрҗеман»нан башка бер русча, бер госманлы газеты укып, дөньяда булган эшләрдән хәбәрдар булып торадыр иде. Фатихның укыган китаплары арасында төрле хикәяләр, мәхәббәт һәм гыйшык романнары да очрап, өйләнү, мәхәббәт, гаилә сәгадәте кеби нәрсәләрнең нидән гыйбарәт икәнен яхшы аңлаган иде. Үзен никадәр сату-алуга ихлас биреп, һәрвакыт шулар илә мәшгуль булса да, фикереннән өйләнергә вакыт булганы, өйләнү һич үзенең сату эшләренә зарарлы булмаячагын белеп, өйләнүен бик соңга калдырасы килмәенчә йөридер иде. [...] Шәһәрдә Фатихка тиңдәш булырлык әллә никадәр байлар булып, күбесенең кызы бар иде. Ләкин Фатих аларның һәркайсын сораштырып, төрлесенең төрле гаепләре булганын белгән иде. Сораштыру соңында, үзләренә тиң баерак йирләрдә үзенә муафыйк кызлар булмаганын белгәч, түбәндәгеләрдән бер кыз эзләү фикеренә килде. Фатихтан түбәнрәк кеше кызлары арасында Хөсәен кызы Рәбиганы хатын-кызның мактап-яратып сөйләгәнен ишетеп, дөреслеген беләсе килеп, сеңлесе Һәдиядән сораштырды. Чөнки Һәдия 14 яшьлек бер кыз булып, Рәбига илә бер остазбикәдә укыйлар иде. Һәдия Рәбиганың әхлакый гадәтләрен һәм төс-битләрен бер-бер мактап сөйләгәч, Фатих Рәбиганы бик күрер һәвәсенә төште.

[...] Сеңлесе Һәдия булганга, Фатихка Рәбиганы күрү читен булмады: бер мәҗлес ясалып, Фатих та эстәдеге кадәр күрде, теләгәне кадәр сынады. Рәбиганың матур тавышлары, җайлы сүзләре, нурлы йөзләре, ягымлы кыйланышы ирексез Фатихны Рәбигага гашыйк итте.

[...] Рәбиганың гыйлеме бик яхшы иде. Остазбикәсе бер хаттат мелланың бер кызы булганга, язуы бик оста, үзеннән укыган кызларга бик яхшылап язу үгрәтү гадәте бар иде. Шуңа күрә Рәбиганың язуы бик матур иде.

Фатих тиз өйләнергә, Рәбиганы алырга уйлап йөрсә дә, Халид агайда улын өйләндерү уйлары бер дә юк иде. Фатих берничә вакытлар атасының өйләндерү уена керүен көтеп йөрсә дә, бернәрсә дә чыкмагач, Рәбиганың бүтән кешегә китүеннән бик курыкты, чөнки Рәбига тәмам өлгереп йиткән бер йимеш иде. [...] Фатихта тиздән өйләнәсе килгәнен, Рәбиганы алмак эстәдеген атасына белгертергә кыюлык юк иде. Рәбиганы башкага йибәрмәскә күп хәйләләр уйлый торгач, хәтеренә шул хәйлә килде: үзенең Рәбиганы чын күңелдән яратканын һич шөбһәсез аңлаячагын алдан белгертеп куярга уйлады...

Рәбига, бу хатны алгач, бик каушады, бу хатны бер мыскыл итәр өчен язылган дип уйлап, бик ачуы килеп, ертып ташлаячак булды. Хатны кырык кат укыды, һәр укыганында төрле төсләргә килде. Бер кызарып, хурланган төскә килде, бер көлемсерәп, йөзендә шатлык әсәре беленде... Берничә көн йөрде, күп уйлый торгач, хатның ихлас күңелдән булуы өскә чыкты...

Фатихның төс-кыяфәте, тәүфыйгы, хәтта бәгъзе сөйләгән сүзләренә кадәр, Рәбигага мәгълүм иде. Шуңа күрә Фатихның үзенә баруны өмид итмәгәнгә, һәркайчан Фатих кебек бер егеткә баруны Ходадан сорый иде.

Рәбига, хатны алгач, ахырында бер җавап язу тиеш булганын аңлап: «Хатыгызны кабул иттем», – дип бер язу җибәрде. Фатих, бу кабул иттем дигән язуны алганнан соң, янә бер озын хат илән үзенең эчендәге уйларын тагын да яхшылап аңлаткач, бик оялса да, каршы язмый калу ярамаганлыгын белеп, Рәбига шушы озын хатны язды: *«Гакыллы вә фәһемле егет, хатыгызны алдым. Әйе, дөрес, үсеп җиткәннән соң, егетләргә – кызлардан, кызларга егетләрдән күңеленә охшаган бер яр табып, шуның илә рәхәт мәгыйшәт итү лязымдыр. Боны беләмен. Парлыкта зур бер сәгадәт булганын да аңлыймын, мин дә Сезнең кебек һәрвакыт муафыйк бер яр насыйп булуны Ходадан теләмәктәмен. Сез, муафыйкны табып, эстәгәнегезне алуда ихтыярлысыз, әмма үзеңезгә мәгълүм, безнең хатын-кызда теләгәнеңне сайлау, эстәгәнеңә бару ихтыяры юктыр. Шуның өчен безгә алдан фараз итеп, муафыйкны эзләп кую файдасыздыр. Минем бу көнгә кадәр сайлаган, муафыйк табып, барырга уйлаган һичкемем юкдыр. Хатыгыз тугърыдан исә, Сез мине сайлагансыз. Бу илтифатыгызга бик мәмнүн булдым. Бик куанып, бердән, зәүҗәңез (хатыныгыз), икенчедән, хәдимәңез (хезмәтчегез) булырга разыймын. Чөнки Сезнең кеби егетләрнең хезмәтендә булу – үзе бер зур сәгадәтдер...»*

Менә, укучылар, Фатих илә Рәбига арасында дуслык, вәгъдәләр шушы хатлардан соң башланды, аерылмаслык мәхәббәт шул көннән соң урнашты. Араларында хатлар туктамады, бер-берен күрмәк тә авыр түгел иде. Эстәдекләре вакыт күрешерләр иде, ләкин күрешсәләр дә, мөгамәләләре бик гафифәнә *(саф)* иде. Фатих, гакыллы егет булганнан, элекке күрешүдә үк, Рәбигадан зәүҗә булырга разый булганын әйттереп, үзе дә зәвеж *(ир)* булганлыгын сөйләп, бу вәгъдәләрнең сергә катышканын ике егеткә ирештереп, шәргый бер гакыйдә дә ясаганнар иде. Фатих атасы Халид агай өйләндерергә башлауны көтеп йөри иде. Атасы өйләндерергә башлап, кыз эзләсә, максуды Рәбиганы аласы килгәнен белгертергә иде. Менә шушы ике яшь күңел тиздән никяхлы бер-беренеке булганны көтеп йөргәндә, Халид агай Рәбигага үзе өчен җаучы җибәрмәсенме?!

Ахыры киләсе санда

Әсәрне басмага филология фәннәре докторы, профессор, РФА Шәрыкны өйрәнү институтының өлкән фәнни хезмәткәре ***Әлфинә Сибгатуллина*** *әзерләде* ■

Шагыйрь Бәдрүш Мокамай

Күренекле якташыбыз, журналист, фронтовик-шагыйрь Бәдрүш Мокамай хакында белмәгән кеше аздыр. Аның хакында Татарстан һәм Башкортстан матбугатында басылган язмалар байтак. Беренче карашка, ерак 1944 елда фронтта һәлак булган шагыйрьнең тормышы һәм иҗат юлы турында барысы да язылган, нәрсә дә булса өстәү мөмкин түгел кебек.

Ләкин аның, һәрбер кешенеке сыман, гаиләсе – кадерлеләре, якыннары булган. Алар хакында мәкаләләрдә бер юл белән генә язып үтелә: «Бәдрүш Мокамай 1937 елның октябрендә укытучы Клавдия Архиповага өйләнә, 1938 елда беренче кызлары – Линария, тагын бер елдан Эмма дөньяга килә...»

Мин якташыбызның гаилә әгъзаларын эзли башладым. Линария Батырованың – Бөгелмәдә, Эмма Мөхәммәтҗанованың Уфада яшәве билгеле булды. Линария Батырованы интернет челтәре аша таптым һәм аңа хат җибәрдем. Әлбәттә, өлкән яшьтәге ханымның заман техникасы белән таныш булуына, глобаль «пәрәвездә» утыруына шигем зур иде. Ләкин юкка шикләнгәнмен, ике сәгатьтән җавап килде: «Әйе, мин – Бәдрүш Мокамай кызы. Урысча язуым өчен гафу итегез. Балачагым урыс авылында үтте, урыс мәктәбендә укыдым. Мин татарча сөйләшәм, укыйм, ләкин яза белмим. Мин Бөгелмә шәһәрендә яшим, миңа 77 яшь, еш авырыйм. 28 февраль 2016 ел».

Шул рәвешле без Линария Бәдретдин кызы белән хат алыша башладык. Хатларның берсендә ул балаларының Мәскәүдә яшәве, тиздән үзенең дә шунда күченеп китәчәге турында хәбәр итте. Берничә көннән без фотохәбәрче Наил Акмеев белән Бәдрүш Мокамайның кызы яшәгән Бөгелмәгә юл тоттык.

Линария Бәдретдин кызы безне якын туганнары кебек каршы алды. Батыровларның иркен фатирына аяк басу белән борынга тәмле аш исе килеп бәрелде. «Ерак юлдан килгәнсез, башта тамак ялгап алыйк, аннары иркенләп сөйләшербез», – дип, хуҗабикә безне мул сыйлы табынга чакырды. Фатирның һәр бүлмәсендә фотосурәтләр: Бәдрүш Мокамай, Линария апаның яшь чагы, Батыровлар гаиләсе, балалары, оныклары...

– Әлбәттә, фатир диварына фотосурәт элүне хупламыйлар, бу хакта миңа кешеләр дә әйтте. Ә мин элдем, чөнки аларга карап күңелемә юаныч табам, – диде ул, әтисенең фотосурәтләре беркетелгән зур альбомны кулына алып. Бу мәкалә Линария Батырова истәлекләренә нигезләнеп әзерләнде.

Фәнүз Хәбибуллин

Клавдия Алексеевна Линария (урындыкта) һәм Эмма белән

Ата һәм ана

Бәдрүш Мокамай (тулы исеме Бәдретдин Мөхәммәтҗан улы Мөхәммәтҗанов) 1909 елның 5 октябрендә Уфа губернасының Бөре өязе (хәзерге Дүртөйле районы) Каеш авылында туган.

Аның әтисе Мөхәммәтҗан бала вакытында вафат булган, – дип искә ала Линария Бәдретдин кызы. – Әнисе икенче кешегә кияүгә чыгарга карар иткән, өч баласын да ташлаган. Улларының берсе – Хәниф үлгән. Кадрине туганнары тәрбиягә алган,

Бәдрүш Мокамай хатыны **Клавдия белән**

ә әтиемне Мөхәммәтҗан картәтинең бертуган энесе Хәкимҗан тәрбияләп үстергән.

Бәдрүш Мокамай Каеш җидееллык мәктәбен, 1931 елда Уфа педагогия техникумын тәмамлый. Математика укытучысы һөнәре алып чыга. Чишмә районында – укытучы, Уфада – «Яшь коммунар», Дүртөйле районында «Ярыш» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли.

1934-1936 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә, Ерак Көнчыгышта хәрби бурычын үти. Авылдашларына шигырь белән язылган хат юллый. Ул елларда «Комбайн» колхозы рәисе булып эшләгән Әмир Шәймөхәммәтов болай дип искә ала: «Бәдретдин безнең терәгебез иде. Аны армиягә бөтен колхоз белән озаттык. Аннан хат алгач, бергәләшеп, җавапны да шигъри юллар белән яздык».

Бәдрүш Мокамай «Ярыш» газетасында җаваплы сәркәтип булып эшли. Бу вакытта ул гаиләсе белән Дүртөйленең Совет урамындагы 12 нче йортта яши.

– Әти белән әни Иске Баеш авылында танышканнар. Әни анда укытучы булып эшләгән, активистка булган, төрле җыелышларга һәм конференцияләргә йөргән. Әтием әнигә яучы җибәргән. Алар 1937 елда өйләнешкән. Башта Агыйдел буендагы Кызыл Гвардия урамындагы бер фатирда торганнар. Әнием авырга калган, ләкин авыры төшкән.

Әнинең укытучы булып эшләүче дустының Линария исемле кызы булган. Әтигә дә, әнигә дә бу исем ошаган. Мин 1938 елның 29 июлендә туганмын. Әти янымда очып кына йөргән, өрмәгән җиргә утыртмаган.

Әти белән әни бер-берсен ярты сүздән аңлаган, бер-берсен ихтирам иткән, яраткан. Әти гаиләнең матди хәлен кайгырткан. Әни бернәрсәгә дә мохтаҗлык кичермәгән, рәхәт яшәгән.

...Әтием ак күлмәк, буйлы чалбар кигән, йорт алдындагы баскычта аякларын бөкләп утырган. Уенчык кошның заводкасын бора һәм аны җибәрә. «Кызым, алып кил әле», – ди. Мин, йөгереп барып, кошны әтиемә алып килеп бирәм. Шулай берничә тапкыр кабатлана. Әтием хәтеремдә шулай калган. Бу – бердәнбер хатирәм.

Сеңлем Эмма 1939 елның 27 декабрендә дөньяга килде. Ул, икътисадчы булып эшләп, лаеклы ялга чыкты. Аның кызы Нонна бухгалтер булып хезмәт куя, Артур исемле малай үстерә. Алар Уфада яши.

Кызыл Гвардия урамында яшәгәндә мин бик каты чирләгәнмен. Моны күреп, әтием елап җибәргән. Ул вакытта әнинең сеңлесе Зинаида Алексеевна дәваханәдә эшләгән. Әти аның янына йөгереп килеп: «Зина, кызым үлә бит, тамагыннан берни үтми, тын алалмый. Нәрсә эшлик?» – дигән. «Ат җик тә дәваханәгә алып кил», – дип җаваплаган Зина түти. Муеным шешкән булган, дәваханәдә эренне агызганнар, шуннан мин елмаеп җибәргәнмен.

Бәдрүш Мокамайның авыл хуҗалыгын күмәкләштерүгә багышланган беренче шигырьләре 1929-1931 елларда татар телендә «Яңа авыл», «Яшь юксыл», «Әдәби удар», Чишмә районының «Сталинчы» газеталарында басыла. Шигырьләрен Һади Такташ әсәреннән алынган «Мокамай» тәхәллүсе белән бастыра.

«Язсаң-язсаң, Тукай, Такташ кебек язарга кирәк! Мин Һади Такташның әсәрләрен бик яратам. Аеруча «Мокамай» шигырен. Такташ шигырьләрен яратканга күрә, үземә «Бәдрүш Мокамай» дигән кушамат алдым. Мин Һади Такташны күреп беләм. Минем басылган шигырьләрем хакында Такташ матбугатта язып чыкты.

...Балачагымнан ук җырлар чыгарырга оста идем. Ә хәзер шигырьләр язам, Уфада гәзит-журналларда актив катнашам. Узган елда гына Кызыл Армия сафыннан кайттым. Кызыл Армия хакында да шигырьләрем бар. Үзем хәзер Дүртөйле районында эшлим. Редакция каршында әдәби түгәрәк бар. Яшь шагыйрьләрдән Зыя Мансуров шигырьләре миңа ошый. 1934 елда без, әдәбият түгәрәге әгъзалары «Атака» дигән әдәби җыентык бастырып чыгардык. Бу җыентык хакында Муса Җәлил рецензия язды. Мин Муса Җәлилне дә күреп беләм», – дип сөйләгән Бәдрүш Мокамай, Казанда Самат Шакир белән очрашкач.

Бөек Ватан сугышы башланган көнне, якшәмбе булуга карамастан, газетаның барлык хезмәткәрләре эшкә чыга. Алар «Ярыш»ның яңа санын басмага әзерли. Нәфисә Мансурова ТАССның радиограммаларын кабул итә, Бәдрүш Мокамай, Ватанны сакларга чакырып, халыкка ачык хат белән мөрәҗәгать итә.

Бәдрүш Мокамай сугышның тәүге көннәрендә үк үз теләге белән фронтка китә, кыска сроклы курсларда укый.

– Сугыш башлангач, әти: «Мин мотлак фронтка китәчәкмен, тылда калмаячакмын. Бармый калсам, кешеләрнең күзенә ничек карармын?» – ди. Ул туберкулез белән авырган була, ләкин фронтка барудан азат итә торган «бронь» аңа эләкми. Берничә тапкыр хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итә, берничә ай дәвамында аны сугышка алмыйлар. Курамшина дигән табиб, Уфага барып, әтине хәрби хезмәттән азат итү турында документ ала. Ләкин ул Дүртөйлегә кайтып җиткәнче әтием фронтка киткән була инде.

Бәдрүш Мокамай башта – Көнбатыш, аннары Калинин фронты составында Вязьма, Можайск, Великие Луки шәһәрләрен азат итүдә катнаша.

Фронтта, лирик шигырьләр белән беррәттән, Зоя Космодемьянскаяга багышланган «Таня» поэмасын, «Линарияга хатлар» дигән проза әсәрен, «Кан өчен кан» пьесасын яза. 1943 елда фронт вакыйгаларын сурәтли, туган илне сөюгә дан җырлый, дошманга нәфрәт уята торган «Урал егете» дигән шигырьләр һәм поэмалар китабы басылып чыга.

– Әтием старшина булып хезмәт итә. Әниемә акча җибәреп, ярдәм итеп тора, бу хакта аның фронт хатларында да еш искә алына. Бәлки алар – басылган шигырьләр өчен гонорар булгандыр.

Бу хакта шагыйрьнең хатынына язган хатларында да сүз бара:

«Кадерле Клава!

Сиңа һәм балаларга гаять күп сәлам. Үзем исән һәм сезгә дә шуны телим. Бу арада синнән хатлар юк. Ә сиңа бу көннәрдә бик күп хатлар яздым. Син мин җибәргән пьесаны һәм «Линарияга хатлар»ны алдыңмы? Мин җибәргән акчаны һәм китап акчасын алдыңмы? Тормышың ничек? Син миңа хатларны еш яз. Синнән хатлар килсә, миңа бик тә күңелле була. Соня апалар ни хәлдә яши?

Сине һәм балаларны гаять сагынам. Ләкин җиңүдән соң кайтып сезне күрәчәгемне уйлап шатланам. Башка язар сүз юк.

Сезне сөюче Бәдрүш Мокамай.
26.4.43.
255 нче кыр почтасы, 713 нче часть».

Линария Батырованың шәхси архивында фотосурәтләр, әтисенең бик күп хатлары, аның турында матбугатта басылган язмалар саклана. Алар арасында Клавдия Алексеевнаның Бәдрүш Мокамайга язган һәм, ни сәбәпледер, кире кайткан бер хаты да бар:

«Кадерле Бәдрүш!

Барыбыздан да кайнар сагыну сәламе. Үзебез исән, сиңа да шуны теләп калабыз. Мин әле военкоматта эшләп утырам. Берничә көннән колхозда эшләргә тиешмен.

Синнән бу арада хатлар булмагач, бик эч поша. Сине уйламаган бер минутым да юк. Кайда гына булсам да гел синең белән. Бүген төштә дә синең белән карточкага төштем. Кешеләргә товар бирәләр. Мин аңа да кызыкмыйм. Тик син исән кайтсаң иде.

12/VI Ибраһимовның «Партизанка» дигән пьесасын карадым. Кыска-кыска гына өч пәрдәдән тора. Азактан 22 яшьлек партизанканы асалар. Шуннан партизаннар килеп чыгып, немецларны кулга алалар. Синең дә пьесаң ярарлык дип беләм. Только Кудашев кына бер җавап та язмый. Син үзең язып сора әле.

Әминевларга барганым юк. Бер буш минутым да юк. Балалар көн дә иртән детсадка китеп, сәгать 5тә кайталар.

Үзең ничек яшисең? Сәламәтлегең ничек?

Сәлам белән, сине сөюче Клава Мокамай.
15/VI – 43».

Якташыбыз Бәдрүш Мокамай фронтта ике тапкыр яралана. Халык шагыйре Сәйфи Кудашка язган хатыннан:

«Сәйфи абый!

Сәлам. 21 февральдә, 1944тә кич белән яраландым. Шунда Язучылар союзына әгъзалыкка кандидат карточкасын югалттым. Минем «Хикәяләр» ни хәлдә?..

Хушыгыз. Сәлам белән: Бәдрүш Мокамай.
29/II – 1944».

Дәвалангач, Бәдрүш Мокамай саперлар взводы командиры булып хезмәт итә.

«Көт син мине, гүзәл Агыйделкәй,

Данлы җиңү белән кайтырмын», – дип язса да, Бәдрүш Мокамайга туган ягына, хатыны һәм кызлары янына кайту насыйп булмый. Шагыйрь 1944 елның 20 сентябрендә Латвия җирендә дошман пулясыннан һәлак була.

– «Кара кәгазь»не почтальон әнинең сеңлесе Зина апага тапшырган. Ул бу хакта шул ук көнне әнигә әйтмәгән, бер атнадан соң гына хәбәр иткән. Кайгылы хәбәрне әнием бик авыр кичерде. Берничә көн эшкә дә бармады. Әтиемнең фотосурәтләрен янына тезеп салып, һушсыз булып караватта ятты, «Минем өчен тормыш бетте, шундый кешене югалттым!» – дип бик каты елады. Берничә көннән эшкә йөри башлады.

Клавдия Алексеевна

– Әни, сеңлесе Зинаида Алексеевна белән бергә, фронттан кайтучылар утырган һәр пароходны каршы алырга бара иде. Шундый пароходларның берсеннән Ибраһим Сәет улы Баһманов төшә һәм болар янына килеп сүз куша. Бераздан ул әни белән очраша башлый. Нәтиҗәдә, моңа кадәр өйләнеп карамаган егет ике балалы әнием белән гаилә кора.

Әнием Клавдия Алексеевна үзенчәлекле, талантлы шәхес иде. Веялочный завод[1] мәктәбендә укучылар белән концертлар куя иде. Үги әти янына складка баргач, ул анда гармун күргән. Гармун беркемгә дә кирәкми икән. Әни аны өйгә алып кайткан, тиз арада уйнарга өйрәнгән.

Концертларда ул гармунда уйнап, укучыларны җырлата, биетә иде. Начар ишетүенә карамастан, татар (шул исәптән, керәшен), урыс җырларын бик матур җырлый иде. Аның җырлаганын яздырып калмавыма үкенәм. Уфада аңа операция ясадылар, аннары ул яхшы ишетә башлады.

Әнине авылда бик нык ихтирам иттеләр. Берәрсенең гаиләсендә тавыш-гауга чыкса: «Клавдия Алексеевна, ярдәм итегез», – дип, безгә киләләр иде. Пекарняда он бетсә дә аның янына чабалар, әнием, барып сөйләшеп, он кайтарта иде.

...Үземне белә-белгәннән бирле әтием Бәдрүш Мокамай кайтыр, дип көттем. Без Веялочный заводтан Әңгәсәккә йөреп укыдык. Юл урман һәм басу аша үтә. Еш кына алты километр араны берүзем кичәм. Шунда каршыма килүче берәр ир-егет күрсәм, әтием кайта, дип уйлый идем. Ләкин ул кайтмады... Бу хыяллануым аркасында төрле хәлләргә дә тарыдым. Беркөнне дус кызларыма «әтием кайтты», дип әйттем. Клавдия Алексеевнаның беренче ире кайткан, дигән хәбәр авылга яшен тизлегендә таралды. Бу хәбәрдән авыл гөж килеп торды. Әлбәттә, үги әтигә боларны ишетү бер дә җиңел булмагандыр. Ә әнигә?.. Ләкин ул мине моның өчен тиргәмәде.

Үсә төшкәч тә һәр автобуста, поездда әтиемне эзли идем. Шулай бик озак дәвам итте. Бервакыт мин төш күрдем. Имеш, ул Бөгелмә хәрби комиссариатында эшли икән, мин аны күрергә килгәнмен. Күрештек, кочаклаштык. Мин аны: «Нигә минем янга бик озак кайтмый тордың?» – дип тирги башладым. Шулвакыт ул: «Кызым, бар, өйгә кайт, монда башка килмә!» – дип, ишектән чыгарып, озатып калды. Мин төшенкелеккә бирелеп кайтып киттем.

Иртән бу төшне искә төшергәч, бер-бер куркыныч хәл булмагае, дигән уй килде. Биш көннән Уфадан сеңлем Эмма әнинең вафат булуы турында хәбәр итте. Әни аларга кунакка киткән иде. Эмма, аның кызы һәм әнием Яңа елга безгә кунакка кайтырга тиеш иде...

Әнием Клавдия Алексеевна 1972 елның 26 декабрендә, үзенең кече улы Эрикның туган көнендә, баш миенә кан савудан вафат булды. Әнием белән бәхилләшергә бөтен авыл җыелды. Әнинең вафатын бик авыр кичердем, хәтта невропатологка мөрәҗәгать итәргә туры килде. Ун ел үткәннән соң гына күңелем аның юклыгына күнә алды...

Әни белән үги әтинең ике уллары бар иде. Өлкәннәре Юра 1948 елда туды. Машина йөртүче булып эшләде. Соңгы елларда Бөгелмә шәһәрендә, бездән ерак түгел генә яшәде. Ун ел элек туберкулездан вафат булды.

Эрик 1952 елгы иде. Ул Уфада нефть институтын тәмамлады, аннары Краснодар шәһәрендә яшәде, эшмәкәрлеккә алынды. Эрик яман шеш авыруыннан узган ел кинәт кенә вафат булды.

Ахыры киләсе санда ■

[1] Башкортстанның Дүртөйле районындагы авыл. Бүгенге көндә Җилгәргечләр исемен йөртә.

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

ТЫҢЛАГЫЗ, КАЗАН СӨЙЛИ!

Фоат Галимуллин



Ф.Галимуллинның Татарстан радиосында диктор булып эшләгән вакыты. Узган гасырның алтмышынчы еллары

Бәхетемәдер инде, миңа Татарстан радиосының иң абруйлы чорларының берсендә шунда диктор булып эшләргә насыйп әйләде. Сүз дә юк, аның халыкка аеруча көчле тәэсир итеп эшләгән чагы сугыш чоры һәм аннан соңгы илленче еллар булган. Әмма мин бирегә эшкә килгән алтмышынчы елларда да радио әле нигездә киң күләмдәге мәгълүматны һәм сәнгатьтәге казанышларны күзгә күренмәгән дулкыннары белән меңнәрчә чакрымнарга илтеп ирештерүче бердәнбер чара иде. Татар телендә эшләүче башка радиолар юк, телевидение, үзенең эшчәнлеген башласа да, әле ул Мәскәү программасы мөмкинлек биргән вакыт аралыгына кысылып кына дөньяга чыга. Күп кенә җирләргә аның яктылыгы төшми, Казан, Әлмәт, Лениногорск кебек шәһәрләр тирәләрендә генә аларны экранда «кар яуган» хәлдә булса да карый алалар. Шуңа күрә халык, кинәнеп, радио тыңлый. Х.Туфан бер эпиграммасында: «Казанский радионың радиусы бәләкәй», – дип язса да, хәзергесе белән чагыштырганда, шактый зур булган икән бит. Без иртәнге тапшыруларны: «Казан сөйли! 1181 метр дулкынлы радиостанция эшли. Мәскәү вакыты белән 7 сәгать 10 минут», – дип башлап җибәрәбез. Бу – озын дулкынлы радиостанциянең авазы, ул, Татарстаннан тыш, тулысынча Башкортстанны, Ульяновск, Киров һәм Пенза өлкәләрен, Мари, Чуаш, Удмурт һәм Мордва Респубикаларын иңли. Хәтта Оренбург, Свердловск һәм Чиләбе өлкәләренең безгә табарак булган төбәкләреннән дә, сезне тыңлыйбыз, теге яки бу җырны, спектакльне тапшырсагыз иде, дип хатлар килә.

Тагын шунысы да бар: Ульяновскида һәм Кировта, күрәсең, мөстәкыйль тапшыру станцияләре булмаган, алар үз тапшыруларын да элемтә каналлары буенча Казанга җибәрәләр дә, шул ук 1181 метрлы көчәйткеч ярдәмендә аны эфирга чыгаралар. Димәк,

Татарстан башкаласының Троицк урманындагы станциясенең көче бу өлкәләрне тулысынча иңләргә җиткән. Дөрес, Казанга кадәр элемтә чыбыклары буенча килгәнлектән, бу шәһәрләрдән эфирга чыгучы тапшыруларның яңгырашында ниндидер «юшкын»нар сизелә, безнекеләрнең сыйфаты күпкә яхшырак була. Еллар үткәч, әлеге өлкә үзәкләре дә үз радиостанцияләрен булдырдылар, шуның белән аларның безгә «ялынычлары» бетте.

Без – дикторлар әнә шундый гаять киң таралган җирлекләрдә үз кеше идек. Татарстанны инде әйткән дә юк, аеруча яратып, үз итеп тыңлаучыларыбыз Башкортстанда да күп булды. Андагы күп кенә районнардан хатлар агылып кына торды. Бигрәк тә Камал Саттарованы яраталар, аңа еш кына: «Казан абыстаебыз», – дип язалар. Чыннан да, сугыш вакытыннан бирле тыңлаучыларның яратып тыңлый торган бу дикторы телебездәге гарәп-фарсы алынмаларын яки махсус тапшырулардагы дини тәгъбирләрне шулкадәр җиренә җиткереп, оста итеп әйтә ки, аны яхшы әзерлекле дин әһеле дип тә кабул итәргә мөмкин иде. Мәрьям апа Арсланова белән шәхсән үземә дә тыңлаучылар битараф булдылар, дип зарлана алмыйм. Ул хатлар арасындагы аеруча җылы итеп язылганнарын әле дә кадерләп саклыйм.

Әйтик, 1972 елда булса кирәк, миңа Уфадан бер хат килде. Кире адресы да юк, авторның имзасы да куелмаган. Аның каравы, конверт эчендә шигырь бар. Ул «Тыңлагыз, Казан сөйли!» дип атала. Хат кулдан, тигез, матур хәрефләр белән җыйнак итеп язылган. Аны язган кешенең пөхтәлек яратучы икәнлеге әллә каян күренеп тора. Менә ул:

Җилләр инде яфракларның
Соңгыларын җиргә сибә;
Кар аралаш яңгыр ява,
Бик ямансу әллә нигә...

Шул сагышлы көзге көнне
Таныш тавыш котлый безне,
Ул хәерле иртә тели:
– Тыңлагыз, Казан сөйли!

Килеп керде дусларымны
Иң сагынган чакта гына.
Алып китте Казанына,
Чаллы, Кама якларына...

Иркәләде колагымны
Әткәм-әнкәм теле белән,
Салих Сәйдәшев моңнарын
Алып килде үзе белән.

Шушы моңнар озатып бара
Елларымның агышында.
Алар, җылы агым булып,
Кергән минем язмышыма.

Бүген дә боек күңелемне
Ул туган моңнарга күмде.
Ак бәхетләр тели-тели:
– Тыңлагыз, Казан сөйли!

Шигырь миңа бик ошады, коллегаларым Камал һәм Мәрьям апаларга да укып күрсәттем. Аны укыганда, режиссерыбыз Госман абый Әхмәтҗанов белән рус телендә сөйләүче хезмәттәшебез Таисия Калугина да бар иде. Барыбыз бергәләп Таисия Андреевнага аның эчтәлеген тәрҗемә иттек. Ул болай дип әйтеп куйды:

– Татар тыңлаучылары бик игътибарлы кебек тоела миңа. Үземнең рус телле тыңлаучыларымнан, сирәк булса да, мин дә хатлар алгалыйм. Әмма аларда күбрәк нинди дә булса кимчелек күрсәтелә, йә, бер дә булмаса, тегеләй-болай укырга кирәк, дип, мине өйрәтеп язалар. Атап мондый шигырь язулар юк та юк инде.

Камал апа, һәрвакыттагыча шаяртып, сүзгә кушыла:

– Хатны Фоатка җибәргәннәр бит, бу берәр кыздан булырга тиеш. Шигырьне Фәйрүзәңә күрсәтә күрмә, көнләшер, – ди.

Мәрьям апа җитдирәк, ул язуын җентекләп карый:

– Юк, бу яшь кызлар кулы белән язылмаган. Күрәсез, һәр хәрефе бөртекләп, җиренә

җиткереп төшерелгән. Яшьләрнең болай итеп утырырга түземлекләре җитми.

Кулдан-кулга йөрткәннән соң, хатны миңа бирәләр. Госман абый әйтә:

– Сакла, безгә, Таисия Андреевна әйтмешли, күбрәк акыл өйрәтеп язалар. Мондый матур шигырьләр эшебезгә бирелгән ихлас бәя ул!

Бер-ике көннән зур студиядә радионың элеккеге дикторлары Зәйнәп Хәйруллина, Маһинур Җиһаншина һәм Айрат Арсланов белән очрашу уздырылды. Алар үткәннәрне искә төшерделәр, олырак яшьләрдәге хезмәткәрләр бу могтәбәрләр эшләгән заманнар турында истәлекләр сөйләделәр. Бигрәк тә утызынчы еллар шагыйрәләре Зәйнәп апа Садыйкова, Мөршидә апа Вилданова чыгышлары кызыклы булды. Мине дә хәзерге дикторлар исеменнән сүз әйтергә чыгардылар. Мин исә шушы билгесез авторның шигырен яттан сөйләдем. Әсәр һәммәсенә дә ошады. Татарстан радиосының төрле җирләргә таралып яшәүче милләттәшләребезне рухи яктан бергә туплавындагы әһәмияте никадәр осталык белән әйтелгән, дип сокландылар. Зәйнәп апа исә өстәп әйтеп куйды:

– Автор әйтергә теләгән уй-хисләрне күңелләргә үткәреп укыганың өчен, Фоат энебез, сиңа рәхмәт!

Шул рәвешле, бу шигырь, татар шигъриятенең күп кенә башка әсәрләре кебек, минем күңелемдә яши башлады. Мин, аны, җае чыккан саен, төрле чараларда укый торган булдым.

...Җитмешенче еллар ахырында аспирантураны Уфада Башкорт дәүләт университетында үттем. 1980 елда классик шагыйрь һәм әдип Мәҗит Гафуриның тууына 100 ел тулды. Шул уңай белән Башкорт телевидениесе татар телендә дә бер тапшыру оештырырга ниятли. Аның авторы, ярдәм сорап, БДУга килде. Татар филологиясе кафедрасы мөдире Габделхәй Хурам улы Әхәтов белән аның кабинетында сөйләшеп утыра идек, шушы журналист килеп керде. Бу егетнең йомышы кафедра мөдиренең әлеге тапшыруда чыгыш ясавын сорау икән.

– Без бу бәйрәм уңае белән башкорт телендә тапшырулар әзерләдек. Менә татар телендә дә булсын, дибез. Телевидениегә килеп, Мәҗит агабыз турында сөйләп китсәгез иде.

Габделхәй агай кинәт миңа таба борылды:

– Мин инде сездә булгалап торам. Менә Мәҗит Гафури хакында бездәге халык өчен яңа кеше сөйләсен. Үзе – Казаннан. Мәҗит аганы анда ничек бәяләүләрен ишетү тагы да кызыклырак булыр.

Егет миңа борылды:

– Безгә бүген үк кирәк.

– Габделхәй Хурамович әйтә икән, хәзер үк сөйли алам!

Шулай итеп, әлеге егеткә ияреп, Салават һәйкәленнән ерак түгел генә урнашкан Башкортстан телевидениесе бинасына киттем.

Анда бер абзый сорый:

– Ничә минут сөйлисез?

– Сезгә ничә минут кирәк булса, шулкадәр.

– Унбиш минут күп булырмы?

– Мин Мәҗит Гафуриның байтак әсәрләрен яттан беләм. Ярты сәгать бирсәгез, әйбәт булыр иде.

– Вакытын бирербез, әмма безнең таләпләргә туры килмәгән очракта, кыскарту ихтималыбыз да бар.

Мин инде, Уфада зыялылар арасында бераз кайнашып, биредәге аерым язучыларга мөнәсәбәттәге кайбер нечкәлекләрне белә башлаган идем. Шуңа күрә, чыгышымны, алар күзеннән караганда да, нинди дә булса ризасызлыкка урын калдырмаслык итеп

ясадым. М.Гафуриның татар әдәбиятындагы зур урынын күрсәттем, аның башкорт сүз сәнгатен үстерүгә юнәлдерелгән хезмәтләрен киңәйтеп бәян итәргә тырыштым. Мине бүлдерүче булмады. Студиядәгеләр рәхмәт әйтеп калдылар. Кичен бу язманы эфирга чыгардылар. Чыгышымны тулысынча калдырганнар булып чыкты.

Фәния Чанышева

Иртәгесен каланың В.Ленин урамындагы китап кибетенә кердем. Ике катлы кибеттәге китап байлыгына исем китеп карап йөрдем. Сәйфи ага Кудашның ике томлыгын сатып алып, бинадан чыгып барганда, каршыма мөлаем гына бер ханым очрады. Ул, минем белән исәнләшеп, күптәнге танышы шикелле, иркен генә сөйләп китте:

– Кичә телевидениедән, Фоат энем, Сезнең чыгышны карадык. Чын татар сөйләмен, телебезнең казан татарларына хас үзенчәлекле яңгырашын тыңладык. Диктор булган кешенең сөйләме аеруча аһәңле булып кабул ителә икән: дөрес тә, гади дә, шул ук вакытта халыкчан да. Рәхмәт Сезгә.

Миңа, әлбәттә, мондый бәяне ишетү күңелле иде. Әмма бу ягымлы ханымны танымый гаҗизләндем. Сораулы карашымны сизде булса кирәк, ханым үзе белән таныштырырга ашыкты:

– Мин Фәния апаң Чанышева булам...

– Алай булгач, Сезне шагыйрә дип беләбез. Әле күптән түгел генә Казанда шигырь китабыгызны укып утырырга туры килде. Аларны үзебезнең телевидениедә «Яңа китаплар» тапшыруында яңгыраттым.

– Рәхмәт инде, китабымны игътибарсыз калдырмыйсыз икән. Кызганыч, Казан телевидениесе тапшыруларын монда карый алмыйбыз. Ә радиодан сөйләвегезне ишетеп торабыз. Бер елны мин сезгә «Тыңлагыз, Казан сөйли!» дигән шигыремне дә җибәргән идем әле.

Мин шунда ук әлеге шигырьне сөйли башладым. Фәния ханым елмая-елмая тыңлап торды. Аңа үз әсәренең Казаннан килгән бер мосафир тарафыннан яңгыратылуы көтелмәгән хәл иде.

– Шушы шигырьме? – дидем мин, укып бетергәч.

– Шушы инде, шушы. Димәк, ул адресатына барып җиткән, алай гына да түгел әле, әсәр үзенең мөстәкыйль тормышы белән яши башлаган! Моны күреп тору миңа бик күңелле!

Фәния Чанышева – Уфада яшәп, татар телендә иҗат итүче шагыйрә. Ул – күренекле галим һәм шагыйрь, Мәҗит Гафуриның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнеп, докторлык диссертациясе язып яклаган Гыйлемдар Рамазановның хәләл җефете дә. Еллар узгач, без аның белән, М.Кәримнең 80 яшьлек бәйрәме уздырылганда, шагыйрьнең туган авылы Келәштә, башка әдәби форумнарда да очраштык. Ике арада хатлар йөргән вакытлар да булды. Үз төбәгендә татар рухын саклап яшәгән Фәния ханым Чанышевага рәхмәтем бик зур.

Редакциядән: Күренекле әдибә Фәния Гаффар кызы Чанышева (1926-2018) быел 14 апрельдә дөньядан китте. Фоат ага Галимуллинның ошбу язмасы аны яд итү булсын. ■

Истә, һаман да истә!

Артист Идрис Мәсгутовның тууына 70 ел

Татарстан Республикасының атказанган артисты (1985) **Идрис Мөдәррис** улы **Мәсгутов** 1948 елның 12 ноябрендә Татарстанның Чистай районында туа. 1974 елда Казан театр училищесын тәмамлый. 1974-1986 елларда Әлмәт театрында эшли. 1986 елдан вафатына чаклы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында хезмәт куя. 2008 елның 22 ноябрендә вафат була.

Сәхнәдә уйнаган кайбер рольләре: Ислам (Ш.Хөсәенов «Әни килде»), Каюм (Т.Миңнуллин «Ат карагы»), Пантолоне (К.Гольдони «Ике хуҗаның хезмәтчесе), Габдулла (Ф.Бүләков «Әбиләргә ни җитми?»), Тархан (Н.Исәнбәт «Хуҗа Насретдин) һ. б.

Артист һәм режиссер Газиз Айдарскийның тууына 120 ел



Күренекле артист һәм татарлардан беренче профессиональ режиссер **Газиз Исхак** улы **Айдарский** (Вәлитов) Казан губернасының Чуел өязендәге (хезерге Яшел Үзән районында) Айдар авылында 1898 елның 23 ноябрендә туа.

1909-1917 – Әстерхан губернасы Красный Яр өяз шәһәрендәге (1925 елдан – авыл) китап кибетендә – йомышчы малай, соңрак приказчик. 1917-1918 – Әстерхан губернасының мөселман эшләре буенча комиссариатында татар яшьләре арасында мәдәни-агарту эшләре белән шөгыльләнә. «Сәйяр» труппасы белән гастрольләргә килгән Зәйни Солтанов, Касыйм Шамил чакыруы буенча Казанга кайта. Камал I белән бергә Буа театрында бер сезон эшли. 1918-1920 – ТАССР мәгариф халык комиссариатында эшчеләр комитеты сәркатибе, 1918 елда оешкан театр студиясендә режиссер. 1920-1922 – ТАССР мәгариф халык комиссариатында сәнгать бүлеге мөдире. Беренче татар үрнәк театрында эшли. Ачлыктан интегүчеләргә ярдәм итү комитеты эшендә, Татар театрының беренче бинасы (хәзерге рус ТЮЗы) төзелешендә катнаша. 1922 елда Мәскәүдә Үзәк театр сәнгате техникумына (соңрак ГИТИС) режиссерлык факультетына укырга керә, «Коммунальщик» клубы каршында эшләп килгән татар драма труппасыннан «Эшче» театрын оештыра. «Красный Богатырь» заводында татар эшчеләренең сәнгать түгәрәге җитәкчесе була. 1923-1924 – Беренче татар үрнәк театрында (хәзерге Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры) эшли. 1924-1933 – Мәскәүдә Мәскәү үзәк татар эшче театрының сәнгать җитәкчесе һәм баш режиссеры. 1925-1926 – Казанда беренче татар операсы «Сания»нең куючы режиссеры. 1930-1931 – Казан театр укуханәсендә укыта. Мәскәү шәһәрендә нәшер ителгән «Коммунист» газетасы һәм Казанда басылган газета-журнал битләрендә үсеп килүче милли сәхнә хакында дулкынланып язган мәкаләләре бер-бер артлы дөнья күрә.

Без аны күренекле композитор һәм җырчы Сара Садыйкованың ире буларак та беләбез. 1933 елда 34 яшендә туберкулез чиреннән вафат була. Кабере юк, чөнки җәсәде кремацияләнә, көл салынган савыт башта гаиләсендә саклана, аннары Милли музейга тапшырылгач, юкка чыга.

Куйган спектакльләре (Мәскәү үзәк татар эшче театрында): «Галиябану» – Мирхәйдәр Фәйзи; «Зәңгәр шәл» – Кәрим Тинчурин; «Казан сөлгесе» – Кәрим Тинчурин; «Наёмщик» – Таҗи Гыйззәт; «Аршин мал алан» – Гозәер Хаҗибәков; «Оештыручы» – Салих Баттал.

Бу мәшһүр артист һәм режиссер турында танылган драматург һәм артист Юныс Сафиуллин зур хезмәт язып, аны китап итеп бастырып чыгарды.

Шагыйрь Шамил Анакның тууына 90 ел



Шагыйрь **Шамил Анак** (Шамил Гомәр улы Мәхмүдов) 1928 елның 25 ноябрендә Башкортстанның Әлшәй районы Габдерәшит авылында туа.

Дәүләкән педагогия училищесында укыганнан соң, М.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетын һәм аспирантураны тәмамлый. М.Горький исемендәге Әдәбият институтында (1957-1959), Прага университетында (1959-1960) укыта.

Шамил Анак – киң мәгълүматлы әдәбият белгече, оста тәрҗемәсе. Ул төрек шагыйре Назыйм Хикмәтнең ике шигырь китабын, шулай ук төрек хикәяләрен тәрҗемә итә. 1969 елдан СССР (Татарстан) язучылар берлеге әгъзасы. 2005 елда вафат.

Аеруча танылган басма китабы – «Тыйнак табын» (1982).

Галим Фәрит Бәшировның тууына 60 ел

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы **Фәрит Кәрим** улы **Бәшир** (Бәширов) 1958 елның 30 ноябрендә Татарстан Республикасының Арча районы Шекә авылында укытучы гаиләсендә туа.

1974 елда сигезьеллык мәктәпне, 1976 елда Шушмабаш урта мәктәбен тәмамлый. 1976-1981 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. 1981-1984 елларда СССР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурада укый. 1984-2003 елларда шул институтта кече фәнни хезмәткәр вазыйфасын башкара. 1989 елда «Яңа татар романы формалашу (XIX гасыр ахыры-XX йөз башы)» дигән темага кандидатлык, 2002 елда «XX йөз башы татар прозасының үсеш этаплары» дигән темага докторлык диссертацияләрен яклый.

Фәрит Бәшир 2003-2006 елларда Татарстан китап нәшриятында бүлек мөдире, аннан «Матбугат йорты» нәшриятында редактор булып эшли. 2007 елдан – Татарстан Республикасының мәгарифне үстерү институты профессоры. Ф.Бәшир әдәби-мәдәни мирас белән җентекле кызыксынып, элегрәк дөнья күрә алмаган әсәрләрне киредән халыкка кайтару буенча шөгыльләнү белән бергә, хәзерге әдәби хәрәкәтне өйрәнү, татар язучыларының иҗат портретларын укучыга җиткерү, яңа басылган әсәрләргә бәяләмә язу юнәлешендә дә актив эшли. Ул 2009 елның октябрендә Казанда вафат була, туган авылы – Арча районының Шекә авылы зиратында җирләнә. Ф.Бәшир – 2006 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЧЛЫК *тар.* – Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) һәм аның сәхабәләре Мәккәдән Мәдинә шәһәренә күчеп китәргә мәҗбүр булганнан соң, пәйгамбәр Мәккә халкын ачлык көтүе турында кисәтә. Ачлык еллар борынгы Мисырга да мәгълүм булган. «Йосыф» сүрәсендә Мисырда *кызликъ* (ачлык, кытлык) еллар турында да сөйләнә.

Иҗтимагый афәт буларак, ачлыкны ике төргә бүлеп карыйлар: беренчесе – *абсолют ачлык*, ә икенчесе – *чагыштырма ачлык*. Соңгысы вакытында туклану рационында тереклек өчен кирәкле мөһим компонентлар җитми. «Политик-экономик терминнар» сүзлегендә (1941) *«голодная заработная плата»* – ачыгырлык дәрәҗәдәге эш хакы, *«голодный минимум»* – ачлык минимумы кебек сүзләр теркәлгән.

Халык телендә ачлыкны «бүре сырхавы» дип тә атаганнар. Ачлык мәгънәсендә

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

йот сүзе дә бар (*«далага дәһшәтле йот килде»*). Әдәбиятта, русчадан күчереп, «ачлык патша» дигән гыйбарә йөргән. Ачлык елны алабута елы дигәннәр.

Тарихи чыганакларда ачлык турында хәбәрләр шактый еш очрый. 1024 елда Суздальдә ачлык булган һәм руслар Болгардан бик күп ашлык алып торганнар. 1228-29 елларда Бөтен Русьта, бигрәк тә Новгород һәм Белозерскта ике елга сузылган көчле кытлык була, шул вакытта болгарлар Идел һәм Ука сулары буенча русларга кәрван-кәрван ашлык озаталар, ә болгар ханы Новгород кенәзенә утыз көймә икмәкне бүләк итеп җибәрә (Габдрахман Таһирҗанов буенча). Рәуф Сабиров (1894-1937, репрессия корбаны) Русиядәге 1231 елгы ачлык турында: «Шушы ачлык елларның соңгысында халык гаять тә күп үлгән һәм Германиядән икмәк китерү аркасында гына халык бөтенләй үлеп бетүдән котылып калган», – дип яза.

1872 елда Самарада гадәттән тыш каты ачлык булуы мәгълүм. 1877 елда Россиядә иген уңмый һәм илдә ачлык башлана. 1883 һәм 1891 елларда шушы ук хәл кабатлана (1891 елның 14 ноябрендә Казанда мөселман балалары бушлай туклана торган ашханә ачыла). 1901 елда да игеннәр уңмый. 1906-1907 елларда Россиянең Европа өлешендә, шул җөмләдән Казан губернасында да,

ачлык хөкем сөргән. *«Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый»*, – дип, Тукай юкка гына язмаган. 1911 ел да – Россия өчен чагыштырма ачлык елы. Ул Россиянең 195 миллион халкы булган 20 губернасын чолгап ала.

Дөнья күләмендә җир-суларга иң бай дәүләт булган Русиянең шушылай бик еш ачлыктан интегүенең ил-халык психологиясендәге эчкәрегә, ихтимал, генетик сәбәпләре дә бардыр. 1920 ел ук инде Татарстан өчен чагыштырма ачлык елы булган, дип әйтергә мөмкин. Идел буенда 3 миллион кеше гомерен алып киткән 1921-23 елгы ачлык, 1933-1934 елда Саратов өлкәсе һәм Краснодар крае халкын 10%ка киметкән ачлык, шулай ук 30 нчы еллар башында Украинадагы ачлык, 1947 елгы ачлык большевикларның эчке икътисади сәясәтенә турыдан-туры бәйләнгән.

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соңгы 1947 ел да СССР күләмендә ачлык ел булып исәпләнә. Бу хакта азык-төлек җитештерү, халык саны, шулай ук үлем-җитем турында статистик мәгълүматлар аз. Ачлыкның ни дәрәҗәдә авыр булганлыгын, мәсәлән, ил күләмендә ипи пешерүнең 1940 ел белән чагыштырганда өч тапкыр кимүе бик ачык күрсәтә.

Татар телендәге йот сүзе табигый бәла-казалар (мәс., далада язын җепшеткәннән соң даланың боз катламы белән каплануы) аркасында хайваннарның ачлыктан кырылуын белдерә (йотлыгу – бик нык ачыгу). Рус теленә джут рәвешендә кергән.

//Ачлык арысланны да үләксәгә ташланырга мәҗбүр итә. Әс-Самарканди. *Бу сәнә ачлык җыланы чын халык бәгърен ашый! Кит, китап! Сабрит, дип әйтмә, ул халык көчен ашый!* Тукай. *Илсез калмас, телсез калмас өчен, Ачлык тотар көнгә калганбыз...* Газинур Морат. *Ачлык тоту* – ачлык игълан итү. Бу гыйбарә, «ураза тоту» сүзе үрнәгендә, XX гасыр азакларында барлыкка килде шикелле. ■

Телебезне кадерләп саклыйк

Рүзәл Юсупов

Бер телдәге сүзнең мәгънә төсмерләре икенче телдә, урынына карап, төрле сүзләр белән белдерелергә мөмкин. Тәрҗемәче бу үзенчәлек турында онытырга тиеш түгел, ләкин әлеге хәл һәрчак исәпкә алынмый. Нәтиҗәдә сөйләмдә һәр телнең үзенә генә хас үзенчәлекләре дөрес чагылдырылмый. Мәсәлән, урыс телендәге *колесо машины* чын татарча *машина көпчәге* дип, ә *колесо телеги – арба тәгәрмәче* дип йөртелә. Әмма хәзерге яшь каләм ияләре телнең мондый үзенчәлекләрен белеп бетермиләр – алар өчен машинада да, арбада да тәгәрмәчләр әйләнә: «*Тәгәрмәчләрне* вакытында алыштырса, машина йөртүче... юлда курыкмыйча хәрәкәт итә ала». Чын татарчасы: «*Көпчәкләрне* вакытында алыштырса, шофер юлда курыкмыйча йөри ала».

Хәзерге публицистика телендәге (шул ук вакытта берникадәр матур әдәбият телендәге һәм кайбер кешеләрнең сөйләмендәге дә) иң күп ялгышлар сүзләрнең үзара мәгънәви бәйләнеше, ягъни сөйләмдә (текстта) мәгънәләре буенча бергә килү кагыйдәләрен (нормаларын) бозу аркасында барлыкка килә.

Казан федераль университетындагы тел галимнәре яңа гына *татаристика* дигән термин уйлап чыгарганнар. Менә ул газетада ни рәвешле чагылыш тапкан: «Татарстанда туган телебездә

Ахыры. Башы журналның 10 нчы (2018) санында.

дипломат булырлык, чит телләрдән татарчага тәрҗемә итә алырлык, зур сәхнәдә чыгыш ясарлык милли кадрлар хәзерләнәме? Аларны бары бер генә уку йортында – КФУның *Татаристика* һәм тюркология югары мәктәбендә укытып чыгаралар». Кайсысының башына килде икән мондый экзотик сүз?! Ул морфология төзелеше буенча да, мәгънәсе буенча да адәм аңларлык һәм аңлатырлык сүз түгел. Мисал итеп китергән текстның эчтәлегенә караганда, ул *мәктәпне* (Ни өчен мәктәп? Ни өчен *бүлек*, яки *факультет*, яки *институт* түгел?) *татар мәдәнияте* бүлеге дип атарга кирәк булгандыр. Гомумән, соңгы елларда бу уку йортының структур бүлекләренә, төптән уйлап тормыйча гына, сәер исемнәр кушу модага кереп китте.

Төрле телдәге төп мәгънәләре белән тәңгәл сүзләрнең, башка тәңгәл сүзләр белән үзара мәгънә бәйләнешенә кереп, табигый әйтелмә (сүзтезмә) төзи алу-алмау үзенчәлекләрен белү һәм исәпкә алу – дөрес тәрҗемә итүгә ирешүдә төп кагыйдәләрнең һәм иң мөһим шартларның берсе.
Тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләрнең (татар журналистларының барысына да тәрҗемә итәргә туры килә) күбесе шушы кагыйдәне һәм дөрес тәрҗемә итү шартын тиешенчә үтәми.

Хәзерге публицистика телендәге (шул ук вакытта берникадәр матур әдәбият телендәге һәм кайбер кешеләрнең сөйләмендәге дә) иң күп ялгышлар сүзләрнең үзара мәгънәви бәйләнешен, ягъни сөйләмдә (текстта) мәгънәләре буенча бергә килү кагыйдәләрен (нормаларын) бозу аркасында барлыкка килә. Моны болай аңлату кулай булыр. Безнең сөйләмдә теләсә кайсы сүз, башка теләсә нинди сүз белән бергә килеп, конкрет мәгънә белдерә торган тәгъбир (сүзтезмә) тәшкил итә алмый, ягъни һәр сүзнең башка сүзләр белән мәгънәләре буенча бәйләнешкә керү мөмкинлеге чикләнгән була. Мәсәлән, *кош оча,* дип әйтә алабыз. Димәк, бу ике сүз үзара табигый бәйләнешкә кереп, конкрет мәгънәле әйтелмә яки җөмлә тәшкил итә. Ә *кеше оча,* дисәк, бу татарча дөрес сөйләм булмый, чөнки *кеше оча* алмый. Яки *чибәр кеше* дип әйтеп була, *чибәр йорт,* дип әйтеп булмый. Чөнки *чибәр* дигән сүз *кеше* сүзе белән табигый мәгънә бәйләнешенә керә ала, *йорт* сүзе белән – керә алмый: *чибәр йорт* дип әйтелми, *матур йорт,* диләр. Бу мәсьәләдә каләм ияләренә шуны белү әһәмиятле: ике телдәге төп мәгънәләре белән тәңгәл сүзләрнең башка тәңгәл сүзләр белән үзара мәгънәви бәйләнешкә керүе бер очракта бертөрле, икенче бер очракта төрле-төрле була. Мәсәлән, урыс телендәге *крупный, картофель* сүзләре һәм аларның татарча тәңгәллекләре *эре, бәрәңге* үзара ике телдә дә бертөрле табигый бәйләнешкә керәләр: *крупный картофель – эре бәрәңге*. Шуның белән бергә, урыс телендәге *крупный* һәм *город* сүзләре, үзара мәгънә бәйләнешенә кереп, табигый әйтелмә тәшкил итсәләр *(крупный город)*, аларның татарча тәңгәллекләре булган *эре* һәм *шәһәр* үзара андый бәйләнешкә керә алмыйлар: чын татарча *эре шәһәр* дип әйтмиләр, *зур шәһәр,* диләр.

Төрле телдәге төп мәгънәләре белән тәңгәл сүзләрнең, башка тәңгәл сүзләр белән үзара мәгънә бәйләнешенә кереп, табигый әйтелмә (сүзтезмә) төзи алу-алмау үзенчәлекләрен белү һәм исәпкә алу – дөрес тәрҗемә итүгә ирешүдә төп кагыйдәләрнең һәм иң мөһим шартларның берсе.

Тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләрнең (татар журналистларының барысына да тәрҗемә итәргә туры килә) күбесе шушы кагыйдәне һәм дөрес тәрҗемә итү шартын тиешенчә үтәми. Шуның аркасында публицистика телендә күп бәла-казалар килеп чыга да инде. Кайбер мисаллар китерик.

«Рәмзия... чынбарлыкны ачыктан-ачык яңгыратты». Татарча әйбәт белгән кеше шулай «*чынбарлыкны яңгыратты*», дип сөйләр идеме икән?! «...*Чынбарлыкны әйтеп бирде* яки *сөйләп бирде* (*ачып бирде* һ.б.ш.) булырга тиеш, әлбәттә.

Сүзләр сөйләмдә (текстта) бер-берсе белән мәгънәләре буенча бәйләнешкә билгеле бер чаралар ярдәмендә керәләр. Аларның вазыйфаларын бәйлекләр, бәйлек сүзләр, кушымчалар, янәшә тору, сүз тәртибе дигән грамматик күренешләр тәшкил итә. Менә шушы бәйләү чараларын куллану кагыйдәләрен (нормаларын) дөрес куллана белмәү сәбәпле дә телебездә күп ялгышлар килеп чыга.

«Бу санны Украина Президенты Петр Порошенко яңгыратты». *Санны* ничек *яңгыратып* була икән? «Бу *санны*... Порошенко *әйтте (атады, китерде* һ.б.) кирәк.

«Туры элемтә»дә *яңгыраган сораулар* турында» (мәкалә исеме). Дөресе – «Туры элемтә»дә *бирелгән сораулар турында*».

«Бу хакта Камил Фатыйхов матбугат конференциясендә җиткерде». «Бу хакта ... әйтте (сөйләде, хәбәр итте, игълан итте һ.б.) кирәк.

«Сәламәт яшәү рәвеше *алып бару* өчен шартлар бармы?» («*Вести* здоровый образ жизни» фразасының мәгънәсез калькасы). Моны татар сүзләре белән урысча сөйләү, дип әйтергә була. Гади генә, чын татарча итеп, «Сәламәт яшәү өчен шартлар бармы?» дип әйтергә буладыр бит, ләбаса.

«Бу хәбәрне ишетүгә улым янына *очтым*». Дөресе – «...улым янына *киттем*».

«Россия туристлары Мисырга Минск аша *оча* башлаган». «...Минск аша *йөри* башлаган» кирәк.

«Казаннан Германиягә кышын да *очып* булачак». Чын татарчасы – «Казаннан Германиягә *самолет белән* кышын да (кышкы айларда да) *барып* булачак».

Бер газетадагы мәкалә исеме «Алар хәтергә лаек» дип атала. Татарча алай сөйләмиләр. Мәкаләдә сүз Казан психик авырулар төрмә-хастаханәсендә үлеп калган сәяси тоткыннар турында бара. Димәк, аның исемен яки «Алар искә алуга лаек» («Алар онытылырга тиеш түгел», «Алар хәтердә саклансын») дип, яки башкача шулайрак итеп куярга кирәк иде.

«Кушлавыч авылында Тукай һәйкәлен *ачу*». «Тукай һәйкәлен ачу», дип әйтүгә караганда «Тукайга һәйкәл *кую*», дисәң, дөресрәк булмас идеме икән?

«Нинди авырлыклар белән күрештегез?» – дип сорый ТНВ телевизион каналындагы тапшыруны алып баручы. Урысчадагы: «С какими трудностями встретились?» – дигән җөмләне шулай тәрҗемә итеп әйтә ул. «Мине шәһәргә тартмый» («меня не тянет к городу»ның хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе), дип сөйли бирәү шул ук ТНВда. Татар телен ничек тупас бозу болар! Телне мондый дәрәҗәдә белүчеләр, дөресрәге, белмәүчеләр эфирга чыгарга тиеш түгел, әлбәттә.

Бүгенге татар матбугаты битләрендә *тере тавышка* җырлау (дөресе – *турыдан-туры, алдан яздырмыйча* җырлау), авылыма – 90 *яшь* (авылыма – 90 *ел*), *бөртек* суктыру (*ашлык* суктыру), *эре* шәһәрләр (*зур* шәһәрләр), бюджет *өстендә эшлибез* (бюджет *әзерлибез*), *үзәк көю (сару кайнау)*, юл *хезмәте* эшли (юл *хезмәткәрләре* яки юл *чистартучылар*, *төзүчеләр* һ.б. эшли), *һава торышы* бозыла (*һава* яки *көн* бозыла) кебек йөзләрчә, меңнәрчә гайре табигый, туган тел кагыйдәләренә (нормаларына) туры килми торган әйтелмә, гыйбарәләр хөкем сөрә.

Әле генә без сөйләмдә сүзләрнең үзара мәгънәви бәйләнеше кагыйдәләрен (нормаларын) бозу аркасында барлыкка килгән ялгышларны карап киттек. Мәгълүмат чаралары телендә киң таралган хаталарның тагын бер төрен күрсәтмәсәк, язмабыз тулы булмас иде.

Сүзләр сөйләмдә (текстта) бер-берсе белән мәгънәләре буенча бәйләнешкә билгеле бер чаралар ярдәмендә керәләр. Аларның вазыйфаларын бәйлекләр, бәйлек сүзләр, кушымчалар, янәшә тору, сүз тәртибе дигән грамматик күренешләр тәшкил итә. Менә шушы бәйләү чараларын куллану кагыйдәләрен (нормаларын) дөрес куллана белмәү

Безнең мирас №11 ноябрь 2018

сәбәпле дә телебездә күп ялгышлар килеп чыга. Һәм бу ялгышларның да нигезендә дөрес тәрҗемә итү принципларыннан һәм ысулларыннан хәбәрдар булмау, төгәлрәк итеп әйткәндә, бер телдәге сүзне икенче телгә ялгыш, хәрефкә-хәреф (буквально) күчерү ята. Мисалларга мөрәҗәгать итик.

Ниһаять, журналистларга да, татар теле белән эш итүче барлык башка һөнәр ияләренә дә телебезгә җитди карарга, аны яхшы итеп өйрәнергә, дөрес итеп кулланырга, кадерләп сакларга күнегергә вакыттыр инде.

«Арпад Галгоци үз истәлекләре белән уртаклашты». Саф татарчасы «Арпад Галгоци истәлекләрен уртаклашты». *Уртаклашу*ны үзенә ияреп килгән башка сүзләргә, урыс теле калыбында, *белән* бәйлеге ярдәмендә бәйләү күренеше киң таралган. Хатирәләре белән, шатлыклары белән, кайгылары белән һәм башка нәрсәләр белән уртаклашу, дип язалар һәм сөйлиләр кайбер татарча начар белгән кешеләр. Боларның берсе дә дөрес түгел, барысы да – тупас ялгыш. Чын татарча, мәсәлән: «Мин дусларым белән шатлыгымны уртаклашам», «Ул мөлкәтен ярлылар белән бүлешкән».

Канәгать сүзе белән килгән әйтелмәләрдә дә хаталар күп очрый. Мәсәлән: «Әсхәт бронза медаль белән канәгать түгеллеген әйтте». Дөресе – «Әсхәт бронза медальдән канәгать түгеллеген әйтте». *Канәгать* әйтелмәдә үзе ияртеп килгән сүз белән чыгыш килеше кушымчасы –дан/ –дән (–тан/ –тән, –нан/ –нән) ярдәмендә бәйләнә: «Мин аның эшеннән канәгать түгел».

Безнең мәгълүмат чараларында, күп еллар буена кулланылып, бүгенге көнгә килеп җиткән бик шыксыз бер ялгыш тәгъбир – *күзлектән чыгып карау бар:* «Мәдәни үсеш *күзлегеннән чыгып караганда* Универсиададан ким түгел». Дөресе – «Мәдәни үсеш *күзлегеннән караганда* Универсиададан ким түгел».

Соңгы елларда *гармунда уйнау, пианинода уйнау, скрипкада уйнау* һәм башка төрле музыка коралларында *уйнау* дип сөйләү һәм язу гадәти күренешкә әверелеп бара. Мәсәлән: «...баянда уйнарга да шунда өйрәнгән» (дөресе – «...баян уйнарга да шунда өйрәнгән»). Татар телендә *уйнау* сүзе сөйләмдә үзе ияртеп килгән сүз белән баш һәм төшем килешләре кушымчалары ярдәмендә бәйләнешкә керә: *курчак уйнау, шахмат уйнау, баян уйнау (баянны яхшы уйнау)* һ.б. Бу форма татар теленең катгый законы (кагыйдәсе, нормасы) белән беркетелгән һәм аны үз белдеге белән бозарга беркемнең дә хакы юк.

Мондый тел бозу күренешләре булырга тиеш түгел. Алар туган телебезнең гасырлар буе камилләшкән, чарланган табигый кулланылыш тәртибен, нигезен какшатуга, таркатуга китерә.

Ниһаять, журналистларга да, татар теле белән эш итүче барлык башка һөнәр ияләренә дә телебезгә җитди карарга, аны яхшы итеп өйрәнергә, дөрес итеп кулланырга, кадерләп сакларга күнегергә вакыттыр инде.

Туган тел ул – ата-анабыз, туган җиребез кебек үк газиз нәрсә, халкыбызның нигезе. Телебез бетсә, үзебез дә алдынгы, мәдәниятле милләт буларак яшәүдән туктаячакбыз.

Безнең дәүләт җитәкчеләребез, «ТАТМЕДИА» оешмасы, язучылар һәм журналистлар союзлары, Татарстан фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре телебезнең сафлыгын саклау, дөрес кулланылышына ирешү мәсьәләләре белән җитдирәк шөгыльләнергә, бу юнәлештә конкрет һәм катгый чаралар күрергә тиеш. ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

КАЗАН ГУБЕРНАСЫНЫҢ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ БАСМАЛАРЫ ТУПЛАНМАСЫ

Казан губернасында чыккан журналлар һәм газеталар – мәдәни мирасның бер өлеше, алар, шушы җирлек белән бәйләп нәшер ителгән күп санлы фәнни, фәнни-популяр басмалар, дәреслекләр һ.б. белән беррәттән, төбәк тарихын тулыландыра, баета.

Мәдәни төрлелек һәм кабатланмас үзенчәлекләр хас булган тулы канлы тормыш Казан губернасында кайнап торган.

Казан губернасы периодик басмалары арасында педагогик, иҗтимагый-сәяси, дини һәм башка махсуслашкан басмаларны аерып күрсәтергә мөмкин. Педагогикага караган журналлар һәм газеталар төркеме шактый тулы, болар – «Вестник образования и воспитания», «Начальное обучение», «Циркуляр по Казанскому учебному округу» журналлары. Алар губернадагы мәктәп һәм мәгърифәт тарихы, тәрбия һәм белем бирүдә яңа алдынгы башлангычлар, чит илләрнең мәктәп тормышы тәҗрибәсе турындагы материалларны үз эченә ала.

Икенче төркем – иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге журналлар һәм газеталар: «Волжско-Камское слово», «Волжский вестник», «Деятель», «Журналы и протоколы заседаний Казанской Городской Думы», «Заволжский муравей», «Земская неделя», «Казанские известия», «Казанские губернские ведомости», «Казанский телеграф» һәм «Крестьянская газета». Аларда төп темалар буларак яңалыклар, җирле тарих, сәяси күзәтүләр, хөкүмәт карарлары, сәүдә хәбәрләре, шау-шулы «эшләр», белешмә мәгълүматлар һәм реклама чагылыш тапкан. Һәрберсендә әдәби сәхифә булып, анда яңа китаплар, шул заманның әдәби әсәрләре, халыкның нәрсә укуы турында фикер алышканнар.

Өченче төркемне дини, рухани юнәлештәге басмалар тәшкил итә: «Православный собеседник», «Сотрудник братства святого Гурия», «Церковно-общественная жизнь», «Известия по Казанской епархии». Чиста дини мәкалә-язмалар белән бергә боларда мәдәният үсешенә, тарихка, гореф-гадәтләргә, руханилар арасыннан булган авторлар иҗатына, шулай ук губернадагы китапханәчелек эшенә дә җитди игътибар бирелгән.

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

ТВЕРГЪ, 2 ДЕКАБРЯ 1882. Г. КАЗАНЬ. ЧЕТВЕРГЪ, 2 ДЕКАБРЯ 1882.

ВОЛЖСКО-КАМСКОЕ СЛОВО

ПОЛИТИЧЕСКО-ОБЩЕСТВЕННАЯ ГАЗЕТА

ВЫХОДИТЪ ТРИ РАЗА ВЪ НЕДѢЛЮ, ПО ВТОРНИКАМЪ, ЧЕТВЕРГАМЪ И СУББОТАМЪ.

пятницу, 10-го декабря,
НЕФИСЪ П. Ф. СОЛОНИНА
ПРЕДСТАВЛЕНО БУДЕТЪ:
1.
Е ОТЪ УМА.
Комедія въ 4 д., соч. Грибоѣдова.
2.
ТЕННАЯ НЕВИННОСТЬ.
ствіи, съ пѣніемъ, музыка Императорскихъ театровъ.
3.
ДИВЕРТИСМЕНТЪ.
заблаговременно можно получать въ кассѣ театра.

рникъ, 7-го декабря 1882 г.,
ВЪ ГОРОДСКОМЪ ТЕАТРѢ
ТЪ ВСПОМОГАТЕЛЬНАГО ОБЩЕСТВА ПРИКАЗЧИКОВЪ
ПРЕДСТАВЛЕНО БУДЕТЪ:
1.
ОСЛАВИЛИСЬ.
едія въ 4-хъ дѣйствіяхъ, соч. Н. Я. Соловьева.
мидгофъ, Суревичъ, Лопухина, Трефилова и др.; г.г. Полтавцевъ, Никешинъ, Ленскій, Солонинъ, Матрозовъ, Конаковъ и друг.
2.
РОФЛЕ-ЖИРОФЛЯ.
еская опера, муз. Лекока. Данъ будетъ 2-й актъ.
а, Попова, Прокофьева; г.г. Синельниковъ, Эспе, Большаковъ, Петровъ и хоръ.
НАЧАЛО ВЪ 7½ ЧАСОВЪ.
говременно въ квартирѣ Правленія, въ зданіи Купеческой Биржи, отъ бухгалтера, а

крытіе въ Западной Сибири перваго особаго управленія государственными имуществами.

Дѣло Мартовой съ Александровымъ будетъ разсматриваться мировымъ судомъ.

„Голосъ" передаетъ, что коммиссія сокращенія войсковыхъ нарядовъ для караульной и конвойной службы проектируетъ особую тюремную и конвойную стражу, подвѣдомственную министерству внутреннихъ дѣлъ. Реформы предполагается начать съ западныхъ губерній и осуществить въ три года. Войсковые караулы наряжать впредь только въ большихъ тюрьмахъ.

Миклуха-Маклай выѣхалъ въ Австралію.

Коммиссія, разслѣдовавшая безпорядки въ харьковскомъ ветеринарномъ институтѣ, присудила: исключить безусловно 13, на извѣстные сроки 4 и выслать къ родителямъ 65 человѣкъ.

СОФІЯ. Выборы завершились полнымъ торжествомъ партіи, преданной князю. Ни одинъ радикалъ не избранъ. Выборы прошли совершенно спокойно.

(Среда, 1 декабря).

ОДЕССА. Начато слѣдствіе о неправильной выгрузкѣ балласта въ Азовскомъ морѣ. Привлечены къ отвѣтственности два бывшіе управляющіе Таганрогской корабельной конторой.

ВОЛОГДА. Торги на вырубку казенныхъ лѣсовъ сѣверныхъ уѣздовъ для заморскаго отпуска не состоялись вслѣдствіе высокой таксы.

СОФІЯ. Въ срединѣ ноября произведены въ Македоніи многочисленные аресты болгаръ; часть арестованныхъ отправлена въ кандалахъ

✦ „Новости" сообщ
столѣтія торговой фирм
бургскій голова Глазу
Станислава 1-й ст.;
въ дворяне.
✦ „Голосу" сообща
послѣднее время, по
земской управы, волост
было собрать свѣдѣнія
вреждено червемъ озим
неожиданно пришлось
Многіе изъ крестьянъ,
только скрывали дѣй
истребленныхъ посѣвов
казывались дать какія
ихъ словамъ, „грѣхъ
объявляя, что червь н
✦ Газета „Сибирь"
стоящее время, въ
изыскиваются мѣры
чайно усилившихся въ
говъ рабочихъ съ золо
цѣлью предполагается
отношенія между зо
пріисковыми рабочими.
— Въ Выборгѣ го
дняхъ къ смертной
тельницу, вдову крест
жегшую лавку своего
Приговоръ будетъ пре
утвержденіе.
✦ Съ границы Ки
тября, что китайцы н
риторіи совершаютъ

Яшәешнең төрле тармакларына, һөнәри юнәлешләргә караган, ягъни махсуслашкан журналлар һәм газеталар тагын бер төркемгә керә: «Казанский медицинский журнал», «Журнал Казанского общества пчеловодства», «Наш край», «Известия общества археологии, истории и этнографии» һәм «Казанская кооперативная газета».

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлегендәге Казан губернасы газеталары җыелмасы гаять зур тарихи-мәдәни һәм фәнни кыйммәткә ия. Алар аз санда сакланып калган, шулай булса да, махсус өйрәнүчеләрдә һәм киң катлам укучыларда кызыксыну уяталар. Әлеге җыелмадан укучылар тагын да иркенрәк һәм күбрәк файдалансын өчен, соңгы елларда актив рәвештә цифрлаштырылалар.

Моннан йөз ел элек Казан губернасының 83 китапханәсе 172 нөсхә газета и 55 исемдәге 385 нөсхә журнал яздырып алган. Казан губернасының вакытлы матбугат басмалары тупланмасында җиде исемдәге газета саклана, алар 1815 елдан 1917 елга кадәрге вакыт аралыгына карый.

1917 елгы октябрь инкыйлабы белән бәйле сәяси һәм башка вакыйгалар газета-

лар нәшер итүдә тотрыксызлык һәм тәртипсезлек китереп чыгарган, аларны планлы рәвештә җыеп бару да мөмкин булмаган. Шуңа күрә бер генә китапханәдә дә, хәтта иң эреләрендә дә, газеталарның тулы җыелмалары юк, төрле фондларда кайбер аерым саннары яки тулы булмаган төпләмәләре генә саклана. Татарстан Милли китапханәсенең Казан губернасы вакытлы матбугаты тупланмасы да бу җәһәттән искәрмә түгел.

Казан губернасында газеталар чыгару актив үскән, ләкин бу бер дә җиңел эш булмаган. Күп хезмәт кую, газетаның төзелешен камилләштереп тору, кызыклы һәм аң-белем бирерлек сыйфатларын даими кайгырту таләп ителгән. Матбугат басмасын цензура япмасын өчен дә күп көч сарыф ителгән. Ул заманнарда газетаны йорттагы тәрәзә белән чагыштырганнар. Якты дөньяда ниләр барлыгын күрәсең килсә, тәрәзә янына кил... Ә тәрәзәсез йортта яшәп кара – сукыраясың. Казанда нәшер ителгән газеталар үз укучыларына файдалы булырга тырышканнар, төрле проблемалар турында язып,

№ 5 Земская Недѣля 7

ЗЕМСКАЯ ЖИЗНЬ.

Казанское земство.

Цѣнное пріобрѣтеніе.

24-го января по случаю пріобрѣтенія Казанскимъ губернскимъ земствомъ дома З. Н. Ушковой состоялось скромное торжество.

На торжествѣ присутствовали: губернскій предводитель дворянства С. С. Толстой-Милославскій, уѣздный предводитель дворянства А. Н. Боратынскій, предсѣдатель и члены губернской земской управы, служащіе губернскаго земства, представители печати и др.

Причтомъ Воскресенской церкви совершено былъ въ главномъ залѣ пріобрѣтеннаго дома молебствіе, съ провозглашеніемъ многолѣтія Государю Императору и всему Царствующему Дому, доблестной русской арміи и земскимъ дѣятелямъ.

По окончаніи молебствія С. С. Толстой-Милославскій, привѣтствуя губернское земство по случаю цѣннаго пріобрѣтенія, провозгласилъ здравицу Государю Императору, покрытую ура и троекратнымъ исполненіемъ національнагогимна.

Послѣ этого присутствующимъ на праздникѣ, по русскому обычаю, была предложена хлѣбъ-

Домъ губернскаго земства, недавно купленный у Ушковыхъ.

...тала не было, такъ что расплату за пожарные убытки приходилось покрывать займами.

Отсутствіе контроля вызвало злоупотребленія при ликвидаціи пожарныхъ убытковъ и порождало спекулятивные пожары. Число пожаровъ стало расти, и пожарные убытки превышали страховые платежи.

Къ 1891 году долгъ Правительству возросъ до 800 тысячъ рублей, а выдача погорѣльцамъ убытковъ задерживалась на продолжительное время.

Наконецъ, Губернское Земство сознало, что все зло заключается въ неправильной постановкѣ страхового дѣла, а главнымъ образомъ, въ отсутствіи контроля на мѣстахъ.

Покойный К. Н. Буличъ, бывшій въ то время Членомъ Губернской Управы, реорганизовалъ страховое дѣло и настоялъ на введеніи института страховыхъ агентовъ. Результаты сказались быстро: число пожаровъ сократилось болѣе чѣмъ вдвое, а платежи стали поступать аккуратно. Чтобы не быть голословнымъ, считаю необходимымъ доказать это цифрами: Такъ въ 1891 году до введенія агентуры было 1246 пожаровъ въ губерніи, за что пришлось уплатить 700 тыс. руб., а въ 93 году — только 481 пожаръ и выдано 132 тысячи, т. е. число пожаровъ сократилось въ 2, 6, а сумма убытковъ сократилась болѣе чѣмъ въ 5 разъ.

Долги вскорѣ были погашены, и сталъ накапливаться запасный капиталъ.

14 лѣтъ тому назадъ, когда мнѣ при-



КАЗАНСКІЯ ИЗВѢСТІЯ.

№ 8.

Среда, Генваря 27-го дня, 1815 года.

Казань, 25 го Генваря.

Сего Генваря 24-го числа въ здѣшнемъ Каѳедральномъ Благовѣщенскомъ соборѣ Архимандритами съ прочимъ Духовенствомъ по окончаніи Литургіи отправляемо было погребеніе преставшагося Архіепископа Казанскаго и Симбирскаго Павла. При семъ Каѳедральнаго собора Протоіереей и Кава... ...ная могила, каковыя приготовлены еще при построеніи собора. Со времени поставновленія гроба съ 17-го числа на амвонъ въ холодномъ соборѣ, множество народа каждодневно посѣщало сей соборъ для прощенія съ Архипастыремъ, а между тѣмъ у гроба безпрестанно находились члены изъ Духовенства и читано евангеліе. Миръ праху твоему почтенный Архипастырь!

КАЗАНСКАЯ ГАЗЕТА.

Новый годъ.

Онъ прошелъ. Прошелъ тотъ годъ, въ теченіи котораго Россія пережила величайшія потрясенія.

Утомленная, израненная, окровавленная и еще болѣе обѣднѣвшая Русь нынѣ переступаетъ порогъ пережитаго года.

Не судилъ Богъ русскимъ людямъ совершить обновленіе своей родины безъ перенесенія великихъ несчастій. Не явился на Руси во время геній, все предвидящій, все могущій, который бы отклонилъ отъ страны чашу горькихъ испытаній и окольнымъ путемъ, минуя историческую неизбѣжность, вывелъ бы русскій народъ на путь мирнаго развитія.

Пережитъ годъ трудный, годъ тяжелый, пережитъ годъ великихъ волненій русскихъ людей, великихъ сотрясеній всей земли русской. Въ теченіе прошлаго года русскіе люди кругомъ себя видѣли только озлобленіе, раззореніе, кровавыя распри, сиротство, голодъ. Высочайшіе манифесты, вносили лишь временное утишеніе страны, за которымъ вновь вихремъ мятежнымъ поднимались страсти людскія.

Истекъ страшный годъ, что обѣщаетъ дать новый?

Каждаго окрыляютъ надежда и вѣра при встрѣчѣ новаго года. Хотя надежды часто обманчивы, хотя вѣра расшатана у всѣхъ, но всякій невольно опирается на эти чувства, всегда всѣмъ сулящія блага. Хочется вѣрить, что только тотъ, ушедшій въ вѣчность, годъ былъ годомъ разрушенія, а грядущій будетъ годомъ великаго творенія новыхъ порядковъ и новыхъ законовъ на русской землѣ. Творить же русскимъ людямъ придется такъ много, много.

Великія задачи задало время русскимъ людямъ.

Старое зданіе государственнаго устройства обвѣтшало, многія части его рухнули. Что, гдѣ и сколько разрушилось покуда ясно не видно. По планамъ, предлагаемымъ русскому народу правительствомъ, можно усмотрѣть, что въ одномъ мѣстѣ долженъ быть произведенъ лишь ремонтъ, въ другомъ новая стройка. И ремонтъ и работу заново придется произвести во всемъ зданіи и снаружи и внутри, начиная съ верховъ, кончая фундаментомъ.

Однако можетъ-ли великое, много обѣщающее русскому народу строительство проявиться, когда въ странѣ совершается бурное броженіе умовъ.

Тѣсто бываетъ готовымъ, когда оно сверху до низу все перебродитъ.

Вся Русь до самыхъ глубокихъ слоевъ перенесла уже бурное броженіе. Разумъ подсказываетъ, что бурное броженіе кончается и скоро наступитъ то успокоеніе, при которомъ возможно будетъ русскимъ людямъ заняться созданіемъ новыхъ лучшихъ порядковъ жизни. Разумъ укрѣпляетъ въ вѣрѣ, что скоро и умный, и глупый, и умъ просвѣщенный и темный невѣжда со счетами въ рукахъ убѣдятся вполнѣ, что для каждаго и для всей страны выгоднѣе стремленіе къ добыванію возможныхъ благъ только мирнымъ путемъ при руководительствѣ здраваго смысла, а не слѣдованіе приказу слѣпой безрасчетной страсти.

Скоро умъ большинства русскихъ людей опознаетъ, что путь для мирной, достигающей всяческихъ благъ работы свободенъ. Скоро всякій усмотритъ, что не сжатый кулакъ, а мыслящій умъ создастъ на Руси и порядокъ и равноправіе, укажетъ дорогу къ обогощенію, дастъ возможность усвоить русскому народу свободу и научитъ пользоваться всѣми исходящими изъ нея благами.

Вѣримъ, что такое самосознаніе наступитъ въ новомъ году и вмѣстѣ съ нимъ наступитъ возможность государственнаго и общественнаго строительства.

Нельзя ожидать, чтобы броженіе русскихъ умовъ прекратилось совсѣмъ, да и желать этого не нужно. Броженіе умовъ будетъ и въ настоящемъ году, но оно будетъ болѣе покойное, не грозное, для страны не опасное. Оно будетъ проявляться не въ заревѣ пожаровъ, не въ ружейной пальбѣ, не въ разбоѣ, грабежѣ, насиліи и беззаконіи, а въ усиленномъ созиданіи желанныхъ порядковъ жизни, въ развитіи самосознанія и самодѣятельности русскихъ людей, въ развитіи общественной мысли. Такое броженіе умовъ будетъ составлять сущность обновленія страны.

Мало толку бываетъ въ очень буйно растущихъ посѣвахъ. Также мало толку можетъ выйти и отъ бурнаго роста страны.

Нельзя безъ вреда для деревьевъ постоянно срѣзать молодые побѣги. Нельзя также допускать особенно буйный ростъ молодыхъ вѣтвей, ибо древесина ихъ будетъ столь нѣжной, что первый зимній морозъ ихъ погубитъ.

Нельзя задерживать ростъ страны безъ вреда для нея. Нельзя также и думать, чтобы страна могла сама себя въ ростѣ своемъ обогнать.

Русскій народъ, переживавшій въ истекшемъ году бурное броженіе умовъ, въ наступившемъ — новомъ познаетъ чувство мѣры и заростетъ страна крѣпкимъ здоровымъ ростомъ.

хәбәр итеп торуны сораганнар, газетаны яздырып алырга кыстаганнар.

Газеталар арасында иң әүвәлгесе – 1815 елгы «Казанские известия»; әлеге иҗтимагый-сәяси басма берничә бүлектән тора: «Төрле хәбәрләр», «Белдерүләр», «Һава торышын күзәтү». «Төрле хәбәрләр» бүлегенә барлык дөньякүләм яңалыклар һәм Россия империясе яңалыклары урнаштырылган. Сугышлар, хакимият алышынулар, тәхеткә утырулар, хәйриячелек, хәрби дәрәҗәләр бирү,



тѣля, равномѣрно съ достодолжною благодарностію всѣ благія попеченія начальства потому открыто давалъ отчетъ въ дѣлахъ своихъ, желая показать годичныя усилія къ достиженію предположенной цѣли его заведенія и тѣмъ оправдывать надежду какъ Августѣйшаго Монарха, благоволившаго осчастливить оный непосредственнымъ Своимъ покровительствомъ, такъ попечительнаго начальства и любезнаго сердцамъ вѣрноподданныхъ Отечества.

Почитая для многихъ читателей сихъ листковъ неизлишнимъ краткое свѣденіе какъ о Казанскомъ Университетѣ такъ и учебномъ его округѣ, Редакторъ помѣститъ здѣсь извлеченныя имъ изъ документовъ извѣстія какъ объ Университетѣ, такъ объ учебныхъ заведеніяхъ округа, о принесенныхъ пожертвованіяхъ, о публичныхъ преподаваніяхъ на слѣдующій Академическій годъ.

Историческія ученыя достопримѣчательности Императорскаго Казанскаго Университета въ теченіе Академическаго года съ Іюля 1814 го до Іюля 1815 года.

Изъ мужей, прославившихся покровительствомъ наукъ, особенно въ любезномъ Отечествѣ нашемъ, и особъ ученостію и трудами на поприщѣ оной отличившихся избраны и утверждены почетными членами:

1) *Графъ Николай Петровичъ Румянцовъ*, Канцлеръ и Кавалеръ.

2) *Гавріилъ Романовичъ Державинъ* — Дѣйствительный Тайный Совѣтникъ и Кавалеръ.

3) *Григорій Семеновичъ Волкон-*

(321)

бургскій военный Губернаторъ и Кавалеръ.

4) *Иванъ Ивановичъ Дмитріевъ* — Тайный Совѣтникъ и Кавалеръ.

5) *Александръ Семеновичъ Шишковъ* — Вицеадмиралъ, Государственнаго Совѣта членъ и Кавалеръ.

6) *Графъ Дмитрій Ивановичъ Хвостовъ* — Тайный Совѣтникъ, Сенаторъ и Кавалеръ.

7) *Евгеній* — Епископъ Калужскій и Кавалеръ.

8) *Николай Николаевичъ Новосильцовъ* — Тайный Совѣтникъ и Кавалеръ.

9) *Иванъ Ивановичъ Мартыновъ* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

10) *Николай Яковлевичъ Озерецковскій* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ,

11) *Николай Ивановичъ Фусъ* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

12) *Яковъ Васильевичъ Виллie* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

13) *Александръ Александровичъ Крейтонъ* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

14) *Яковъ Ивановичъ Лейтонъ* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

15) *Федоръ Ивановичъ Фонъ Бракке* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ, Вятскій Гражданскій Губернаторъ.

16) *Густавъ Андрѣевичъ Розенкампфъ* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

17) *Вильгельмъ Михайловичъ Рихтеръ* — Дѣйствительный Статскій

18) *Федоръ Ивановичъ Шубертъ* — Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

19) *Иванъ Федоровичъ Крузенштернъ* — Флота Капитанъ 1-го ранга и Кавалеръ.

20) *Николай Михайловичъ Карамзинъ* — Коллежскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

21) *Андрѣй Ивановичъ Лобенвейнъ* — Коллежскій Совѣтникъ и Кавалеръ.

Университетъ почитая всѣмъ вообще извѣстными въ Отечествѣ отличныя заслуги вышесказанныхъ особъ по просвѣщенію, почитаетъ излишнимъ распространяться объ ономъ.

22) *Иванъ Франкъ* — Дѣйствительный Статскій Совѣтникъ и Кавалеръ, Заслуженный Профессоръ, Отличный мужъ по усовершенствованію врачебныхъ наукъ — въ Гейдельбергѣ.

23) *Гуфеландъ* — Королевскій Прусскій Статскій Совѣтникъ и Лейбъ-медикъ, отличный мужъ по усовершенствованію врачебныхъ наукъ — въ Берлинѣ.

24) *Анзельмъ фонъ Фейербахъ* — Королевскій Баварскій Тайный Совѣтникъ, отличный мужъ по усовершенію наукъ юридическихъ — въ Минхенѣ.

25) *Силвестръ де Засси* — Членъ Французской Королевской Академіи наукъ и Кавалеръ почетнаго легіона, прославившійся по части Восточной Словесности — въ Парижѣ.

26) *Графъ Грегоаръ* — Членъ Французской Королевской Академіи наукъ и Кавалеръ почетнаго легіона — въ Парижѣ.

27) *Карлъ Гауссъ* — Профессоръ Геттингенскаго Университета, славный

(322)

28) *Георгій Прохаска* — Профессоръ Вѣнскаго Университета, мужъ прославившійся усовершеніемъ Врачебныхъ наукъ. — въ Вѣнѣ.

29) *Іоганъ Горнеръ* — извѣстный Астрономъ, сотрудникъ въ путешествіи Крузенштерна во кругъ свѣта — въ Цирихѣ.

30) *Іоганъ Тромсдорфъ* — славный Химикъ, — въ Эрфуртѣ.

31) *Плацидъ Гейнрихъ* — прославившійся по части Математико-Физическихъ наукъ — въ Регенсбургѣ.

32) *Георгій Лорсбахъ* — Профессоръ, прославившійся по части Восточной словесности, — въ Іенѣ.

33) *Беллерманъ* — Директоръ Келнской Гимназіи въ Берлинѣ, прославившійся въ Филологическихъ наукахъ, — въ Берлинѣ.

34) *Антонъ Тибо* — Надворный Совѣтникъ, Профессоръ, славный Правовѣдецъ, — въ Гейдельбергѣ.

35) *Гуго* — Профессоръ Геттингенскаго Университета, въ здѣшнемъ Университетѣ по отдѣленію Нравственно Политическихъ наукъ Корреспондентъ, славный правовѣдецъ — въ Геттингенѣ.

36) *Іедикe* — Коммисіонсъ-ратъ, и здѣсь по отдѣленію Математико Физическихъ наукъ Корреспондентъ, — въ Берлинѣ:

37) *Зейлеръ* — Бывшій Профессоръ въ Виттенбергѣ и здѣсь по отдѣленію Врачебныхъ наукъ Корреспондентъ — нынѣ въ Дрезденѣ.

38) *Оловъ Тихсенъ* — Ростокскаго Университета Вицеканцлеръ и заслуженный Профессоръ и Кавалеръ, прославившійся по части Восточной Словесности, здѣсь по отдѣленію Словесныхъ наукъ Корреспондентъ, — въ Ростокѣ.

Кромѣ сего еще въ прошедшемъ предъ симъ Академическомъ году по прошенію Университета благоволили на себя принять званіе почетныхъ членовъ Начальники и усердные Покровители онаго Его Сіятельство Графъ Алексѣй Кириловичъ Разумовскій и Его Превосходительство Михаилъ Александровичъ Салтыковъ. Такимъ образомъ Университетъ имѣетъ нынѣ удовольствіе видѣть въ числѣ почетныхъ своихъ членовъ 40 мужей славныхъ въ области учености и Просвѣщенія, изъ нихъ 23 въ Россійской Имперіи: въ Санктпетербургѣ, Москвѣ, Оренбургѣ, Вяткѣ, Варшавѣ, Вильнѣ, и 17 въ иныхъ земляхъ: во Франціи въ Парижѣ, въ Германіи въ Вѣнѣ, Берлинѣ, Минхенѣ, Ростокѣ, Геттингенѣ, Гейдельбергѣ, Іенѣ, Эрфуртѣ и Регенсбургѣ и въ Швейцаріи въ Цирихѣ; изъ сихъ четыре особы въ Берлинѣ, Дрезденѣ, Ростокѣ и Геттингенѣ приобщены для отправленія Корреспонденціи, доставленія свѣденій о новыхъ въ наукахъ изобрѣтеніяхъ и исправленія препорученій Университета, равно и для сношеній съ учеными обществами.

Деканами отдѣленій на слѣдующій Академической годъ утверждены: прежніе по отдѣленію Нравственно-Политическихъ наукъ Профессоръ Цеплинъ, Физико-Математическихъ Проф. Бартельсъ, Врачебныхъ — Проф. Эрдманнъ, и вновь, Словесныхъ: П. О. Профессоръ восточныхъ языковъ Френъ.

мәктәпләр һәм хәрби уку йортлары ачу белән бәйле вакыйгалар җентекләп сурәтләнгән. «Белдерүләр» бүлеге нәрсә сату яки сатып алу, кемнәргә бала караучы булып урнашу, кемнең яхшы тукымалар яки модалы эшләпәләр тәкъдим итүе һ.б.ш. турындагы хәбәрләрне җиткергән. «Һава торышын күзәтү» бүлеге бигрәк тә кызыклы. Биредә аеруча катгый төгәллек белән атнаның һәр көне, иртәдән кичкә кадәрге һава температурасы, җилнең юнәлеше тасвирланган...

Газетаның һәр саны «цензура комитеты» дигән сүзләр белән тамгаланган, алар басманың цензура иләгеннән үткәнлеген аңлаткан.

«Волжско-Камское слово» (1881-1882) газетасы да – иҗтимагый-сәяси эчтәлектәгеләр рәтендә. Ул төп дөнья күләм вакыйгалар, Россия империясендәге хәл-әхвәл, Казан губернасындагы яңалыклар турында язган. Тимер юллар үсеше, янгын куркынычсызлыгы, банклар эшчәнлеге, икмәклек акча алып тору кассалары оештыру, театрлар, китапханәләр эше кебек мәсьәләләр дә күз уңыннан читтә калмаган. Шәһәр китапханәләренә яңа китаплар һәм матбугат басмалары алынуы турында хәбәрләр дә еш күренгән. Китапханәләрнең шәхси булып, хуҗасының фамилиясе белән аталуын әйтергә кирәк, мисал өчен Проломная (хәзерге Бауман) урамындагы Н.И.Студенский китапханәсе.

Шәһәрдә бакчалар һәм парклар күп булган, аларда көн саен диярлек халык бәйрәмнәре яки күңел ачулар үткәрелгән, оркестрлар уйнаган, русча җырлаучы хорлар чыгыш ясаган... Концертлар көндезге уникедә башланып, кичке тугызларда тәмамланган. Шулай ук ат чабышлары зур популярлык казанган, аларны тамаша кылу өчен халык күпләп җыелган. Газета саннарын укып, XIX гасырның икенче яртысында Казан шәһәре яшәешенең төрлелегенә шаккатасың һәм сокланасың.

«Волжский вестник» газетасы да мөһим һәм сорала торганнарның берсе булган, шулай ук көн саен чыккан. Аның эчтәлеге тагын да төрлерәк. Кызганыч, безнең фондларда аның 1888 елгы саннары гына бар.

«Казанская газета» алга таба «Земская неделя» дигән исем белән 1903-1917 елларда басылган, аны Казан губерна земствосы идарәсе атна саен чыгарган. Шәһәр халкы аны яратып һәм кызыклы повестька яки нинди дә булса романнан өзеккә юлыккан кебек йотлыгып укыган. Заманасы да ярсулы булган бит: тиз-тиз узучы давыллы вакыйгалар, даими алмашынып торучы сәяси вазгыять – болар укучыны кызыксындырган. Сугыш

барышы, илдәге вакыйгалар һәм земство тормышы газетаның алгы планына чыккан. Яхшы ясалган реклама соклану тудыра, дөрес сайланган хәреф һәм цифр үлчәмнәре дә укучы игътибарын тарта.

Газетаның 1916 елгы бер санында «Ценное приобретение» дип исемләнгән мәкаләгә тап булабыз, аңарда шул ук елның 24 гыйнварында Казан губерна земствосының З.Н.Ушковадан Воскресенская урамындагы йортын (хәзер Кремль урамындагы 33 нче йорт, Татарстан Республикасының Милли китапханәсе бинасы) сатып алуы турында бәян ителә. Шушы уңай белән тантана да уздырылган, анда дворяннарның губернадагы җитәкчесе С.С.Толстой-Милославский, дворяннарның өяздәге җитәкчесе А.Н.Боратынский һәм губерна земство идарәсе әгъзалары, матбугат вәкилләре катнашкан.

Воскресение чиркәве рухание гыйбадәт кылган, император галиҗәнаплары сәламәтлеге өчен дога укылган, өч тапкыр «Ура» кычкырып, милли гимн башкарганнар, аннары кунакларга ипи-тоз тәкъдим иткәннәр. Йорт иминият комитеты хисабына сатып алынган, әлеге оешманы бирегә үк урнаштырганнар да. Бик кыйммәт бәягә сатып алуны җентекләп һәм ачыктан-ачык аңлаткан язмалар да газета битләрендә урын алган. Бу бинада кемнәр генә булмаган; берсеннән-берсе кызыклырак мәгълүматлар, серләр саклый ул!

«Казанский телеграфъ» газетасы көн саен чыккан, укучылары күп булган, чөнки, сәясәттән, иҗтимагый һәм мәдәни тормыштан гайре, шәһәрнең сәүдәгәрләр тормышын да яктырткан. Монда тормышта кирәкле һәртөрле мәгълүмат табарга мөмкин: театрларда нинди спектакльләр бара, кемнәр гастрольгә килгән, сәүдәгәрләр җыелышында ни турында сөйләшкәннәр, каян бүләк сатып алырга, нинди китаплар нәшер ителгән, сәламәтлек саклау белән бәйле хезмәт күрсәтү төрләре. Газетаның хатын-кызларга игътибары зур булган: ничек матур булырга һәм матурлыкны ничек итеп озак сакларга, һуштан яздырырлык эшләпәне, алтын бизәнү әйберләрен, кояштан саклану өчен кулчатырны каян сатып алырга һ.б. Ир затларын да читтә калдырмаганнар, аларга да киемнәр һәм ислемайлар, корал, сәламәт булу чаралары, иң тәмле сыра, эшкә урнашу белдерүләре тәкъдим ителгән.

Телгә алынган басмаларның барысында да әдәби сәхифәләр чыгып килгән, аларда яңа китаплар, әдәби әсәрләр турында фикер алышканнар, повестьлардан өзекләр, фельетоннар урнаштырганнар.

«Казанская кооперативная газета» һәм «Крестьянская газета» махсуслашкан басмалар булып саналган. Беренчел куллану товарлары өлкәсендә сәүдәне үстерүгә зур урын бирелгән. «Крестьянская газета» атнага ике тапкыр чыккан, крестьяннар, авыл хуҗалыгы, җир эшләре, авылларда йөреп кайту нәтиҗәләрен тикшерү, хатын-кызлар бунтлары мәсьәләләрен үзәккә куйган. Крестьяннарның хокуклары, крепостной бәйлелектән котылу һәм алга таба ничек яшәү турында язылган китапларга багышланган аерым бүлек тә булган.

Вакытлы матбугат бүлегендә саклана торган рус телендәге газеталар яхшы сыйфатлы кәгазьгә басылганнар, хәзергә кадәр файдаланырлык хәлдә саклананалар. Аларны китапханәгә килүчеләр еш сорап ала; битләрендә элеккеләрнең гамәли тәҗрибәсе һәм безнең төбәк тарихы чагылыш тапканга күрә, аларга карата кызыксыну кимеми. Үткән заман сәхифәләрен бер-бер артлы ача барып, без Казан губернасы яшәешенә, шул заманда гомер сөргән, ниләрдер тудырган һәм иҗат иткән кешеләр тормышына чумабыз, үзебезгә файдалы мәгълүмат алабыз, ата-бабаларыбыз белән горурланабыз.

Дәвамы бар ■

Кала тавы

«Кала тавы» яки «Калатау» – этнәлеләр Күәм авылыннан ерак түгел урнашкан, Ашыт елгасының уң ярындагы биек урынны менә шулай атап йөртә. Археологиядә исә Кала тавы «Әйшияз шәһәрчеге» исеме белән билгеле.

Тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани бу кала ислам мәмләкәтенең чиге булып, чирмешләрдән сакланыр өчен кальга буларак хезмәт иткәндер, дигән фикерне

әйтә. С.М.Шпилевский Әйшияз шәһәрчеге үрләренең кирпеч ишелүдән барлыкка килгәнлеген фаразлый. Димәк, үр өстендә кайчандыр кирпеч дивар булган, шунда ук чокыр, керү юлларының да булганлыгы күренә. 1956 елгы казу эшләре вакытында биредә б.э.ның I меңьеллыгы уртасына хас керамика кисәкләре табылган. «ТАССР тарихы»ның I томындагы картада бу шәһәрлектә бронза гасырга, ягъни б.э.к. II меңьеллыкка нисбәтле ядкәрләр барлыгы турында язылган. Кыскасы, Калатау – сере әлегә кадәр ачылмаган изге урын. Якында гына халык телендә «Ханнар зираты» дип йөртелгән Әйшияз каберлеге (XVI гасыр) һәм изге чишмә дә бар.

2000 нче еллар башында Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе **Әсгать Әхмәт улы Сәфәров** бу изге урында намаз укыр өчен гыйбадәт йорты төзетте, 2015 елда анда бик күп игелекле гамәлләр кылган «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры **Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин** җитәкчелегендәге элемтәчеләр төркеме яңарту-төзекләндерү эшләрен башкарды. ■

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

ТИМЕР ЮЛ КЫЙССАСЫ

Егерменче гасыр башларында тимер юллар салу Россиянең икътисади үсешенә гаять уңай йогынты ясый. Элек гомер-гомергә йөкне җәен су юлыннан баржаларда, кышын исә ат чанасында ташыганнар, ә йөк машинасы турында хыялланырга гына калган...

1911 елда Россия хөкүмәте Мәскәүдән Екатеринбургка тимер юл салу хакында карар кабул итә. Россия үзәгеннән – Себергә, Ерак Көнчыгышка яңа юнәлешләр ача торган проектны эшмәкәрләр, сәүдәгәрләр һәм гади халык – һәммәсе хуплый. Министрлар Советы утырышы 1912 елның 27 апрелендә уздырылып, анда бертавыштан «Мәскәү-Казан тимер юл җәмгыяте»нең «Казан-Сарапул-Екатеринбург» проекты җиңеп чыга. Дәүләт Советының Икенче департаменты да әлеге проектны яклый.

Әмма тимер юлның кайсы торак пунктлар аша үтү-үтмәве бик зур бәхәсләргә сәбәпче була. Биредә хикмәт шунда ки, һәр җирле түрә вә эшмәкәр тимер юлның нәкъ менә үзләре яшәгән кала йә авыл-сала тирәсеннән үтүен тели. «Казан-Екатеринбург тимер юлы» проекты Кукмара эшкуарларын канәгатьләндерми, чөнки киез, киез итек сәнәгате үсеш алган авыл проекттагы тимер юлдан читтә калачак... Өязгә тимер юлсыз калу ихтималы янаганга, Мамадыш өязенең җир управасы да бу проектка каршы чыга. Ниһаять, әлеге четерекле мәсьәләне хәл итү эшенә «Бертуган Комаровлар» сәүдә йорты хуҗаларының берсе Николай Васильевич Комаров алына. Мамадыш өязендәге икътисади вазгыятьне яхшы белгән бу дәүләти фикер йөртүче шәхес «Мәскәү-Казан тимер юлы җәмгыяте» идарәсенә, Кукмараның фабрика-заводларына зур йөк әйләнешенең үтә мөһимлеген исбатлап, саллы дәлилләр китереп мөрәҗәгать итә. Тимер юлны Кукмара авылы аша үткәрү өчен, Н.В.Комаров тимер юл төзү җәмгыяте җитәкчеләренә зур ришвәтләр

Тимер юл төзелеше



Кукмара тимер юлы. 1960 нчы еллар

биргән икән, дигән имеш-мимешләр дә йөри .Тик бу дөрес түгел. Тимер юл салу кебек әһәмиятле стратегик объект бик җитди исәп-хисап, анализ ясаганнан соң гына, анда да күмәк рәвештә генә раслана. Җирле фабрикантларның гозерләре, дәлилләре исә фәкать дәүләти мәнфәгать күзлегеннән чыгып кына карала.

1913 елның 14 маенда «Казан-Екатеринбург» тимер юлы төзелешен раслаган Югары Фәрман (Высочайший Указ) игълан ителә. Ә бер айдан, 13 июльдә илнең тимер юллар министры С.В.Рухлов, Кукмара аша үтүче яңа тимер юл проекты вариантлы белән килешеп, имза сала. Линиянең бөтен озынлыгында тимер юл кору эшләре башланып китә.

Ниһаять, 1916 елда Кукмара аша тәүге поезд үтә! 1920 елда исә тимер юл вокзалының беренче бинасы файдалануга тапшырыла. Шәһәрнең хәзерге тимер юл вокзалы 2005 елда төзелә.

1991 елда, Кукмара киез-киез итек фабрикасы директоры Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин идеясе һәм фабриканың матди ярдәме белән, пассажирлар өчен «Бертуган Комаровлар» тукталыш платформасы төзелә. Аның рәсми атамасы «927 нче километр» исә, халык күңеленә ятышлы булмаганлыктан, күрәсең, сирәк яңгырый. Ә менә Кукмара төбәгенә бөтен гомерен багышлаган Бертуган Комаровлар халык хәтерендә сакланып калган, аларның хезмәтләре һәм исемнәре әле дә яши! ■

«Бертуган Комаровлар» тукталышы

ОКТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru, tatar-congress.org/ru сайтларында

● Сентябрь ахырында бертөркем язучылар Мөслимдә булды. Алар дүрт мәктәптә очрашуда катнашты һәм чыгыш ясады. Язучылар шулай ук Флүс Латыйфи һәм Харрас Әюпов каберләренә чәчәкләр салды, мәшһүребез – шагыйрь Зөлфәтнең туган йортына элмәтакта куюда катнашты. Шундый ук элмәтакта Мөслимдә яшәп иҗат итүче әдип, Татарстанның халык язучысы Фоат Садриев йортына да куелды.

● 1 октябрь көнне Татарстан Язучылар берлеге «Өлкәннәр көне» уздырды. Әдәби-музыкаль кичә рәвешендә үткән әлеге мәҗлескә өлкән язучылар һәм вафат булган әдипләрнең хатыннары чакырылган иде. Язучылар бу көнне Лев Гумилев һәйкәленә чәчәкләр дә салды.

● 4 октябрь көнне Каюм Насыйри исемендәге музейда күренекле прозаик һәм шагыйрь, юмор остасы Фаил Шәфигуллин һәм аның абыйсы, диңгезче-рәссам Шәүкәт Шәфигуллинны искә алу чарасы булып үтте. Әлеге күркәм чараны музей директоры, әдип Ф.Шәфигуллинның кызы Раушания ханым оештырган иде. Әдәби-музыкаль кичәдә Ф.Шәфигуллинның хатыны, күренекле шагыйрә Эльмира Шәрифуллина, онык Сәгыйть Камалиев, шулай ук Ф.Шәфигуллинның дуслары, каләмдәшләре, аерым алганда, нәфис сүз остасы, әдипнең якташы Рәшит Сабиров, артист һәм язучы Хәлим Җәләй, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург Данил Салихов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, җырчылар Миңгол Галиев һәм Илгизәр Исламов, скрипкачы Динә Закирова, галимнәр Фоат Галимуллин, Зөфәр Рәмиев һ.б. катнашты һәм чыгыш ясады.

● 4 октябрь көнне Казанда Әхмәтһади Максудиның тууына 150 ел тулуга багышланган кичә узды. Чарада «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин да катнашты.

● 7 октябрьдә Актаныштa һәм Киров авылында Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, күренекле драматург һәм прозаик Данил Салиховка 60 яшь тулуга нисбәтле әдәби-музыкаль кичәләр булып узды. Әлеге күркәм чараларда Казаннан, Чаллыдан һәм Башкортстаннан бертөркем язучылар катнашты. Алар арасында Эльмира Шәрифуллина, Фәйрүзә Мөслимова, Рифә Рахман, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Рәдиф Сәгъди,

Вахит Имамов, Әлфия Ситдыйкова, Факил Сафин, Халисә Мөдәррисова һәм Ләбиб Лерон бар иде.

● 10-12 октябрьдә Ульяновск өлкәсендә Татар мәгарифе көннәре үтте. Зур чараларның берсе Иске Кулаткы районында узды. Чарада галим Олег Хисамов, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова һәм Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты, «Безнең мирас» журналының бүлек мөхәррире, шагыйрь Марат Закир катнашты.

● 13 октябрьдә татар зыялылары дәүләтебезне яклап шәһит киткән каһарман бабаларыбызны искә алуга багышланган Хәтер көнен үткәрде.

● 15 октябрьдә К.Тинчурин исемендәге театр бинасында танылган драматург, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Хәбибрахман улы Салиховка 60 яшь тулу уңаеннан тантаналы кичә узды. Әдипне Татарстан Республикасының премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, Татарстан Республикасының мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, «Татнефть» ААҖ генераль директорының урынбасары, «Рухият» фонды рәисе Рөстәм Мөхәммәдиев, театр әһелләре һәм башка күренекле шәхесләр котлады. Юбилярга Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең дә котлавын ирештерделәр һәм бүләген тапшырдылар. Тантаналы кичәне артистлар Резеда Сәләхова һәм Артем Пискунов алып барды.

● 15 октябрьдә Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасы янында атаклы балет биючесе Рудольф Нуриевка һәйкәл ачтылар. Биш метрлы скульптураның авторы – Зураб Церетели.

● 19 октябрьдә Тукай районында Татар әдәбияты көннәре узды. Фәннур Сафинның туына 70 ел тулуга нисбәтле әлеге чарада Тукай муниципаль районы җитәкчесе Фаил Мисбах улы Камаев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, «Казан утлары» һәм «Безнең мирас» журналлары, шулай ук «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррирләре Рөстәм Галиуллин, Ләбиб Лерон, Вахит Имамов һәм башкалар катнашты.

Мирасворд

Киләпле җепне йомгакка урага нда кулланыла торган җайланма

100 квадрат метр

Явым-төшемсез, болытсыз (диал.)

Сугым аты

Борынгы Русь дәүләтендә: халык җыелышы

Шагыйрь Шамил …

Әхәт Гаффар романы

Җәя җебе

Татар халык җыры

… Маликов (татар шагыйре, прозаик)

… Бор (Дания физигы)

Гореф-гадәт

Мәшһүр немец шагыйре

Он тузаны

Борынгы грек шагыйре

Фәйзуллин, Шәрәфи

… Вәлиди

Җырның нинди дә булса бер өлешен бик тиз башкару

Патша Россиясендә дворян титулын алган татар-башкорт түрәсе

Сүз, сөйләм (иск.)

Мәче башлы ябалак (диал.)

Станислав … (поляк язучысы, фәлсәфәче)

Алтын Урда ханы

«Алтынчәч», «Сания», «Качкын»

Байрак (иск.)

Рус географы, диңгез сәяхәтчесе

Ярдәмлек сүз төркеме

Быргы (иск.)

XIX йөз рус рәссамы

… Баһман

Боек … юлы

Мөритләр башлыгы

Чыңгыз хан империясе таркалганнан соң оешкан дәүләтләр исеме

Ат җигү дирбиясе

… Юзиев



Күрәзәлек, юрау

Борынгы Идел

Камил Кәримов романы

Зөяннең сул кушылдыгы

Казах, кыргызларда: шагыйрь-импровизатор, җырчы

Ромул һәм … (Римга нигез салучылар)

Якутиядәге елга

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Султан уңга: баек, сәвер, «Кояш», рөшди, Луи, Гидаш, «Муса», Филүс, ямь, Гаттар, белек, «Уку», Абрек, тояк, куәтле, ату, Шәкүров, ерак, Агаян, яга, пиннек, Ак.
Өстән аска: «Яра», афоризм, Бикә, ук, Кашшаф, беләү, япа, шилек, трагик, «Логан», үгет, Ева, ни, Сарымсаков, Еники, «Сиваш», Туктар, дуадак, та, Раил, Рубрук.

Рәис Габдулла төзеде.

Башкалабыз Казандагы Дәрвишләр бистәсе урамында урнашкан С.Сәед-Галиев исемендәге Мәдәният сарае. 1959 елда төзелгән

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / ноябрь

550 ел элек (1468)

Мәскәү кенәзлегендә, татар дәүләтчелеге мәнфәгатьләренә карaганда, малны-байлыкны өстен күргән татар аксөякләре буыны барлыкка килә һәм Иван III, Казан ханлыгын яулап алу өчен аларны ныклап торып файдалана. Бүгенге көнгә кадәр дәвам итүче «сатлык татарлар чоры» башлана.

130 ел элек (1888)

15 ноябрьдә Казанда беренче телефон эшли башлый.

110 ел элек (1908)

Ганҗә шәһәрендә (хәзер Азәрбайҗанга карый) Хөсәен Ахундов мөхәррирлегендә атналык «Истикъбаль» («Киләчәк») милли-демократик газетасы чыга башлый.

100 ел элек (1918)

Ноябрь урталарында Кәрим Тинчурин Казанга кайта һәм «Сәйяр» труппасында актер вә режиссер булып эшкә керешә.

95 ел элек (1923)

30 ноябрьдә Казан университеты оештырган кичәдә Шамил Усманов,Һади Такташ һәм Кави Нәҗми яңа әсәрләрен укый.

90 ел элек (1928)

16 ноябрьдә Казанда Таҗи Гыйззәт һәм Салих Сәйдәшевнең «Наемщик» музыкаль драмасы куела. Режиссеры – Сөләйман Вәлиев-Сульва.

60 ел элек (1958)

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры Г.Тукай әсәре буенча эшләнгән «Кисекбаш» балетын (Ә.Фәйзи либреттосы, Г.Гобәйдуллин музыкасы) күрсәтә.

55 ел элек (1963)

1858 елда, Россия белән төзелгән Айгун килешүен юкка чыгаргач,Кытай хакимиятенең җирле түрәләре Голҗа каласында 1920 елдан бирле Габдулла Тукай исемен йөрткән урамны Тәңре Тау урамы атамасына үзгәртәләр.

45 ел элек (1973)

23 ноябрьдә башкалабызның Дәрвишләр бистәсендәге Мәдәният сараенда Атилла Расихның «Язгы авазлар» романы буенча укучылар конференциясе оештырыла.

25 ел элек (1993)

17 ноябрьдә галим һәм язучы Миркасыйм Госманов җәлилчеләрнең үлем алды шаһиты булган Корьәнне Муса Җәлилнең Казандагы музей-фатирына тапшыра.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. НОЯБРЬ 2018

Историческое наследие: «Гаухаршад». О.Иванова; «Судьба Казанского ханства». Б.Хамидуллин; «Ичкинские татары». Р.Исакаев; «Гани бай». Б.Шараф; «Татарские деревни после голода в Поволжье». Р.Сабиров; «Шамские татары». Л.Муртазина; «Татарская свадьба в арабской среде». Камал; «Род Риза казия». Р.Шагиев; «Страна Качи». Ф.Закиров.

Татарский мир: «Буинская Талия». М.Хабутдинова.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Жизнь». С.Максуди; «Поэт Бадруш Мукамай». Ф.Хабибуллин.

В глубине памяти: «Слушайте, говорит Казань!». Ф.Галимуллин; «В памяти, до сих пор в памяти!».

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. NOVEMBER 2018

Historic heritage: «Gaukharshad» by O.Ivanova; «The fate of Kazan khanate» by B.Khamidullin; «The Ichken Tatars» by R.Isakaev; «Gani richman» by B. Sharaf; «The state of the Tatar villages after starvation» by R.Sabirov; «The Tatars of Shamskiy village» by L. Murtazina; «Tatar wedding in Arabic manner» by Kamal; «The kin of Riza kaziy» by R.Shagiev; «Kacha country» by F. Zakirov.

Tatar world: «Taliya from Buinsk» by M. Khabibullin.

Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov.

Literary heritage: «Existence» by S. Maksudi; «Poet Badrush Mokamay» by F. Khabibullin.

In the deepest store of memory: «Attention, please, Kazan is broadcasting!» by F. Galimullin; «Still keeping in the memory, still keeping!».

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

1960 елның 28 августында Казан шәһәрендә туа.
Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый.
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РФ һәм ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы.
Рәссам Алсу Адлер кызы китап графикасы һәм декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендә дә эшли, Татарстан тарихы һәм этнографиясе белән кызыксына. Казан шәһәрендә яши һәм иҗат итә.

Алсу Адлер кызы Тимергалина

«Якшәмбе көн». 1910. Киндер, майлы буяу

«Иске Казан. Бауман урамы». 2003. Киндер, майлы буяу

«Иске Казан. Госман мәчете». 2005. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

«Сау бул, авылым!» Хәлим Җәләй

Тәрҗеман-әл-Әнҗерән нәселе. Алсу Низами

Безнең заман һәм замандашлар. Роза Хәбибуллина

«Яңгыр җиле» яңгыр вәгъдә итә. Мөдәррис Әгъләм

Тел күрке – сүз, милләт күрке – тел. Рәсим Хәбибулла

Сау бул, авылым! Хәлим Җәләй

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
• *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275 (П-7074)
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

*«**БЕЗНЕҢ МИРАС**» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*